Каюм Насыйриның (1825–1902) тууына 200 ел булу уңае белән үткәрелә торган чараларга мөнәсәбәттә, әледән-әле: «Каюм Насыйри – основатель татарского литературного языка» дигән фикер кабатлана. К. Насыйриның иҗади эшчәнлеге башланган XIX гасырның уртасына кадәр, татар халкының төрки-татар язма әдәби теле җиде-сигез йөз еллар буена эзлекле кулланылышта булуы мәгълүм. Әлеге үзенчәлек гомумтюркологик хезмәттә ассызыклана. «Языки мира. Тюркские языки» дигән энциклопедик басмада, төрки гаиләнең борынгы һәм хәзерге вакытта яшәүче 39 халык теленең язмачылык тарихы V-VI, VIII–IX, X–XII йөзләрдә гомумтөрки гаиләдә башланып, XII–XIII гасырдан үз дәүләтендә язылган истәлегенең язылу датасы билгеле булганга, иске язулы телгә ия (старописьменные) халыклар дигәндә, азәрбайҗан, төрек, төрекмән, уйгур, үзбәк телләре белән рәттән, татар теле дә истә тотыла [51: 358]. Төрки-татар теленең язма истәлеге дигәндә, Кол Галинең, үз дәүләте Болгарда, сәнгатьчә нәфис образлар белән иҗат ителеп, 1233 елда тәмамланган «Кыйссаи Йосыф» поэмасы күз уңына куела. Димәк, Кол Галине, үлемсез әсәре белән, халкыбызны иске язулы телләр рәтендә раслатучы мәшһүр шәхес икәнлеген дә истә тотарга тиеш булабыз. Галимнәр белдерүенә күрә, иске язулы телләрнең әдәби нормасы формалаша, әлеге норма традиция буларак дәвам ителә, аерым дәүләт (төбәктә) яшәүчеләрнең сөйләмә тел үзенчәлекләре белән баетылуы, язма норманың төрле вариантлары белән кулланылышын барлыкка китерә [1: 533]. Әлеге юнәлештә, К. Насыйри әдәби язма телебезне нигезли дигәндә, нәрсәнең ничек итеп расланuын төгәлрәк ачыклау сорала. Тема итеп билгеләнгән «Татар әдәби теле тарихы – аның стильләре тарихы ул» дигән фикер кысасында, галимнең, язма әдәби телне сөйләмә телдән аерып карарга кирәк булуын ассызыклап, үз чоры әдәби теленең функциональ стильләрендә иҗат итүен, мәкалә кысасында тезислар рәвешендә булса да анализларга җөрьәт ителә.

К. Насыйриның кулъязмаларын өйрәнүче М. Гали туганнарына язылган хатларының сөйләмә телдә булуын белдерә [5: 127]. Классик мәгърифәтче галим, сөйләмә тел дигәндә, табигый җанлы сөйләшү баруын

Н.И. Ильминскийга язган хатында аңлата [48: 176]. Шуның белән бергә: «Мәдәниятле һәрбер адәмнең ике төрле теле булып, берсе анасыннан сөт имгән мөддәттә үгрәнгән теледер. Икенчесе, дәхи бер остазга тәгълимгә бирелгәч, гыйлем вә фән лөгатьләре белән ачылган теледер», – дип, язма телнең үзенчәлеген билгели [33: 31–32; 22: 299]. Шулай итеп, татар халкының бөек мәгърифәтчесе, Казан төрки лингвистика мәктәбенең күренекле вәкилләре булган, И.А. Бодуэн де Куртенэ (1845–1929), Н.В. Крушевский (1851–1887), В.А. Богородицкийлар (1857–1941) белән бер үк вакытларда, җанлы сөйләмә телнең язуда чагылыш таба торган язма әдәби тел белән тәңгәл күренеш булмавын, «...телемездә ун төрле тауыш хәрефләре бардыр ки, ...ошбу ун тауыш хәрефләре бәрабәренә өч галәмәтебез бар дыр...», – дип, татар телендәге сузык авазлары әйтелешенең язуда дөрес чагыла алмавын исбатлый [35: 3; 22: 301]. Бу уңайдан, язма әдәби телдә, сүзләрне вазыйфаларына туры китереп, кулланырга кирәклек, ягъни татар сүзләре белән гарәп һәм фарсы алынмаларының төрле максаттан файдаланылуы күрсәтелә [34; 21: 32–33]. Әлеге нигездә, татар теле дип башланган беренче хезмәтеннән үк, теле белән бергә милләт тә, халык та татар дип атала, татар теле атамасының тарихтан килүенә ишарә ителә [29; 21: 29]. Татар атамасының тарихтан килүе дигәндә, К. Насыйриның, XVIII гасыр ахырларында, С. Хәлфин эшчәнлеге белән башланып (1778, 1785), алга таба күп сандагы авторлар тарафыннан, русларга татар телен укыту өчен, дәреслекләр язылуына нигезләнүе аңлашыла. Әлеге эшчәнлекнең мөһимлеге академик А.Н. Кононов җитәкчелегендә төзелгән хезмәттә билгеләнә: «Первым преподавателем татарского языка для русских именным указом Екатерины II был назначен казанский татарин Сагит Хальфин (приступил к преподаванию 5 октября 1769 г.) родоначальник хальфинской династии преподавателей татарского языка <...>» [19: 18]. Бу эшчәнлек XVIII гасыр урталарында Россиянең барлык төбәкләрендәге уку йортларының программаларында «татарский язык» дигән предмет куелуы белән дәвам ителә. «Кроме светских духовных заведений подготовкой специалистов по восточным языка занимались также духовные заведений. Одним из крупных центров подготовки востоковедов, и в частности тюркологов, для миссионерской деятельности, были Казанская духовная академия и семинария...», – дип, бу юнәлештә эшләүчеләрнең нинди хезмәтләр язулары күрсәтелә [19: 9-90]. Билгеле ки, русларга татар телен укыту өчен беренче басма дәреслек С. Хәлфин тарафыннан языла. «Письмо у Татар пишется от правой руки къ левой, такъ какъ и книги у них начинаются; и оно собственныхъ буквъ не имеетъ; а употребляются въ немъ Арапская, у коихъ считается дватцать девять» дип, «Азбука татарского языка...» хезмәтендә, 29 хәреф, башта кириллда язылып исеме бирелә һәм сүз башы, сүз уртасы, сүз ахырындагы язылышы белән гарәп графикасында күрсәтелә [19: 282]. Шулай итеп, гасырлар буена гарәп графикасы белән башланып, дәүләтенең атамасы белән, Болгар төркисе, Алтын Урда кыпчак төрки-татар теле, Казан ханлыгы классик иске-татар теле дип, төрки нигез истә тотылып, гасырлар буена эзлекле кулланыла торган төрки-татар теле дигән төшенчә, кирилл-рус хәрефе белән күрсәтелеп, төрки тамыры истә тотылмыйча, И. Гиганов сүзлегендә «российско-татарский» дип билгеләнгән язма телне [19: 147], Россиянең барлык төбәгендә яшәүче русларга, Әби патша хөкеме

белән укыту башлана. Татарларга рус телен өйрәтү истә тотылмый. Өйрәтүчеләр, асылда, Казандагы духовная академия һәм семинария укытучылары була. Әлеге даирәдә Каюм Насыйриның татар теле дип, ижади эшчәнлеге башлана; әмма халык үз теленең Болгар-Казан төркисе дип исемләнгән вакытлары булуын да яхшы хәтерли. Шуның белән бергә, К. Насыйри беренче хезмәтен дә үк: «Кыскача татар нәхүе. Татарча һәм урысча үгрәнүчеләргә файдалы гыйлем булсын өчен...» дип, кемгә ни өчен язуы турында махсуслап искәрмә ясый [29; 22: 289]. Ижади өйрәнү барышында: «... Татар теле мөстәкыйль бер тел булса, әлбәттә, үзенә махсус дөрес язу кагыйдәләрен аңлату да синтаксис мәсьәләләренең бер тармагы булуы үзенчәлегеннән, гаять игътибар кылыначак шәйдер», – дип, аңлатма бирә [29; 21: 29–30]. Татар телен, русларга өйрәтүчеләрнең ысул / максатыннан үзгә халәттә, аның үзенә хас кагыйдәләре белән мөстәкыйль тел булуын аңлап, махсус фән буларак тикшерергә кирәклек зарурлыгы ассызыклана. Аның төрле тармакларын, аларның кагыйдәләрен ислах кылып аңлатырга кирәклекне исбатлау юнәлешендә ижат итә. XX гасыр башында, галимнең ижаты турында сүз әйтүчеләр аның татар теле дигән атамасын хуплап, яратып кабул итә. Ф. Әмирхан: «...иң әүвәл татарларга үзләренең бер телләре бар икәнен белдертер өчен, "Ләһҗәи татари" вә "Фәвакиһел җөләса" тәэлиф итүче вә ул ук, иң әүвәл, әсәрләрен татарча яза башап, һәр язу таныган кеше истифадә итәрлек тарызда ясаучы...» дип, куанычын белдерә [2: 67–73]. Ж. Вәлиди: «Каюм әфәндегә кадәр татар теле дигән бер тел йук иде. Телемезне иң әүвәл бер телгә хисаблаб аның да кагыйдәсе барлыгын, башка телләрдән ким булмавын вә хәттә артыклылары булуын дәгъва вә исбат итүче улдыр», – дип, галимнең ижаты өйрәнелгәндә, аның бу үзенчәлегенә игътибар ителергә тиешлеген билгели [4: 61]. Чыннан да, галимнең эшчәнлеген, ижтимагый-сәяси вәзгыятькә нигезләп тикшерү барганда, Г. Ибраһимовка хас булганча, бер мәкаләдә кистереп әйтелгән фикер, икенче мәртәбә тагын да киңәйтеп дәвам ителүе күренә [16: 220–222.]. К. Насыйри хезмәтләрен рус мөстәшәркъләре (востоковеды) төзегән сарыф китаплары белән чагыштырып аңлата: «Боларның һичберендә татар теленең үзенә махсус хасыятләре бөтенләй юк <...>. Боларны татар теленең сарфы һәм нәхүе дип атарга һичбер юл юк <...>. 1895 елда К. Насыйриның "Әнмүзәҗ"е чыга. Хәзерге көндә санлары егермегә якынлашкан сарыф һәм нәхү китапларының башы, бисмилласы – Каюм әфәнденең шул китабыдыр» [17: 110–111]. Әдип әсәрләренең 8 нче томын төзүче Ф. Фәсиев тарафыннан бу фикергә искәрмә ясала [17: 377–378]. Г. Ибраһимов үзенең фикерләрен йомгаклап бирергә кирәк дип саный [18: 483–484]. Телче галим Л. Җәләйнең «Татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәте һәм Каюм Насыйри» дигән мәкаләсе басыла [12; 22: 311]. Шул ук рухта Х. Курбатовның мәкаләсе языла [20; 22: 310]. Әлеге юнәлештәге тикшерү әдәбиятчы галим М. Гайнуллин тарафыннан колачлы булып үстерелеп дәвам ителә [6: 127–171; 7: 258–273]. XXI гасыр башында, академик М.З. Зәкиев, югарыда әйтелгән фикерләргә нигезләнеп: «Здесь необходимо особо осветить деятельность Каюма Насырова по разработке норм татарского национального литературного языка. В историю татарского народа он вошел как основоположник татарского национального литературного языка», – дип белдерә. Әмма, фикер дәвам ителә: «Как известно, литературный язык состоит из

множества стилей. Полное формироване национального литературного языка происходит лишь тогда, когда все стили его основываются на общенародных нормах» [14: 29, 31]. Димәк, «Әдәби телнең тарихы – аның стильләре тарихы ул» дип, тикшерү барганда, бу мәсьәләнең мөһимлеген истә тотып, өйрәнүне дәвам итәргә кирәк булу аңлашыла. Стиль, стилистика дип сүз башлаганда, әлеге фән тармагына нигез салучы, татар тел белеменең беренче фән докторы, танылган педагог-остаз Л. Җәләй (1894–1966) хезмәтләренә мөрәҗәгать итү объектив дөреслеккә туры килә [3]. Галимнең беренче мәкаләләрендә: а) стиль – ул бер әдәбият,телгә караган нәрсә генә түгел, б) стиль – ул сыйныфның яшәү, көрәш, үз интересларын яклауда кулланылган алым үзенчәлекләреннән тора", – дип аңлатыла [8]. Әлеге юнәлештәге гамәли эшчәнлекнең, ягъни хосусый текстны язма сөйләм күренеше буларак ничек тикшерелергә кирәклек мәсьәләләре «Практик стилистика алдында торган төп бурычлар» дигән мәкаләдә яктыртыла [9]. «Тукай телендә фигыльләр» дигән күләмле язмада дәвам ителә [10]. Л. Җәләй озак еллар Казан дәүләт университетында «Татар диалектологиясе», «Татар теленең тарихи грамматикасы», «Татар әдәби теле тарихы» курслары буенча лекцияләр укый, имтиханнар ала. Мин дә Җәләй аганың 1958-1959 нчы еллардагы лекцияләрен тыңлаучы бәхетлеләрнең берсе булганмын икән. «Әдәби телнең гомумхалык теленнән аермасы – стиль булуда, ул стильләр тарихы» дигән теманы, Л. Җәләй «Татар теленең стильләре тарихы» дигән махсус курс буларак укыта: «Формалашып җиткән әдәби тел биш стильгә бүленә, аларның һәрберсенең тарихы бар: 1) сәнгатьчә әдәбият стиле, 2) фәнни һәм фәнни-популяр әдәбият стиле (гыйльми әсәрләр теле стиле), 3) публицистик (иҗтимагый-политик темалага караган) әдәбият стиле, 4) йомышлы әдәбият стиле, 5) хатлар язу стиле», – дип, бу стильләрне, хосусыйлап тикшерү максат итеп алына. Лекциядә һәр стильнең, әдәби язма сөйләм күренеше буларак, ягъни язма текстлары нигезендә, үзләренә хас табигате, вазыйфасы, терминнары, тарихи үсеш-үзгәреше күзаллана [11]. Шулай итеп, XX йөз урталарында, татар әдәби теле тарихын барлыкка китерә торган функциональ стильләре дигәндә, аның биш төрдә кулланылышта булуы билгеләнә; теория буларак хәзер дә истә тотылуы мәгълүм. Әлеге стильләрне, К. Насыйри иҗатына мөнәсәбәттә, академик Э.Р. Тенишев билгеләгәнчә, әдәби телнең табигатенә хас булган төп биш үзенчәлекнең берсе дип санала торган функциональ-стилистик вариантлылыгына ия булу үзенчәлегенә нигезләп аңлату дөрес дип кабул ителә [49: 67]. Темабызга туры китереп, К. Насыйриның үз чоры язма әдәби телен, функциональ-стилистик вариантлылыкта ничек файдалануын күзаллау максатыннан, авторның мәгълүм хезмәтләрен [21, 22: 289–303] аерым стильләргә нисбәтләп күрсәтергә җөрьәт итәбез. Беренчедән, сәнгатьчә әдәбият стиле дигәндә, К. Насыйри төрек телендә [23], гарәп телендә [24, 25, 26, 27, 28] иҗат ителгән әдәби әсәрләрне, аң / фикерендә эстетик кабул итеп, олуг мәгърифәтче буларак, татар укучысы үз телендә укып аңласын дигән максат белән, татар теленең нәфис сүз-сурәтләре белән «<...> илебездәге ислам кешеләре теленә тәрҗемә ителеп» укучы хозурына тапшыра. Олуг галим М. Гайнуллин тарафыннан җентекләп тикшерелә [7: 150–159; 8: 268–270]. Бу урында, күрсәтелгән әсәрләрне әдәби тел тарихы юнәлешендә караганда, Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасыннан башлап,

әдәби әсәрне укучыга икенчел текст буларак җиткерү ысулының, К. Насыйри иҗатында да яратып дәвам ителүенә игътибар юнәлтәбез. Икенчедән, энциклопедик белемле галим, иҗтимагый тормышны алып бару өчен мөһим булган мәсьәләләрне фәнни яктан тикшерү зарурлыгын аңлый. Бу стильдә «<...> урысча үгрәнүче мөселман егетләре өчен вә һәм татарча үгрәнүче урыс егетләре өчен <...>» – дип башланган юнәлештәге өйрәтү максаты [29], телнең төрле тармакларында дәвам ителеп берләшүе күренә [30; 31; 32]. Максатына ярашлы рәвештә: «<...> бер хосус өчен, рус кешесе белән мөкяләмәгә җитәрлек микъдар белмәк белән хасил булыр», – дип, «русча үгрәнүчеләргә бераз нәсыйхәт» бирелә [30: 34–35]. Шуның белән бергә, «<...> хосусан рус телен укытканда, үз телебезнең кагыйдәсен бәян кылгучы бер китапка мохтаҗ буладыр идем, әгәр берәү үз теленең кагыйдәләрен белмәсә, аңар гайре телне үгрәнү гаять мөшкилдер» [35: 3], «<...> безнең үзебездә тел үгрәнмәк һөнәре моңарчы юк иде», дип, татарларга үз телләрен фәнни нигездә өйрәтү юнәлешендә эшчәнлек башлана [33; 34; 35]. Алга таба, бу юнәлештәге эшчәнлек: «Һәр телнең кагыйдәсе бардыр. Гыйльме хисап, гыйльме җәгърәфия, гыйльме һәндәсә вә табигыять гыйльме риязиятнең (математика) шөгъбәләредер (бүлек). Боларны күрмәгән адәм – адәм булмыйдыр. Адәмне егетләндерә торган фәннәрдер. Һәркайсыннан балаларыгызга бераз-бераз белдермәк лязем иде», – дип [2: 46], иҗтимагый тормышны алып баруда мөһим булган әлеге төгәл фәннәрне тикшергән хезмәтләре басыла [36; 37; 38; 39; 40; 41] һ. б. Гадәти сүзнең истыйлях вазыйфасына «күтәрелүен» автор төрле фәннәрдә төрле ысул белән тормышка ашыра. «Хисаплык» мәсьәләләренең кагыйдәләрен аңлату барышында, татар теленең сүзе алгы планга куела [22: 293; 87–88; 37]. Фәнни стильдә язылган «Тәварихе Казан» хезмәте теленең, төгәл фәннәрне өйрәнеп язылган хезмәтләрдән аерылу үзенчәлеген, К. Насыйри үзе аңлата [21: 69]. Димәк, фәнни стиль дигәндә, жанрына карап, әдәби телнең төрле мөмкинлеге файдаланылуын истә тотарга кирәк була. Өченчедән, К. Насыйри, «Казан халкына мөрәҗәгәте» дигән, сәнгатьчә ялкынлы публицистик (иҗтимагый-сәяси темаларга караган) әдәбият стилендә, тыңлаучыларга эндәшеп, хис-кичерешләре белән «мин» дип үз исеменнән, әлхитабес-салис бүлегендә яза: «Үзегез хәер, балаларыгыз утын, сез бала тәрбия кыла белмисез <...>. Балаларыгызның бары анасыннан имчәк имгәндә үгрәнгән телләре бар <...>. Мәгърифәт иясе бер адәмгә тапшырып тәрбия кыйлдыра алмыйсыз». Әлеге фикер әлхитабер-рабигъ бүлегендә һәм башка бүлекләрдә дәвам ителә [21: 39–48]. Шуның белән бергә, К. Насыйри, әдәби тел тарихында эзлекле булып килә торган ысулны, ягъни башка стильләрнең текстларында да, авторның мөнәсәбәте ачыктан-ачык белдерелган публицистик рухтагы өзекләр белән фикерен тәгаенләве мәгълүм [40; 22: 72; 39; 22: 299]. Димәк, публицистик әдәбият стиленә берләшә торган ялкынлы язмаларын барлап, берәштереп, хосусый функциональ стиль, тоташ язма сөйләм, үзенчәлекле текст буларак өйрәнүне көтә. Дүртенчедән, «Казан шәһәрендә икамәт итүче гыйззәтле мөэмин вә мөселман кардәшләргә игълан кыламын шул хосуста кем, бу Россия мәмләкәтендә торып, русча белмәк дөнья могамәләсе өчен гаять зарур вә мөһим эштер <...>» – дип, йомышлы (эш кәгазьләре) әдәбият стилендә «Игъланнамә» басыла [21: 57]. Бу юнәлештә, галимнең төрле хезмәтләре бергә тупланган

«Игъланәт» дәфтәре дә истә тотыла [22: 302]. Бу урында, Календарьларда басыла торган йомышлы эш-гамәлләренә нисбәтле белдерүләргә игътибар итәргә кирәк була.

Бишенче стиль дигәндә, хатлар язу стиле истә тотыла, профессор М. Гайнуллин хезмәтендә мисаллар белән аңлатыла [21: 24–25], професор В. Хаков хезмәтендә тарихи нигездә өйрәнү барганда, К. Насыйри эшчәнлегенә дә мөнәсәбәт белдерелә: «Мәктүп һәм хат сүзләре элегрәк үзара синоним булып йөриләр. К. Насыйри мәктүп сүзен киң мәгънәдә язу, эш кәгазьләре төшенчәсендә дә куллана [49: 280, 287]. К. Насыйри үзенең "Әбүгалисина кыйссасы"нда патшалар арасында язылган хатта, рәсми-тантаналы яңгыраш тудыру өчен, югары стиль үзенчәлекләреннән файдалана», – дигәндә, «Олуг мәртәбәле падишаһ...» дип башлана торган хатның тексты бирелә [49: 291–292]. Димәк, галимнең төрле кешеләргә, төрле максат белән язылган эшчәнлеген дә барлап, хосусый функциональ стиль, үзенчәлекле язма текст буларак, махсуслап тикшерәсе барлыгы күренә.

Алтынчы һәм җиденче стильләр дигәндә, Л. Җәләй тарафыннан күрсәтелә алмаган, «Шәҗәрәи мөбәракән пәйгамбәр» [42; 22: 289], «Гакаид рисаләсе» [43; 22: 290], «Мохтәсар тәварих әнбия...» [44; 22: 296], «Утыз вәгазь..» [45; 22: 297], «Әхлак рисаләсе» [46; 22: 298], «Тәрбия китабы» [47; 22: 299] кебек әсәрләре истә тотыла. «Бисмиллаһи-р рахмани-р-рахим» аяте белән башланган «Гакаид рисаләсе» болай дип аңлатыла: «Мәгълүм булсын, галимләр вә имамлар әйтмешләрдер һәр мөэмин вә мөселманга өч төрле гыйлемлекне үзенең халенә кирәк кадәр үгрәнмәк фарыз гыйнадыр (байлык), кирәк язу танымаса да галимләрдән тел белән сорашыб үгрәнмәк фарыздыр димешләр. <...> әүвәл, Гакаид гыйлемедер, ягъни иманны вә инти кадны (җитешсезлекне күрсәтү) төзек кыйлмак гыйлемедер. Икенче, фарызларны, ижабларны (уңай ризалыкны белдерү), хәрамны вә хәлялне айыра белмәк гыйлемедер. Өченче, калеб гыйлемедер, ягъни ниятне яхшы кыйлмак, йауыз холыклардан вә йауыз сагышлардан сакланмак, изге холыкларны тотмак бәянында булган гыйлемлекдер» [43: 2–3]. Галимнең бу юнәлештәге эшчәнлеге, XX гасыр ахырларына кадәр, иҗтимагый-сәяси таләпләр кысасында бәяләнә. Олуг галим М. Гайнуллин профессор Григорьевның: «Казан университетында алган гыйлеме Каюм Насыйрины исламга битараф карарлык югары дәрәҗәгә күтәргән. Ул бу яктан безнең Россия мөселманнары арасында беренче кеше», – дип бәяләгән фикерен кабатлый [7: 131; 8: 259–260]. Әлеге фикерләргә мөнәсәбәт белдерү уңаенда, К. Насыйриның «Гәрчә указный булмаса да, тирә-якта Насыйр мулла дип мәшһүр» гаиләдә тәрбияләнеп үсүенә игътибар итү сорала. К. Насыйри иҗаты өйрәнелү уңаенда, татар әдәби теле тарихында, гасырлар буена дәвам ителә торган Илаһият тәгълиматы традициясенең эзлекле рәвештә дәвам ителүе аңлашыла. Менә «Кырык вәзир» кыйссасында: «Ушбу гыйбрәтнамә хикәятләрне тәрҗемә кыйлып интишарына сәбәп булудан максудым, мөтәрҗимнең хәер-дога белән яд кылынмагыдыр», – дип, XIII йөздән, татар сәнгатьчә әсәрләрен тәмамлаганда, укучылардан хәер-дога өмет итү ысулы файдаланыла [6: 250]. Менә «Әбүгалисина кыйссасы»: «Бисмиллаһи-р рахманир-рахим. Әл-хәм дүлиллаһи рабби-л -галәмин вә-л-салават вә-л-сәлам галәә хәйр хилкаһу Мөхәммәд вә сәхаба әҗмәгыйн» дип, башлана һәм «Әл халь тәвәккел галә Аллаһ, тәрҗемәсенә шөруг кыйлдым.

Әл фәкыйрь Габделкаюм бине мөллә Габденнасыйр», дип, махсус ассызыклый [24: 2]. «Кырык бакча» хикәятләрендә Аллаһы Тәгалә төшенчәсе актив файдаланыла [22: 272] h. б. Бу төрдәге өзекләрне дәвам итәргә мөмкин [22: 95], димәк, «Каюм Насыйриның исламга битараф карарлык дәрәҗәгә күтәрелүе»нең бик үк югары булмавы аңлашыла. XX гасырның ахырларында әлеге юнәлештәге эшчәнлекне объектив нигездә тикшерү мөмкинлеге гамәлгә куелгач, галимнең «Утыз вәгазь» әсәрен, гарәп теле белгече Ж.Г. Зәйнуллин тәфсилләп анализлый [13: 47–49]. К. Насыйри иҗатында дини юнәлештәге эшчәнлекнең мөһимлеген, Айдар Хәйретдинов галимнең мәкаләсен тәрҗемә итеп тикшерү барышында һәм үзенең мәкаләсендә, фәнни-объектив дәрәҗәдә җентекләп аңлата. Галимнең дини юнәлештәге эшчәнлеге анализлангач, нәтиҗә ясала: «Как видим, работая в религиозной тематике, учёный выступал как в роли богослова – знатока ислама, так и прогрессивного мыс лителя, знакомящего своих читателей с высокими этическими и гуманис тическими ценностями ислама, показывая его как учение, обращённое к высокому разуму, мысительным способностям и духовным потенциям человека. Сказанное верно как для трудов учёного по исламскому богословию, так и для его религиозно-художественных произведений, посвящённых проблемам воспитания, этики и реабилитации свободы разума. Даже художественно-литературные произведения Каюма Насыри, полностью посвящённые воспеванию высокой роли разума и свободомыслия, тем не менее, выстроены на идейно-содержательной основе постулатов Корана и духовно-нравственных канонов ислама», – дип, ассызыклана [50]. Гомумиләштерелеп әйтелгән әлеге актуаль фикерне, стильләр дип тикшерү барганда: а) «учёный выступал как в роли богослова», ягъни Сәнгатьчә Илаһи / Рухани әдәбият стилендә; б) «<...> так и для его религиозно-художественных произведений, посвящённых проблемам воспитания, этики и реабилитации свободы разума», ягъни Сәнгатьчә Илаһи / Рухани / Инсани әдәбият стилендә дип, ике стильгә нисбәтләп карарга мөмкин булуы аңлашыла. Сәнгатьчә Илаһи, Рухани / Инсани әдәбият стилендә, «Бисмиллаһир-рахманир-рахим, әмма бисмиллаһу хәмед вә салават соңында ошбу “Әхлак рисаләсе” балаларга явыз холыктан сакланып, изге холык белән холыкланмак өчен, ата-ана нәсыйхәте мәнзилендә нәсыйхәтдер», – дип башлана торган хезмәте истә тотыла. Дини гыйлемле булу белән бергә, әхлаклы да булырга кирәклекне, Аллаһы хөкеменә нигезләнеп, баласына ата-ана үзе өйрәтергә тиешлек күз уңына куела. Димәк, бу очракта, Илаһият тәгълиматын, баланың ата-анасы нәсыйхәте рәвешендә, ягъни Аллаһы Тәгалә хөкеме, аерым зат / инсанның эшчәнлеге буларак тормышка ашырылу максаты билгеләнә һәм Сәнгатьчә Илаһи / Рухани / Инсани әдәбият стилендә тасвирлау башлана: «Гәрчә тәмам кагыйдә белән булмаса да, хәрефләрне дикъкать белән дөрес куйдырмак тиеш. Игътибарсыз, аннан моннан сызгаламак язуны вә хәрефләрне тәхфиф кылу (кимсетү) булмас микән, чөнки безнең язу хәреф ләремез Коръән сүзендәге хәрефләрдер, ригая кылмак (хөрмәтләү) тиеш <...>». Шул ук рисаләнең «Гыйлем вә наданлык» дигән өлешендә, гыйлемле булу дигәндә, дөрес ниятләү, уку һәм язу мәсьәләләре истә тотылып: «И газиз бала! Агяһ бул, адәмгә иң әүвәл бигрәк кирәк вә бигрәк лазем нәрсә-гыйлемдер<...>. Илаһи ният кыйлдым гыйлем үгрәнмәккә, белмәгәнемне белмәк өчен вә

белмәгәннәргә үгрәтмәк өчен вә шәригатьне тергезмәк өчен вә дин ислам-ны бакый кылмак өчен дип, ният итеп гыйлем үгрәнмәгә иҗтиһад кыла күр», – дип, баланың үзе тырышырга тиешлегенә өстенлек бирелә, ягъни «Әхлак рисаләсе»нең Сәнгатьчә Илаһи / Рухани / Инсани әдәбият стилендә язылуы мәгълүм була. Хезмәттәге төп фикерләре галимнең: «Балаларны тәрбия кыйлмак вә тәрбия итмәк дигән сүз фәкать ашатып-эчертеп үстермәк мәгънәсендә генә түгелдер, бәлки ашатып-эчертеп үстермәк, вә баланың холкын, фигылен ислах кыйлмак вә төзәтмәк, вә, хайванидан чыгарып, инсаният дәрәҗәсенә китермәк, вә тәгълим бирмәк, вә үгрәтмәк, вә укытмак, вә әдәбе әркян (нигез) бирмәк мәгънәсендәдер. Ошбу рисаләдә зикер кыйлыначак хикәятләр, вәгазьләр вә нәсыйхәтләр һәммәсе, вә бу рисаләнең һәрбер кәлимәсе – бер тәрбиядер, шул җәһәттән “Тәрбия китабы” дип ат бирдек», – дип, 112 бүлекчәле «Китаб-әт-тәрбия» дә, Аллаһы Тәгаләнең хөкеме, аксакаллардан, Локман хәким, падишаһлардан, Искәндәр Руми, шәехләрдән, олуглардан нәсыйхәт бирелә [22: 128–151]. Димәк, «Китаб-әт-тәрбия» әсәренең дә, Сәнгатьчә Илаһи / Рухани / Инсани әдәбият стилендә язылуы аңлашыла. Шулай итеп, К. Насыйри, катлаулы ижади эшчәнлеге белән, үз чоры әдәби телнең 7 (җиде) функциональ стилендә формалашуын исбат итә була. Илаһият тәгълиматы традициясе автор аңында эстетик кабул ителгән дөньяви чынбарлыкны Сәнгатьчә Илаһи / Рухани / Инсани әдәбият стилендә сәнгатьчә тасвирлануы нигезендә дәвам ителү белән бер үк вакытта, гакылга, фәнгә таянып, аерым фән тармагы өйрәнелеп язылган хезмәтләренең, үзләренә хас «тел»е булырга тиешлеге, ягъни гарәп телендәге истыйляхлар, татарча тәрҗемә ителеп, татар укучысы хозурына җиткерелә. Димәк, К. Насыйри – «основатель татарского литературного языка» дигәндә, энциклопедик галим, классик мәгърифәтче-педагог, колачлы ижади эшчәнлегендә, һәркайсының үзенә хас табигате һәм вазыйфасы булган җиде функциональ стильгә бүленү мөмкинлеген раслап, шул стильләрнең кулланылышы белән, үз чорындагы татар язма әдәби теленең, формалашуын билгели була. Бу юнәлештә, К. Насыйриның ижади эшчәнлегендәге әдәби телнең, XX гасыр уртасындагы әдәби телдән, үзенең кулланылу даирәсе ягыннан да, тел сурәтләү чараларын файдаланылуы ягыннан да күләмлерәк-колачлырак булуы ачык күренә. Алга таба, әлеге әсәрләрне, функциональ стиль, хосусый язма сөйләм,үзенчәлекле текст дип өйрәнү барганда, гомумтелнең сөйләм төзелеше тикшерелә торган синтаксис тармагына нигезләнеп, текст синтаксисы / синтаксик стилистика фәне категорияләре таләбе белән, һәр текстның тема / идеясе, кереш / башламы, теманың мәгънәви үзәге булган композиция төзелеше, сүз һәм сурәтләү чаралары сайланышы белән авторның мөнәсәбәте белдерелүенә, бетем / йомгаклауда тәмамлану үзенчәлегенә игътибар итәргә кирәк булуы күренә [15: 5–12; 450–466]. Иншалла, бу юнәлешне яшь галимнәребез дәвам итәрләр дигән өметтә калабыз.

ӘДӘБИЯТ

1. Ахманова О.С. Словарь лингвистических терминов. 1969. 606 с.

2. Әмирхан Ф. Әдәбиятка гаед // Әсәрләр: Дүрт томда. 4 т.: Әдәбият-сәнгать тәнкыйте, биографик материаллар, хатлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. Б. 67–73.

3. Бәширова И. Латыйф Җәләй – остаз, олуг педагог // Мәдәни җомга. 2025. № 13, 14, 15.

4. Вәлиди Ж. Әдәби тел барышы: беренче җөзьә. Оренбург: Вакыть, 1912. 122 б.

5. Гали М. К. Насыйриның кульязма мирасы // Каюм Насыйри. 1825–1945 (Тууына 120 ел тулуга башышланган гыйльми сессия материаллары). Казан, 1948. 127 б.

6. Гайнуллин М. Каюм Насыйри // Татар әдәбияты XIX йөз. Югары уку йортлары өчен. Казан: Таткнигоиздат, Укыту-педагогик әдәбият редакциясе, 1957. Б. 127–171.

7. Гайнуллин М. Каюм Насыйри // Татар әдәбияты тарихы: алты томда. 2 т. XIX йөз татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр, 1985. Б. 258–273.

8. Җәләй Л. Стилистика һәм әсәрнең композициясе.Тәрҗемәчеләр белән уку өчен бер курс. 1934. 36 б.; Стилистика һәм гомуми тел белеме буенча язмалар. 1935. 38 б. // ИЯЛИ. Мирасханә. Ф. 29, оп. 1, ед. хр. 4.

9. Җәләй Л. Практик стилистика алдында торган бурычлар // Мәгариф. 1935. № 11.

10. Җәләй Л. Тукай телендә фигыльләр // Совет әдәбияты. 1938. № 3, 4, 5.

11. Җәләй Л. Лекция. Кулъязма (1958–1959). Шәхси архивта саклана.

12. Җәләй Л. Татарларда мәгърифәтчелек хәрәкәте һәм Каюм Насыйри // Совет әдәбияты. 1945. № 2. Б. 37–44.

13. Зәйнуллин Ж.Г. XVIII йөз – XX йөз башында татар рухани әдәбияты (Коръән тәфсирләре, хәдисләр һ. б. чыганаклар. Тәрҗемә принциплары һәм тел үзенчәлекләре). Казан: Мәгариф, 1998. 207 б.

14. Закиев М.З. Каюм Насыри // Казанская лингвистическая школа: Книга первая: Казанская тюркская лингвистическая школа / сост. М.З. Закиев. Казань: Татар. кн. изд-во, 2008. 424 с.

15. Зәкиев М.З. Кереш. Сөйләм төзелеше системасы турындагы фән буларак синтаксис // Татар грамматикасы: өч томда. Т. 3. М.: Инсан; Казан: Фикер. Б. 5–12, 450–466.

16. Ибраһимов Г. Яңа татар әдәби теленең беренче баскычларында // Әсәрләр: сигез томда. 8 т. Төрки һәм татар тел белме буенча хезмәтләр (1910–1930) // Казан: Татар. кит. нәшр. 1987.

17. Ибраһимов Г. Татар телен тикшерү юлында (татар сарыфлары // Әсәрләр: сигез томда. Т. 8. Төрки һәм татар тел белме буенча хезмәтләр (1910–1930). Казан: Татар. кит. нәшр. 1987.

18. Ибраһимов Г. Каюм бабаның йөз еллыгы (1825–1925) // Әсәрләр: сигез томда. Т. 5. Казан: Татар. кит. нәшр.1978. 615 б.

19. Кононов А.Н. Из истории изучения тюркских языков в России. Дооктябрьский период // Библиографический словарь отечественных тюркологов. Дооктябрьский период. М.: Гл. ред. вост. лит., 1974. С. 9–90.

20. Кукляшев С. Татарская хрестоматия. Казань: Тип. Ун-та, 1859. 164 с.

21. Курбатов Х.Р. Атаклы галим, педагог һәм мәгърифәтче // Яшь сталинчы. 1955. 16 февр.

22. Насыйри К. Сайланма әсәрләр: ике томда. 1 т. Казан: Татар. кит. нәшр, 1974.

23. Насыйри К. Сайланма әсәрләр: ике томда. 2 т. Библиографик белешмә, революциягә кадәр басылып чыккан хезмәтләре. Казан: Татар. кит. нәшр, 1975. Б. 289–303.

24. Насыйри К. Кырык вәзир кыйссасы (1 басма). Казан: Ун-т тип., 1868. 163 б.

25. Насыйри К. «Әбүгалисина кыйссасы» димәклә мәшһүр тәхәйелнең тәрҗемәсе. Габделкаюм мелла Габделнасыйр углының тәрҗемәт вә таснифәтеннәндер (1 басма). Казан: Ун-т тип., 1881. 112 б.

26. Насыйри К. Кырык бакча. Мөстәтәруф сүзләре вә һәм галәмәи Зәмәхшариның рауза сы ыслубы вазәрә бакча тәсмия кыйлынды. Габделкаюм мелла Габделнасыйр углының мәҗмугасыннан. Казан: Перов литогр., 1880. 58 б.

27. Насыйри К. Җәваһирел хикәят вә әл-әсилә вә ләтаиф әр-риваять вә әл-әмсалә. Тәр җемәт мин китаби әнис әл-җәлис әл-имам әс-Сөети Рәхмәтулла. Мин мөәлләфат Габдел каюм ибн мелла Габделнасыйр әш-Шырдани. Казан: Ун-т тип., 1884. 139 б.

28. Насыйри К. Әфсәнаи Гөлрөх вә Камәржан.Чин падишаһының кызы Гөлрөх белән Хорезм шаһ углы Камәржанның мажарасыдыр ки... Казан: Ун-т тип., 1896. 54 б.

29. Насыйри К. Кыскача татар нәхүе. Татарча һәм урысча үгрәнүчеләргә файдалы гыйлем булсын өчен нәхү кагыйдәләрен бәян кыйлудан башка фәкать мисаллар үзәринә ихтисар кыйлынды. Казан: Ун-т тип., 1860. 77 б.

30. Насыйри К. Татарча-урысча лөгать китабы. Казан: Ун-т тип., Фәтхулла Хәмидулла Амашев нәшере, 1878. 120 б.

31. Насыйри К. Кавагыйде кыйраәт русия мәҗмугасы. Илле сабактыр, Ибтидан русча укырга үгрәтүче китапдыр. Әсәр Габделкаюм ән-Насыйри. Казан: Ун-т тип., 1889. 24 б.

32. Насыйри К. Рус хөрүф һиҗасе вазәрә мөрәттип лөгать китабы. Казан: Ун-т тип., 1892. 264 б.

33. Насыйри К. Кавагыйде китабәте, ягъни тасниф вә имля кагыйдәләрен бәян кыйлучы бер яңа фәндер. Габделкаюм Габделнасыйр углының истихрәтендин. Казан: Ун-т тип., 1892, 24 б.

34. Насыйри К. Ләһҗәи татари, татар телендә мәүҗүд булган әл-лөгать. Әүвәл җилд. Казан: Ун-т тип., 1895. 226 б.; Җилд сани. Казан: Ун-т тип., 1896. 106 б.

35. Насыйри К. Әнмүзәҗ. Казан: Ун-т тип., 1895, 87 б.; Казан, 1975. 208 с.

36. Насыйри К. Буш вакыт.– Казан: Казан: Ун-т тип., 1860. 12 б.; 1868. 87 б.

37. Насыйри К. Хисаплык, ягъни гыйлем хисап кагыйдәләре яки арифметика вә һәм хисаплык мәсъәләләре. Әүвәл мәртәбә(басыла) Габделкаюм Габделнасыйр углының таснифедер. Казан: Ун-т тип., 1873. 52 б.

38. Ысулы җәгърәфия кәбир. Азия кыйтгасы. Габделкаюм Габделнасыйр углының таснифләреннәндер. Казан: Ун-т тип., 1894. 206 б.

39. Насыйри К. Гөлзар вә чәмәнзар, ягъни үләнлек вә чәчәклек. Хавассы нәбатат бәянында бер китаптыр ки мәмләкәтемездә ике әҗзаханә сахиблары тасниф кыйлынмышдыр. Андан без тәрҗемә кыйлып интишарына сәгый кыйлдык Габделкаюм Габделнасыйр углы ән-Насыйри. Ошбу китапта мәзкүрың нәбататның русча вә һәм татарча исемнәре тәрҗемә кыйлынып 1887 елгы календарьда басылмыш иде. Казан: Ун-т тип., 1894. 112 б.

40. Насыйри К. Мәнафигъ әгъза вә кануны сыйххәт. Казан: Ун-т тип., 1893. 31 б.

41. Санаигъ голфания. Бер яңа фәндер ки, мәгъдәндән мәгъмуль нәрсәләрне шәһед тәрикъчә алтынламак, көмешләмәк вә кургашламак кебек гамәлләрне бәян кыйлыр. Габделкаюм Габделнасыйр углының әсар ижтиһадияләреннән. Казан: Ун-т тип., 1900. 29 б.

42. Насыйри К. Шәҗәрәи мөбәракән пәйгамбәр / К. Насыйри нәшере. 1860, 1 табак, басма табылмады.

43. Насыйри К. Гакаид рисаләсе. Габделкаюм мелла Габденнасыйр углының мөэлли фатеннәндер. Өченче мәртәбә басыла. Казан: Ун-т тип., 1896.

44. Насыйри К. Мохтәсар тәварих әнбия... Тәварих фәнендин гаять кирәкле вә әһле исламдан һәркемгә белмәкле лязим булган тәварих әҗмалыдыр. Ибтидаи тәварих фәнендин балаларга укытыр өчен тасниф кыйлынды могтәбәр тәварихи китаплардан / Бу китапны тасниф кыйлды Гаделкаюм Габденнасыйр углы. Казан: Ун-т тип., 1884. 78 б.

45. Насыйри К. Утыз вәгазь... Казан: Ун-т тип., Насыйри басмасы, 1888. 180 б.

46. Насыйри К. Әхлак рисаләсе. Казан: Ун-т тип., 1881. 32 б.

47. Насыйри К. Тәрбия китабы. Габделкаюм мелла Габденнасыйр углының таснифәтедер. Казан: Ун-т тип., 1891. 32 б.

48. Насыйри К. Мәҗмәгыль әхбар. Габделкаюм Габделнасыйр углы җәмигъ вә тәртип кыйлдым... Казан: Ун-т тип., 1895. 176 б.

49. Тенишев Э.Р. Принципы составления исторических грамматик и истории литературных языков // Советская тюркология. 1988. № 3. С. 67–78.

50. Хайрутдинов А.Г. Мифтах аль-кур’ан Каюма Насыри Ислам в современном мире. URL: https://islamjournal.idmedina.ru/jour/article/download/256/198

51. Языки мира: Тюркские языки. Бишкек, 1997. 544 с/

УДК 81`27

Биткеева Айса Николаевна
Института мировой литературы им. А.М. Горького РАН.
Москва, Россия
Bitkeeva Aysa Nikolaevna,
Gorky Institute of World Literature of the
Russian Academy of Sciences
Moscow, Russia
E-mail: an.bitkeeva@iling-ran.ru

МЕТОДОЛОГИЯ ЭКСПЕРТИЗЫ СОЦИАЛЬНОГО ВОЗДЕЙСТВИЯ НА ЯЗЫК И КУЛЬТУРУ: ОПЫТ ИССЛЕДОВАНИЯ СЕВЕРНЫХ ГОРОДОВ

METHODOLOGY OF ASSESSMENT OF SOCIAL IMPACT ON LANGUAGE AND CULTURE: THE CASE OF NORTHERN CITY

Аннотация. *Статья представляет методику оценки социального воздействия на язык и культуру, основанная на подходах социолингвистики. Инструментарий позволяет детально рассмотреть соотнесенность социокультурных факторов, являющихся ключевыми в формировании облика города – близость городского сообщества от природы, исторический, политический, экономический факторы, демографическая, коммуникативная и символическая мощности и языковой конкуренции или языковой монополии, языковых идеологий, языкового активизма в условиях Севера и др.*

Городская среда открывает новые возможности для межкультурного диалога и расширения языкового репертуара жителей Арктики, но в то же время создает риски языковой ассимиляции и утраты языков коренных народов. Сложные природно-климатические условия, отдаленность и неразвитость транспортной инфраструктуры существенно затрудняют проведение полевых исследований в арктических городах, что отражается на количестве и глубине имеющихся научных работ по данной проблематике.

Разработка универсальных показателей (индикаторов) языковой ситуации для оценки качества жизни позволяет интегрировать выработанные индикаторы не только при типологизации районов компактного проживания КМНС по потенциалу устойчивости системы жизнеобеспечения и этнической культуры, в оценках воздействия этнологической среды (этнологической экспертизы), но и в международную систему оценки благополучия населения Арктики, в т. ч. и в городском пространстве.

Источниками выступили материалы комплексного исследования языкового пространства в Анадыре, Якутске, Билибино в октябре 2023 г., Мирном и Билибино в мае – апреле 2024 г., с анкетированием около 800 информантов – горожан Якутска, Мирного, Анадыря, Билибино разных социальных групп и интервьюированием 41 чел. разных социальных групп населения в указанных городах.

Annotation. *The article presents a methodology for assessing the social impact on language and culture based on sociolinguistic approaches. The toolkit allows for a detailed examination of the correlation of sociocultural factors that are key in shaping the image of the city – the proximity of the urban community to nature, historical, political, economic factors, demographic, communicative and symbolic power, language rivalry or language monopoly, language ideologies, language activism in the North, etc.*

The urban environment opens up new opportunities for intercultural dialogue and expansion of the linguistic repertoire of Arctic residents, but at the same time creates risks of linguistic assimilation and loss of indigenous languages. Complex of nature and climatic conditions, remoteness and underdevelopment of transport infrastructure significantly complicate field research in Arctic cities. Arctic cities still rarely become the subject of special scientific analysis.

The working out of universal indicators of the language situation for assessing the quality of human well-being allows integrating these indicators not only in the typology of areas of compact residence of indigenous peoples of the North according to the potential for the sustainability of the life support system and ethnic culture, in assessing the impact of the ethnological environment (ethnological expertise), but also in the international system for assessing the well-being of the population of the Arctic.

The research is based on the materials of a field research of the language space in the industrial cities Anadyr, Yakutsk, Bilibino in October 2023 and Mirny and Bilibino in 2024. The survey covered 800 citizens and interviewing 41 people of different social groups of the population of the mentioned cities.

Ключевые слова: *языки России, языковая ситуация, языковая политика, языковое пространство промышленного города, социальное воздействие на язык и культуру, арктические индикаторы, северный город*

Keywords: *languages of Russia, language situation, language policy, linguistic space of an industrial city, social impact on language and culture, arctic indicators, northern city*

Введение. Необходимость поиска баланса между урбанизацией, индустриализацией, модернизацией и сохранением культурно-языкового наследия, обеспечения устойчивого развития арктических сообществ в условиях стремительных социокультурных изменений один из основных вызовов нашего времени. Городская среда открывает новые возможности для межкультурного диалога и расширения языкового репертуара жителей Арктики, но в то же время создает риски языковой ассимиляции и утраты языков коренных народов. Несмотря на растущий интерес исследователей к проблемам языкового взаимодействия в северных и арктических городах, многие вопросы, связанные с функционированием и развитием многоязычия в урбанизированной среде Крайнего Севера, остаются малоизученными. Северные и арктические города до сих пор редко становятся объектом гуманитарного научного анализа. Практикоориентированных исследований проблем северных и арктических регионов не гуманитарного плана больше, так, экологами, биологами и зоологами разработаны критерии и методики для проведения экологической экспертизы, которые позволяют точно оценить и выработать стратегии развития, направленные на минимизацию экологического ущерба при освоении территорий. Это привело к тому, что с 2011 г. в России началась практическая реализация закона об этнологических экспертизах.

Немаловажна роль языка как социального показателя благополучного развития человека в Арктике, однако, как оценить качественные изменения в языковом потенциале северных и арктических городов?

Ученые и общественность говорят об угрозе исчезновения языков и культур народов России. Сегодня почти все языки РФ находятся на разных стадиях языкового сдвига. Казалось бы, язык и культура величины аб-

страктные, однако, тоже поддающиеся количественному анализу. В статье представлена методика оценки социального воздействия на язык и культуру на основе комплекса показателей влияющих на языковую ситуацию.

Представленная методология экспертизы социального воздействия на язык и культур северного города разработана на основе экспертных исследований, включающих этнокультурные показатели: зарубежных практик оценки социального воздействия (Social Impact Assessment, SIA) и арктических социальных индикаторов (Arctic Social Indicators – ASI), отечественного опыта проведения Этнологической экспертизы. При разработке методологии учитывались этнокультурные показатели, представленные в рассматриваемых экспертных исследованиях.

Апробация модели экспертизы социального воздействия на язык и культуру проводилась на материале, полученном в ходе полевых исследований языкового пространства северных и арктических городов в Анадыре, Якутске, Билибино, Мирном Центром по национально-языковым отношениям Института языкознания РАН совместно с Центром арктических исследований Института гуманитарных исследований и проблем малочисленных народов Севера СО РАН в 2023–2024 гг. Исследование включило проведение масштабного анкетирования и интервьюирования разных социальных групп населения городов Республики Саха (Якутия) – Якутск, Мирный и Чукотского автономного округа – Анадырь, Билибино. В анкетировании приняли участие около 800 информантов, записано 41 интервью в указанных городах (Полевые материалы авторов 2023 г. – далее ПМА-2023); полевые материалы авторов 2024 г. – далее ПМА-2024).

Этнокультурная ситуация в Этнологической экспертизе. Одной из экспертиз, в рамках которых проводятся комплексные междисциплинарные исследования, является Этнологическая экспертиза (ЭЭ). Понятие Этнологической экспертизы появилось в российской правовой системе в 1999 г. в федеральном законе «О гарантиях прав коренных малочисленных народов Российской Федерации»: «этнологическая экспертиза – научное исследование влияния изменений исконной среды обитания малочисленных народов и социальнокультурной ситуации на развитие этноса» [1].

Феномен этнологической экспертизы находится на начальной стадии как в государственно-правового, так и научного осмысления. [2; 3; 4; 4; 5; 6].

Рассмотрим этнокультурные показатели, присутствующие в ЭЭ, проводимых в Республике Саха (Якутия), чье законодательство в отношении ЭЭ существенно опережает федеральное.

Социально-культурная ситуация в зоне влияния планируемой и прогнозируемой хозяйственной и иной деятельности анализируется в отдельном разделе «Характеристика этнокультурного и социально-экономического развития малочисленных народов, в том числе медико-демографической, этносоциологической оценки населения». В данном разделе приводятся следующие этнокультурные показатели этнологического мониторинга:

– характеристика языковой ситуации, функционирование родного языка (социальная языковая ситуация (количество хранителей и носителей); владение родным языком (признание языка родным); наличие литературы, СМИ, географических и административных названий на этнических

языках, использование этнической символики в языковом ландшафте поселений, в оформлении административных зданий);

– преподавание родного языка и культуры в образовательных учреждениях: официальный статус школы (родной); количество часов родного языка и культуры; учебники, рабочие тетради, словари, справочники по родному языку и культуре; наличие преподавателей родного языка и культуры; экзамены по родному языку и культуре;

– характеристика культурного центра (включая местные музеи и библиотеки) по сохранению и развитию родного языка и культуры (наличие фольклорных ансамблей, сувенирных мастерских, обеспечение права на традиционные промыслы и фольклор; вклад общественных организаций в сохранение и развитие родного языка и культуры;

– описание мест историко-культурного наследия.

В виду того, что ЭЭ в основном проводятся в местах традиционного проживания и традиционной хозяйственной деятельности коренных малочисленных народов Севера (КМНС), представленных в основном сельскими поселениями, мы решили апробировать этнологическую экспертизу на материале северных городов, где наиболее контрастно высвечивается взаимосвязь и взаимозависимость вопросов недродобывающих компаний и коренных народов, состояние их традиционной среды обитания, культуры и языка. Полагаем, что методика ЭЭ должна быть полимасштабна – федеральный уровень (когда рассматривается вся страна), региональный уровень (когда изучается регион и/или смежные регионы), территория муниципального образования (когда, рассматривается один район), поселенный уровень (когда рассматриваются отдельный город и/или сельский населенный пункт).

Разработка универсальных показателей (индикаторов) языковой ситуации для оценки качества жизни позволит интегрировать выработанные индикаторы не только при типологизации районов компактного проживания КМНС по потенциалу устойчивости системы жизнеобеспечения и этнической культуры, в оценках воздействия этнологической среды (этнологической экспертизы), но и в международную систему оценки благополучия населения Арктики, в т. ч. и в городском пространстве.

Существующие подходы к оценке жизнеспособности языков, такие как методология ЮНЕСКО и факторы, выделенные А.Е. Кибриком, предоставляют ценную основу для понимания текущего состояния языкового разнообразия. Они позволяют выявить языки, находящиеся под угрозой исчезновения, и определить ключевые факторы, влияющие на их выживание. При разработке показателей витальности языка учитываются в первую очередь языковые данные (наличие межпоколенной передачи, коммуникативная мощность и др.), социальные параметры (демографическая мощность, способ расселения группы и др.). Однако, как мы полагаем, в современных условиях для более точной оценки необходимо учитывать расширенный спектр параметров. В быстро меняющемся мире, где социально-экономические факторы играют все более важную роль, необходимо включать в анализ экономические аспекты, связь сообщества с природой, исторический контекст, идеологические установки и др. Игнорирование этих факторов может привести к неполной или даже ошибочной оценке

витальности языка, упуская из виду важные движущие силы, влияющие на его развитие или упадок.

В частности, развитие арктических регионов представляет собой яркий пример того, как экономические и социальные изменения могут оказывать глубокое воздействие на языки коренных народов. Дальнейшие исследования и разработки в области оценки жизнеспособности языков должны учитывать эти сложные взаимосвязи, стремясь к созданию комплексного и полимасштабного анализа, способного отразить реальную картину языкового ландшафта и обеспечить основу для эффективных мер по сохранению языкового и культурного наследия. Это особенно очевидно на примере развития северных и арктических регионов, об этом речь пойдет далее.

Эксперты и сами носители языков считают, что система оценки этнокультурного и языкового ущерба необходима. В.И. Шадрин вице-президент Ассоциации коренных малочисленных народов Севера Республики Саха Якутия в интервью отмечает, что на сегодня полностью отсутствует методика расчета ущерба этнокультурным процессам, хотя с 2011 г. началась практическая реализация закона об этнологических экспертизах (ПМА-2024).

В сборнике нормативных правовых актов и в аналитическом материале «Этнологическая экспертиза в России» под редакцией А.И. Горбуновой, отмечается, что «существующие методики расчета убытков (ЭЭ – от авт.) построены на принципе доказывания валового дохода и не отражают весь комплекс взаимосвязанных потерь для традиционной экономики, сохранения языковой среды и т. д.» [7: 36]. Действительно, необходимым результатом научного изыскания по итогам экспертизы следовало бы считать разработку и внедрение системы мер, ориентированных на поддержание традиционного уклада жизни и хозяйствования, сохранение языков и культуры коренных малочисленных народов, а также создание рабочих мест как в традиционных, так и в новых отраслях, чтобы компенсировать утерянные объемы промыслов, что, в свою очередь, благоприятно сказывается на языковой среде. При этом, достижение обозначенного результата определяется не только качеством самой этнологической экспертизы как таковой, но и, в равной степени, социальной ответственностью и политикой компании [7: 37]. Проблемы языковой среды коренных сообществ остаются вне этнологической экспертизы, хотя как инструмент реализации государственной национальной политики Российской Федерации, должны быть учтены и включены в рамках этнологической экспертизы. Назрела необходимость разработки комплексной оценки социального воздействия на язык и культуру. При этом мы должны понимать, что языковая комфортность напрямую зависит от социально-экономического развития локуса, которое приводит в итоге неизбежно к культурному многообразию и возможно развитию гибридных форм культур или унификации локальных сообществ, где доминирует один язык, малые языки «страдают» в результате роста числа населения, трудовой миграции, промышленного освоения и т. д. [8; 9].

Соответственно, можно говорить о том, что гуманитарная проблематика оценивания этнокультурных и языковых ситуаций недостаточно разработана в отличии от социально-экономического развития арктических территорий. Учитывая, что язык является основой культуры и самоидентификации народа, его сохранение и развитие должно стать одним из приоритетов

в стратегии развития Арктической зоны России. Для обеспечения языковой комфортности жителей городских поселений необходимо проводить соответствующие мероприятия, включая поддержку и развитие национальных языков, обеспечение доступа к образованию на родном языке, создание условий для использования языка на рабочих местах и в повседневной жизни и др.

Методология экспертизы социального воздействия на язык и культуру. В предыдущих публикациях нами подробно рассматривался комплекс методов, позволяющих системно подойти к исследованию языковой ситуации городского пространства посредством оценивания языковой комфортности [10].

Разработка комплексной оценки языковой комфортности базируется на ряде ключевых положений, которые определили метод расчета и источников данных. Во-первых, комплексная оценка должна быть применима к любому территориальному объединению, а не только отдельным категориям, выделенным по численности сообщества или территориально-административному статусу. Во-вторых, предполагается возможность отслеживания динамики и адаптации оценки к изменениям, происходящим в каждом конкретном территориальном объединении. В-третьих, используемые индикаторы должны быть общедоступны, открыты и применимы для качественного и количественного выражения комплексного анализа.

Полагаем, основой языковой экспертизы могут послужить многофакторная модель прогнозирования развития языков, разработанная нами [8] и индикаторы оценки языковой комфортности предлагаемой нами ранее [9].

Предлагаем усовершенствовать данную модель в части этнокультурных показателей (ЭП) и дать оценку этноязыковой ситуации (ЭС). Оценка этноязыковой ситуации проводится с учетом всех факторов, детализирована в части определения оценочных факторов и суммирования их количественных и качественных показателей и определялась по формуле:

ЭС = (ПУ+ИК+ПиИА+ДМ+СЭК+КМ+СМ+ЭП) + УС, где ЭС – этноязыковая ситуация, **ПУ** – природные условия, **ИК –** исторический контекст, **ПиИА –** политический и идеологический аспект, **ДМ –** демографическая мощность, **СЭК** – социально-экономический контекст, **КМ** – коммуникативная мощность, **СМ** – символическая мощность, **ЭП** – этнокультурные показатели, **УС** – управление судьбой.

Шагыйрьләр иҗатында, чәчмә әсәрләрдән аермалы буларак, поэзиядә саналып бирелә торган тиңдәш кисәкләр азрак һәм аларны җыеп бирүдә ярдәмче сүзләр кулланылмый диярлек, автор, нигездә, санау интонациясеннән файдалана: *Қош-қорт, хәйван-хәшарәт* / *Хақға қылыр ғыйбадәт* [Мәүлә Колый, 2001, б. 60]. *Хытай, қыпчак, Йәсәви, Сәуран әүладлары,* / *Табты, Болғар, Кирмән, Казан фәрзандлары, – Булыр, барча, пиремезнең мөридәләре,* / *Пирем уғлы Мәхзүмиҗән, хәзрәт ишан* [4: 37].

Тиңдәш кисәкле җөмләләр шигырь юлларына сөйгән ярның, кыз баланың гүзәллеген, күңел матурлыгын тасвирлау, ягъни портретка характеристика бирү максатыннан килеп керергә мөмкин: *Мәдех әйләделәр һәзар кямалең:* / *Каму шиwәлегең, күркәм җәмалың* [1: 60].

Язма истәлекләрдә тиңдәш кисәкләр градация кебек стилистик чара барлыкка китерүдә аеруча актив катнаша. Мәгълүм булганча, градация образлылык тудыра торган төп стилистик алымнарның берсе булып санала. Мәсәлән, түбәндәге очракта автор градация алымын персонажның хис-кичерешләрен тулырак, тәэсирлерәк күрсәтү өчен файдалана. Аеруча романтик рухта язылган «Мәҗмугыль хикәят» әсәрендә бу алым хисләр үсешен тиңдәш фигыльләр ярдәмендә аеруча куертып, эмоциональ яктан баетып-көчәйтеп тасвирлый: *Падишаһзадә атасидин бу җавапны ишетеб, бисийәр пәришан булды, күңеле ғәмгә тулды, хатыре мәлүл булды* [3: 513]. *Шаһзадә аны күреп йөз-мең җан-дил берлә ғашыйқ булды, аһ орды, ул заман ғақыйлдин китеп торды* [3: 514].

Габдерәхим Утыз Имәни иҗатында тиңдәш кисәкләр, башка төр сурәтләү чаралары белән үрелеп, градация алымын барлыка китереп, шагыйрьнең әйтергә теләгән фикерен, үгет-нәсихәтен эмоциональ яктан көчәйтеп тасвирлый. Мәсәлән, түбәндәге мисалда надан кешегә бер генә акыллы сүз дә, изге гадәт тә, Коръән сүзләре дә, пәйгамбәр хәдисләре дә үтеп кермәвен автор шактый үтемле, образы итеп тиңдәш кисәкләр ярдәмендә җиткерә: *Аңа нәфғ итмәйә һичбер ғыйбарәт,* / *Әгәрчә сәмғ идәр йөз-мең бәшарәт,* / *Уқырсың сәмғынә Тәүрат wә Инҗил,* / *Бәраһинә дәлил Қоръән wә Тәнзи,* / *Әхадисе нәбидин чуқ ғәрәиб* / *Мәғәниләр ғәрәисын араиб, Тықарсың сәмғыйнә йакути әсрар,* / *Дәхи диярсең аңа әхләқый әбрар,* / *Нәғяһ итмәз сәнең ширин сүзиңә,* / *Хәқарәт әйләйур бәлки үзиңә* [7: 36] h. б.

Мәүлә Колыйның фәлсәфи-шигъри фикерләрен җиткергәндә исә тиңдәш кисәкләрдән торган тасвир чаралары тагын да куертыла төшә, кабатлаулар белән бергә килеп, градация төсен ала. Үзара тиңдәшләнеп

килгән сүзләр генә түгел, сүзтезмәләр, тезмә җөмләләр дә градация алымы барлыкка китерүдә катнаша. Мәсәлән, шагыйрь фикеренчә, сабыр иткәннәр дәва таба, хәтта аларның күрмәс күзләре күрә башлый, алай гына да түгел, сабыр кеше дәүләт иясе булу дәрәҗәсенә үк ирешә: *Сабыр берлә Әйүп тапты сиххәт үзен,* / *Сабыр берлә Йакуп ачты күрмәс күзен.* / *Сабыр берлә Йосыф тапты дәүләт йөзен,* / *Сабыр сүзен телдин җөда итсә булмас* [4: 19]. Түбәндәге мисалда градация лирик геройның күңелендә ташыган мәхәббәт-сөю хисләре җиткерү өчен кулланыла: *Мәхәббәт ғыйшқы берлә күңеле ташса,* / *Ғыйшықъ уты илә көйеп, йанып, қайнап пешсә,* / *Җәзебә улып, үзен белмәй җандин кичсә,* / *Хақ зекерен әйтмәлектә ағзы талмас* [4: 100].

Шул рәвешчә, XVII–XVIII гасырлар иске татар язма чыганакларында вакыйгаларны, яки вакыйгалар бара торган урынны, табигать күренешләрен тулырак тасвирлау, теге яки тарихи шәхес, персонаж хакында киңрәк мәгълүмат бирү, лирик геройның хис-кичерешләрен, дөньяга карашын тулырак чагылдыру максатыннан, авторлар тиңдәш кисәкләр аеруча мул кулланыла. Әлеге синтаксик чаралар язма текстларны төзек, ятышлы, аһәңле итүдә, тезмә әсәрләрдә ритмик камиллек барлыка китерүдә зур роль уйный. Бигрәк тә, ялгызлык исемнәр, исем сүз төркеменә караган сүзләрнең үзара тиңдәш булып килүе, аларны берләштерүдә *берлә, wә* кебек бәйләүче чараларның актив булуы шушы чор әсәрләренә хас стилистик үзенчәлекләрнең берсе булып тора.

ӘДӘБИЯТ

1. Габдессәлам // XVIII гасыр әдәбияты. Поэзия. Казан: Дом печати, 2006. Б. 41–73.

2. Дәфтәре Чыңгызнамә // Мирастан биш сәхифә: XVII–XIX гасырлар әдәбитарихи ядкярләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. Б. 37–96.

3. Мәҗмүгъ әл-хикәят // Борынгы татар әдәбияты. Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. Б. 503–522.

4. Мәүлә Колый Хикмәтләр. Казан: Иман, 2001. 135 б.

5. Мөслими Тәварихы Болгария / басмага әзерл. С. Гыйләҗетдинов. Казан: Иман, 1999. 100 б.

6. Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. һәм автор М.З. Зәкиев. Тулыл. 2 нче басма. Казан: ТәһСИ, 2017. III т. 536 б.

7. Утыз Имәни әл-Болгари Шигырьләр, поэмалар / төз. Ә. Шәрипов. Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. 397 б.

УДК 811.521

Волкова Елена Викторовна
Санкт-Петербургский Гуманитарный университет профсоюзов
Санкт-Петербург, Россия
Volkova Elena Viktorovna
St. Petersburg University of the Humanities and Social Sciences
Saint-Petersburg, Russia
E-mail: fujivara_isae@mail.ru

АКТУАЛИЗАЦИЯ КОНЦЕПТА «ВОЙНА» В ПОЭЗИИ М.И. ЦВЕТАЕВОЙ И ЕЕ ПЕРЕВОДЕ НА АНГЛИЙСКИЙ ЯЗЫК Р. КЕМБАЛЛОМ

ACTUALIZATION OF THE CONCEPT "WAR" IN MARINA TSVETAEVA'S POETRY AND IN ITS TRANSLATION INTO ENGLISH BY R. KEMBALL

Аннотация. *Художественный перевод является одной из форм межкультурной коммуникации и средством для продвижения культуры на мировой арене. Целью статьи является описание языковых средств актуализации концепта ВОЙНА как элемента индивидуально-авторской картины мира в сборниках М.И. Цветаевой «Версты I» и «Лебединый стан», а также сопоставление их с вариантами перевода Робина Кембалла на английский язык. Особое внимание уделяется описанию когнитивных признаков концепта.*

Annotation. *Literary translation is a form of intercultural communication and a means of promoting culture on the global stage. The purpose of this article is to describe the linguistic means of actualizing the concept of WAR as an element of the individual author's worldview in Marina Tsvetaeva's collections "Versty I" and "Lebediny Stan," and to compare them with Robin Kemball's translations into English. Special attention is given to the description of the cognitive features of the concept.*

Ключевые слова: *картина мира; М.И. Цветаева; когнитивные признаки; индивидуально-авторский концепт; художественный перевод*

Keywords*: worldview; Marina Tsvetaeva; cognitive features; individual author's concept; literary translation*

Чтобы понять автора, его тексты (и адекватно перевести) нужно идти от основ его мировидения. Картина мира – источник того, как поступает человек, что он пишет и как оценивает происходящее в мире. Именно картина мира автора определяет те смыслы, которые закладываются в текст. Именно ее он и хочет (не всегда осознанно) передать читателю, потому что все идеи, оценки, чувства автора зиждутся на том, как он видит этот мир. Картина мира – междисциплинарное понятие, в определении которого нет единства, поскольку «это не объективно существующая реалия, а умозрительное построение, используемое его создателями для решения каких-либо теоретических или практических задач» [5: 4]. Тем не менее, хоть и только в сознании человека, картина мира существует и в современном мире становится объектом когнитивных исследований. Во многих источниках из области языкознания автором термина «картина мира» назван немецкий филолог и философ В. фон Гумбольдт (1767–1835). В его

понимании картина мира представляет собой «образ мира, полуосознанное или осознанное представление, являющееся результатом всей деятельности человека, его контактов с окружающей средой» [4: 151]. Данное исследование опирается на понимание картины мира как культурно детерминированного представления человека об устройстве мира и своем месте в нем, включающего, в том числе, и оценочный компонент, основанный на морально-нравственных и ценностных установках. Элементом картины мира является концепт.

Концепт определяют как «единицу ментальных или психических ресурсов нашего сознания; оперативную содержательную единицу памяти, ментального лексикона, концептуальной системы и языка мозга (lingua mentalis), всей картины мира, отраженной в человеческой психике» [6: 90]. Исследовать концепты можно только через их вербальную актуализацию, при этом говоря о художественном тексте, необходимо иметь в виду именно художественный, индивидуально-авторский концепт. С.А. Аскольдов художественные концепты определял «точками сложнейших соцветий мысленных конкретностей», «сростками возможных образных формирований, определяемых семантикой художественного слова» [2: 267]. В когнитивной лингвистике под содержанием концепта принято понимать набор когнитивных признаков, которые распознаются через смыслы и значения языковых единиц, вербализующих данный концепт [1: 701]. Индивидуально-авторский художественный концепт может быть исследован путем применения метода контекстного анализа на материале созданных автором художественных текстов. При этом, поскольку концепта (и картина мира в целом) постоянно изменяются, развиваясь и обрастая новыми признаками с течением жизни человека, в каждом последующем созданном им тексте набор актуализированных когнитивных признаков будет меняться. Таким образом, целесообразно исследовать индивидуально-авторские концепты в диахроническом аспекте.

Концепт ВОЙНА актуализирован ещё в первых сборниках юной Марины Цветаевой, «Вечерний альбом» и «Волшебный фонарь». Там война предстает игрой, полной романтики, героизма и побед. Лирическая героиня мечтает отправиться на одну из исторических войн, чтобы проявить свою доблесть [3: 239]. Но полные тексты этих сборников никогда не были переведены на английский язык. Можно найти переводы только отдельных стихотворений. Тем не менее, ценность первых сборников Цветаевой именно в их целостности, и их необходимо перевести полностью, чтобы читатель мог прочесть их как дневник. Британец Робин Кембалл перевел на английский язык две книги М.И. Цветаевой – «Версты I» и «Лебединый стан», написанные во время Первой мировой и Гражданской войн. Тексты этих сборников и их переводов послужили материалом данного исследования.

Обратимся к тексту сборника «Версты I». Первая мировая война, которая шла во время его написания, хоть и не часто (внутренняя жизнь Цветаевой превалировала над внешней), но все же прорывается в тексты стихотворений отдельными возгласами: «Ох, как в ночи́ страшен / Рев молодых солдат!» [8: 269], «Ох, и поют же / Нынче солдаты! О Господи Боже ты мой!» [8: 311]. Солдаты издают «рев зверский» [8: 270], «жалобный, жа-

лостный, каторжный вой» [8: 311]. В «Стихах к Блоку» встречается мотив разговоров о войне: «И толк о немце, доколе не надоест» [8: 293]. Отношение Цветаевой к войне, желание ее прекращения проявляется также в строке «…я целую в грудь / Всю круглую воюющую землю!» [8: 284]. Наиболее часто встречающаяся номинация, составляющая ближнюю периферию номинативного поля рассматриваемого концепта, – «солдаты». Прослеживается мотив войны как посланного кем-то (Господом или колдуньей) наказания. Были выведены следующие когнитивные признаки концепта как элемента индивидуально-авторской картины мира М.И. Цветаевой, актуализированной в сборнике «Версты I»:

• ВОЙНА – несправедливое наказание свыше;
• ВОЙНА – горе для людей;
• ВОЙНА – разговоры о ней;
• ВОЙНА – смерть;
• ВОЙНА – солдаты.

Р. Кембалл в своих переводах придерживается стратегии форенизации, т. е. старается сохранить своеобразие оригинала и передать содержание как можно точнее, сохранив при этом форму. Сохранение формы оригинального произведения, однако, зачастую ведет к некоторым смысловым потерям. Концепт WAR актуализирован в тексте перевода прежде всего через номинацию «soldiers». Рев, который в оригинале встречается несколько раз, помимо варианта roar переведен еще и как «shouting», и, таким образом, переходит в дальнюю периферию, меняя наполнение концепта. «Вой» также получил два варианта перевода – «wailing» и «cry» – что несколько меняет звуковую картину жизни в Москве в военное время, переданную Мариной Цветаевой. Переводчик сохраняет отсылки к историческим военным событиям – Наполеону и истории о том, как гуси спасли Рим от нашествия галлов, а также передает идеи автора о войне как результате гнева Господня, наказания и горя.

Наиболее часто встречающаяся номинация, вербализующая концепт ВОЙНА в сборнике «Лебединый стан», написанном во время Гражданской войны, – «Дон». Затем – «солдаты», «Белая гвардия», белый и красный цвета. Это война за Отчизну, за Родину, за Бога. Гражданская война показана глазами человека, живущего в большевистской Москве, ведь Белая армия – далеко, на Дону. Поэтому не раз в тексте возникают красные знамена: это то, что постоянно видела Марина Цветаева в Москве. В рассматриваемом сборнике концепт ВОЙНА тесно переплетен в своем вербальном выражении с концептом РЕВОЛЮЦИЯ, так как именно она послужила причиной этой войны.

Теперь это совсем другая война, не та, что была в первых книгах поэта, она не состоит из побед. Появился мотив обреченности, здесь убивают и хоронят. В то же время, это война священная, на ней «принимали муки» [8: 391]. В первых сборниках война романтизировалась, говорилось о рыцарстве, но прямо не указывалось на то, что это дело чести, верность тому, кому присягнули. В сборнике «Лебединый стан» на это есть множество указаний, добровольчество на Дону ставится автором в один ряд с Вандеей. И эта война идёт внутри страны («Повеяло Бонапартом / В моей

стране» [8: 350]). Имена собственные, встречающиеся в сборнике и вербализующие концепт ВОЙНА, следующие: Бонапарт, бог Марс, Корнилов, Дон, Россия, Крым, Перекоп, Князь Игорь, Ярославна. К гражданской войне отсылают также упоминания Лжедмитрия / Гришки Отрепьева. Но здесь же в тексте присутствует и множество военных атрибутов – мундиры, погоны, оружие, награды и.т. п.

Важнейшей особенностью сборника «Лебединый стан» является образ мужа Цветаевой, Сергея Эфрона, присутствующий на его страницах в таких номинациях, как «Воин», «Ангел», «белый лебедь», «папа» и др. Эта война сопряжена с неизвестностью о судьбе дорогого человека, а еще она – за сохранение того, что было и как было. Война за дом, который нужно беречь и защищать, и за Бога, которого запрещают. Цветаева не может смириться с тем, что уходит привычная эпоха. В сборнике «Лебединый стан» представлены следующие когнитивные признаки индивидуально-авторского концепта ВОЙНА:

- ВОЙНА – дело чести, долг;
- ВОЙНА – гражданская;
- ВОЙНА – солдаты, люди;
- ВОЙНА – красное и белое;
- ВОЙНА – поражения и крах;
- ВОЙНА – судьба мужа;
- ВОЙНА – ее атрибуты;
- ВОЙНА – смерть.

Р. Кембалл, следуя за текстом оригинала, использует номинации «the Don» и «soldiers», помещая их в ближнюю периферию номинативного поля концепта WAR. Следующей по частотности номинацией является «the White Guard». «White» всегда используется как эквивалент белого у Цветаевой, а вот «красный» переведен тремя вариантами: «scarlet», «crimson» и «red». Получается, цвета знамен разнятся, частотность употребления номинаций снижается, они уходят в дальнюю периферию, хотя, как уже было сказано, красный цвет окружает автора в Москве тех лет.

Переводчик использует вариант «It is over, / The White Crusade» [7: 357], говоря о «Белом походе», приравняв, таки образом, его к походу крестовому, чего Цветаева напрямую не делает. В тексте перевода встречаются и другие неточности, меняющие картину, нарисованную словом автора. Например, «погоны» в разных случаях переведены как «insignia» или «epaulets», и оба раза перевод неверен. Более того, эполеты, являющиеся украшением, не могут быть на плечах воюющих и умирающих за честь и долг. Также в тексте перевода было опущено слово «народы», что привело к исчезновению такого когнитивного признака исследуемого концепта, как участие в войне народов, народная война. Все эти изменения незаметны на первый взгляд, но, аккумулируясь, они меняют когнитивные признаки концепта, что ведет к неверной передаче индивидуально-авторской картины мира и искаженному представлению о ней читателя. Решение проблемы видится в тщательном когнитивном анализе оригинального текста переводчиком. Именно такой анализ позволит ему решить, какие средства актуализации важнейших индивидуально-авторских концептов необходимо использовать при переводе.

ЛИТЕРАТУРА

1. Абрамова Е.К. Когнитивная интерпретация как метод выявления признаков концепта // Известия Самарского научного центра Российской академии наук. 2009. Т. 11. № 4-3. С. 700–704.

2. Аскольдов С.А. Концепт и слово // Русская словесность: От теории словесности к структуре текста: Антология. М.: Academia, 1997. С. 267–279.

3. Волкова Е.В. Вербализация концепта ВОЙНА в поэзии М.И. Цветаевой: диахронический аспект // Материалы XXI и XXII международных научных цветаевских конференций (22–24 сентября 2018 г., 26–27 сентября 2020 г., Королев – Москва): Сб. докл. М.: Дом-музей Марины Цветаевой, 2021. С. 235–244.

4. Жукова И.Н. Словарь терминов межкультурной коммуникации / И.Н. Жукова, М.Г. Лебедько, З.Г. Прошина, Н.Г. Юзефович; под ред. М.Г. Лебедько и З.Г. Прошиной. М.: ФЛИНТА: Наука, 2013. 632 с.

5. Корнилов О.А. Языковые картины мира как производные национальных менталитетов. 2-е изд., испр. и доп. М.: ЧеРо, 2003. 349 с.

6. Кубрякова Е.С. Краткий словарь когнитивных терминов / Е.С. Кубрякова, В.З. Демьянков, Ю.Г. Панкрац, Л.Г. Лузина; под общ. ред. Е.С. Кубряковой. М.: МГУ им. М.В. Ломоносова, 1997. 197 с.

7. Цветаева М.И. «Серебряно мне – петь…»: «Версты» и «Лебединый стан» в переводах Робина Кембелла = «In Silvery Tones I'm to Sing…»: «Milestones» and «The Demesne of the Swans» translated by Robin Kemball. М.: Вагриус, 2008. 368 с.

8. Цветаева М.И. Собрание сочинений: в 7 т. Т. 1: Стихотворения / сост., подгот. текста и коммент. А. Саакянц и Л. Мнухина. М.: Эллис Лак, 1994. 640 с.

УДК 811.512.145

Галимбикова Илзирә Илгизәр кызы
Казан федераль университеты
Казан, Россия
Галимбикова Ильзира Ильгизаровна
Казанский федеральный университет
Казань, Россия
Galimbikova Ilzira Ilgizarovna
Kazan Federal University
Kazan, Russia
E-mail: ilzira.galimbikova@mail.ru

«ИДЕЛ» ЖУРНАЛЫНДА ЯҢА ЛЕКСИК БЕРӘМЛЕКЛӘР: ЛИНГВИСТИК АСПЕКТ

НОВЫЕ ЛЕКСИЧЕСКИЕ ЕДИНИЦЫ В ЖУРНАЛЕ «ИДЕЛ»: ЛИНГВИСТИЧЕСКИЙ АСПЕКТ

NEW LEXICAL UNITS IN THE "IDEL" MAGAZINE: A LINGUISTIC ASPECT

Аннотация. *Статья посвящена исследованию современного состояния лексического состава татарского языка. Рассматриваются ключевые факторы, определяющие принадлежность слова к разряду литературных единиц. Анализируются слова, недавно вошедшие в разряд литературных, а также активно используемые в речи, но пока официально не признанные в качестве литератур-*

ных элементов. Подчеркивается важность изучения процессов формирования и развития литературной нормы в условиях динамичного изменения языковой среды.

Annotation. *The article is devoted to the study of the current state of the lexical composition of the Tatar language. The key factors that determine a word's classification as a literary unit are examined. Words that have recently entered the literary category, as well as those that are actively used in speech but have not yet been officially recognized as literary elements, are analyzed. The importance of studying the processes of formation and development of the literary norm in a dynamic changing linguistic environment is emphasized.*

Ключевые слова: *журнал «Идел», лексика, активное употребление, литературное слово, лексический состав, заимствования*

Keywords: *Idel Magazine, vocabulary, active use, a literary word, lexical structure, borrowings*

«Идел» журналы татар яшьләре өчен дистә еллар дәвамында чыгучы периодик басмаларның берсе булып санала. Әлеге журнал үзенең кыйбласыннан тайпылмыйча, бүгенге көнгә кадәр нәкъ менә татар яшьләре өчен хезмәт куя.

XX гасырда, журнал тәүге адымын ясау өчен зур көрәш барган чорда, әлеге журналның язучылары да, укучылары да шактый булган дигән фикер белән килешмәү мөмкин түгел. Биредә яшьләр өчен кызыклы булган темалар, көн кадагындагы проблемалар күтәрелгән, шунлыктан әлеге журнал үз популярлыгын югалтмаган [1: 259]. Ә бүгенге, XXI гасыр яшьләрен, татар басма матбугаты белән кызыксындыру өчен бик күп көч куярга кирәк. Билгеле, бүгенге көндә «Идел» журналын басма матбугат чарасы гына дип карау дөрес булмас, төрле социаль челтәрләрдә үз эшчәнлеген алып баруы, әлбәттә, яшьләрне күбрәк җәлеп итәргә ярдәм итә. Ничек кенә булмасын, тел яшәсен өчен ул яшьләр тарафыннан кулланырга тиеш, ә «Идел» журналы моңа бер яссылык булып тора.

Билгеле булганча, телнең сүзлек составы һәрдаим үзгәрә, шул исәптән тулылана. Татар лексикасын өрәнүгә караган хезмәтләр XX гасырның 30–40 нчы елларында басылып чыга башлый һәм биредә тикшерүнең төп чыганагы булып, дастаннар, әсәрләр хезмәт итә [2: 15]. Бүгенге көндә дә татар теленең лексик составын өйрәнүдә татар әдәбиятының ядкярләре зур роль уйнаса да, халыкның җанлы сөйләм телендә кулланган берәмлекләр телнең сүзлек составын өйрәнгәндә әһәмиятле роль уйныйлар. Нәкъ менә алар татар теленең бүгенге көндәге хәлен ачыкларга ярдәм итәләр.

Тарихи-мәдәни процесслар барышында халыкның мәдәниятендә һәм тарихында булган үзгәрешләр чагыла. Мисал өчен тарихи вакыйгалар еш кына алынмалар барлыкка килүгә, сүзләрнең мәгънәләре үзгәрүгә йогынты ясый [3: 9]. 2022 елда башланган тарихи вакыйга телебездә яңа термин барлыкка китерде «махсус хәрби операция», шулай ук 1934 елда инглиз телендә кулланыла башлаган «дрон» төшенчәсе сонгы вакыйгаларга бәйле бүгенге көндә безнең телебездә дә актив кулланыла. 2019 елда бөтендөньяда таралган COVID-19 пандемиясе телгә «ковид» төшенчәсен кертеп җибәрә, элек сирәк кулланылган «QR-код» төшенчәсен актив рәвештә халык теленә

тарата, ә бүгенге көндә әлеге төшенчә ул елларда вакцинация узган кешеләрнең сертификатларында күрәтелгән билге буларак кына түгел, ә башка төшенчәләрне аңлату өчен дә еш кулланыла (QR-код аша түләү башкару, QR-код аша сайтка күчү, QR-код аша мәгълүмат алу һ. б.).

Социаль төркемнәр үзенчәлекле сөйләм барлыкка китерәләр. Яшьләр жаргоны даими рәвештә яңартылып тора, төрле һөнәр ияләре махсус терминнар формалаштыралар.

Фәнни ачышлар һәм технологик үсеш шулай ук телнең лексикасын яңа сүзләр белән баета. Шулай ук башка телләр белән элемтә барышында алынмалар барлыкка килә.

Алда әйтеп узганча телнең яшәеше, аның ни дәрәҗәдә саф булуы яшьләр тарафыннан ни рәвешле куллануыннан чыгып билгеләнә. Бүгенге көн яшьләр телендә нинди алынмалар, яңа сүзләр барлыкка килә дигән сорауга җавап табар өчен «Идел» яшьләр журналының битләренә күзәтү ясалды. Анализ барышында түбәндәгеләрне билгеләп үтәргә мөмкин.

2010 елда Рәсәйдә блогер һөнәре үсеш ала башлый. Билгеле, беренче берничә елда әлеге өлкәгә караган төшенчәләр гади халык өчен аңлашылып бетмәгән, кирәкле саналмаган булса да, бер дистә ел үтүгә әлеге профессия үз эченә алган сүзләр артык нык популрлык алдылар һәм халык телендә еш куллана башладылар.

«Блогер» төшенчәсе XX гасыр ахырында инглиз телендә кулланыла башлый, рус теленә ул XXI гасыр башында тарала, ә бүгенге көндә татар телендә дә актив кулланыла.

Блогер – блог тотучы кеше. [РТ 2018] «Шулай итеп, алга таба сезне яңа геройлар, формат һәм алып баручы – күпләрегезгә *блогер* буларак таныш Айгөл Тимер көтә» (Идел, 2024, август); «Безнең чараның максаты – төрле юнәлештә блог алып баручыларны күрсәтү, быел нинди проектларны чынга ашырачагыбызны уйлау һәм, әлбәттә, татар *блогерлары* өчен мәйданчык булдыру» (Идел, 2025, гыйнвар). Хәзер ике кешенең берсе *блогер* инде (Идел, 2025, гыйнвар).

Әлеге профессиягә бәйле яшьләр теленә шул ук исәптән татар теленә бик күп башка алынмалар да үтеп керә һәм кулланыла башлый.

Блог – даими яңартылып торган вакытлыча кыска-кыска язмалардан, рәсемнәрдән, төрле мультимедиа мәгълүматтан торган шәхси яки корпоратив веб-сайт. [РТ 2018] «Әйе, шәхси *блогыңда* бераз бу турыда сөйләгән идең» (Идел, 2025, март).

Блогинг – даими рәвештә билгеле бер темага контент булдыру һәм блог алып бару процессы. «Сезнең *блогинг* юнәлешенә ничек килеп эләгүегезне беләсе килә» (Идел, октябрь, 2024).

Конент – мәгълүмат бирү, өйрәтү, күңел ачу яки аудиториянең игътибарын җәлеп итү максатыннан бастырыла һәм таратыла торган мәгълүмат. «Бүген блогерлар матур һәм сыйфатлы гына түгел, ә аудитория өчен файдалы *контент* да эшли» (Идел, 2024 октябрь).

Лайк – блогларда һәм башка социаль челтәрләрдә кулланучыларның контентка карата мөнәсәбәтен белдерергә ярдәм итә торган функция. «Карагач, *лайк* куярга һәм фикереңне калдырырга онытма – безгә тагын да илһамланып эшләргә этәргеч булыр» (Идел, 2024, октябрь).

Паблик – социаль челтәрләрдә кулланучылар өчен алып барылган блог. «*Пабликлар* бу хакта мемнар чыгара, инфлюэнсерлар шәхси комфорт турында күп сөйли» (Идел, 2024, октябрь).

Подкаст – кулланучылар онлайн режимда йөкли яки тыңлый ала торган аудио- яки видеоформаттагы контент. «Тапшыруда мин четрекле сораулар да билгелим: *подкаст* ул – ике кешенең фикер алышуы» (Идел, 2024, август).

Тренд – актуаль юнәлеш. «*Трендлар* бөтен кешегә дә килешмәскә мөмкин бит» (Идел, 2025, март).

Хайп – агрессив реклама, аның максаты кулланучының игътибарын җәлеп итү. «Икенче сезонда Ринат Рәхмәтуллинга шалтыраттым, аның турында имеш-мимешләр кеше телендә йөри иде, мин инде шул *хайпы* «элэктереп», «Ринат абый, сезнең белән төрмәдәге свидание турында чыгыш ясарга телим», – дидем» (Идел, 2025, март).

Хейт – кемгә дә булса яки нәрсәгә дә булса тискәре мөнәсәбәт. «Шоу барышында *хейт* белән очрашырга туры килде дип беләбез» (Идел, 2025, март).

SMM-белгеч – социаль медиа платформаларында идарә итү, стратегия һәм контент белән шөгыльләнүче профессионал, ул брендны алга җибәрү, клиентларны җәлеп итү һәм аның күрүчәнлеген арттыру максаты белән шөгыльләнә. «Сүзем блогер, алып баручы*, SMM-белгеч* Ләйлә Лерон хакында» (Идел, 2024, август).

Шулай итеп, бүгенге көндә телебезгә актив рәвештә яңа алынмалар кереп тора. Алар тиз арада халык телендә таралып, әдәби сүзләр рәтендә теркәләләр. Анализ барышында «Идел» яшьләр журналы битләрендә блогер һөнәренә бәйле дә шактый яңа алынмалар теркәлгәне ачыкланды, аларның 20% инде сүзлекләрдә урын алып, әдәби сүзләр рәтенә кергән, калгаңнар әлегә сүзлекләрдә теркәлмәгән, тик халык телендә актив кулланалар, димәк, тиз арада алар да әдәби лексик сүз статусын алачаклар.

Алынмалар теләсә кайсы телне, шул исәптән татар телен үстерүдә төп роль уйный. Алар сүзлек запасын киңәйтә, телгә яңа чынбарлыкларга һәм мәдәни йогынтыларга җайлашырга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, элек чит элементлар буларак кабул ителгән күп кенә чит ил сүзләре акрынлап көндәлек сөйләмгә интеграцияләнә һәм әдәби телнең аерылгысыз өлешенә әверелә. Бу лексиканы баету процессы, ул халыкның мәдәни үзенчәлеген саклап калуга ярдәм итә. Кайбер алынмалар инде әдәби сүз статусын алган, ә икенчеләре актив куллану стадиясендә һәм тиздән гомум кабул ителергә мөмкин. Шулай итеп, алынма сүзләрнең интеграция процессын өйрәнү телнең яшәеш механизмнарын яхшырак аңларга һәм аның бай мәдәни мирасын сакларга ярдәм итә.

ЛИТЕРАТУРА

1. Галимбикова И.И. Журнал «Идел« в контексте татарской культуры и языка / И.И. Галимбикова, Х.Х. Кузьмина. Текст : электронный // Казанская наука. 2025. № 6. С. 258–260. URL: file:///C:/Users/Ilzir/Downloads/Kazanskaya_Nauka_2025_6.pdf (дата обращения: 08.09.2025).

2. Татар лексикологиясе: өче томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина.. Казан: ТӘһСИ, 2015. Т. I. 352 б.

3. Мөхиярова Р.Х. XX гасыр ахыры–XXI гасыр башы татар әдәби теле лексикасы. Казан: Татар. кит. нәшр., 2019. 183 б.
4. Русско-татарский словарь: в двух томах. Т. 1–2. Казань: ИЯЛИ, 2018.

УДК 811.512.145

Галимова Ольга Николаевна
ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
Казан, Россия
Галимова Ольга Николаевна
Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
Казань, Россия
Galimova Olga Nikolaevna
G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art
of the Tatarstan Academy of Sciences
Kazan, Russia
E-mail: Olgan_77@mail.ru

ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ ТЕРМИНОГРАФИК СҮЗЛЕКЛӘРЕНДӘ КУШЫМТАЛАР ЭВОЛЮЦИЯСЕ

ЭВОЛЮЦИЯ ПРИЛОЖЕНИЙ В ТЕРМИНОЛОГИЧЕСКИХ СЛОВАРЯХ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

EVOLUTION OF APPLICATIONS IN TARTAR TERMINOLOGY DICTIONARIES

Аннотация. *В статье рассматриваются приложения терминологических словарей конца XIX–XXI вв. Изучается их содержание, связь с основным указателем. Выявлено, что первое приложение, данное К. Насыри в «Словаре к книге “Цветы и травы”» (1894), представляет собой алфавитный указатель терминов, функционирующих в книге «Цветы и травы». В 20–30-е гг. XX в. приложение становится важным элементом макроструктуры словаря, поскольку показывает функционирование терминов в специальных текстах. Сегодня в этой части даются различные таблицы, иллюстрации, информация о формировании и развитии терминосистемы, алфавитные указатели терминов, пословицы и поговорки. Особую нагрузку в русско-татарских терминологических словарях несут алфавитные указатели татарских терминов, значительно расширяющие возможности словаря.*

Annotation. *The article discusses the applications of terminological dictionaries of the late XIX–XXI centuries. Their content and the connection with the main index are studied. Revealed that, the first application given by K. Nasyri in the «Dictionary for the book “Flowers and Herbs”» (1894) is an alphabetical index of the terms functioning in the book “Flowers and Herbs”. In the 20–30rd years of the XX century. the application becomes an important element of the macrostructure of the dictionary, since it shows the functioning of terms in special texts. Today, in this part, various tables, illustrations, information on the formation and development of the terminology system, alphabetical indexes of terms, proverbs and sayings are given. Alphabetical indexes of Tatar terms bear a special load in Russian-Tatar terminological dictionaries, significantly expanding the capabilities of the dictionary.*

Ключевые слова: *татарский язык, терминологический словарь, структура словаря, приложение, словник*

Keywords*: Tatar language, terminology dictionary, dictionary structure, appendix, dictionary*

Билгеле булганча, терминографиядә махсус сүзлекләрнең структурасына зур игътибар бирелә, чөнки сүзлекнең дөрес төзелеше мәгълүматны дөрес, оптималь күләмдә бирү һәм кулланучыга әлеге хезмәттән файдалануны җайлы итүнең төп шарты булып тора. Структура дип сүзлекнең һәм аның аерым кисәкләренең оештырылышына әйтәләр [2: 102]. Ул макроструктур һәм микроструктур өлешләргә бүленә. Макроструктура дигәндә сүзлекнең гомуми структурасы һәм лексик берәмлекләрне сүзлектә урнаштыру рәвеше, ә микроструктура дигәндә сүзлек мәкаләләренең форматы, эшләнеше аңлашыла [6: 37]. Макроструктураны бары сүзлек мәкаләләренә генә дә бәйләп аңлату да бар. Бу очракта сүзлекнең аерым өлешләре урнашу рәвеше мегаструктура, икенче төрле кысалы структура дип карала [3: 15]. Әмма С.В. Гринев-Гриневич фикеренчә, сүзлекнең аерым өлешләре үзара бәйләнгән булу сәбәпле, керештән алып кушымталарга кадәр барлык кисәкләр дә макроструктураны тәшкил итә. Мәсәлән, шул ук кушымталар сүзлекнең төп өлешендәге мәгълүматны киңәйтә һәм тирәнәйтә, аерым очракларда исә сүзлекнең мәҗбүри өлеше булып тора [6: 37–38]. Ф.С. Фасеев та кушымталарның сүзлекчә белән бәйлелегенә игътибар итә [28: 115]. Кереш, лөгатьлек, кушымтадан торган сүзлекләр традицион яки гадәти төзелешкә ия сүзлекләр саналалар [3: 15; 4: 177].

Кушымталар татар теленең әле беренче терминологик сүзлекләрендә үк кулланыла. Әйтергә кирәк, рус телендә термин буларак кулланылган сүзләрне җыйган «Чит сүзләр» дә К. Насыйриның «Рус хоруфы һиҗасы үзрә мөрәттәб лөгать китабы»нда (1892) кушымта буларак бирелә [28: 114], ягъни терминологик сүзлекләр телара сүзлекләргә кушымта буларак эшләнә башлый. Галимнең үсемлек, аның кайбер өлешләренең һәм алардан алынган матдәләрнең кайбер атамалары тупланган «“Гөлзар вә чәмәнзар” китабына сүзлег»е (1894) исә чын кушымта белән эшләнә. Хезмәткә «гыйлавә» бирелүе һәм аның эчтәлеге турында автор керештә үк әйтеп үтә: «كلزار و چمنزار كتابند ه مذكورنباتات ننك روسيه و لاتينيه لرى و آند ه ذكر ايتولماكان بعض نباتاتلارننك علاو ه سى بلان » / «Гөлзар вә чәмәнзар» китабында мәзкүр нәбататның русия вә латинияләре вә анда зикер ителмәгән бәгъзы нәбататларның гыйлавәсе белән [9: 1]. Кушымта «صفرندان قاراب روسچه سن تابارغه» / «Сыйфырыннан карап русчасын табарга» дигән баш астында 12–16 битләрдә урнашкан. Монда «Гөлзар вә чәмәнзар»да кулланылган атамаларның исемлеге тәкъдим ителә, һәркайсының китапта ничәнче битләрдә кулланылуы күрсәтелә. Ул, сүзлекнең төп өлешендәге кебек, үк өч баганада алфавит тәртибендә төзелә. Яңа хәрефтән башланган өлешләр, гадәттә, горизонталь сызык белән аерылып тора. Барлыгы 400 дән артык берәмлек теркәлгән. Алар арасында фитонимнардан тыш нәкъ лөгатьлектәгечә үсемлек өлешләренең һәм алардан алынган матдәләрнең атамалары да китерелә:

٢٣شالقان / шалкан

٢٣١شالقان اورلوغى / шалкан орлыгы

شالقان مایی ۲۳۲ / шалкан мае [9: 14].

Тышкы яктан сүзлек белән охшаш булса да, кушымта «Гөлзар вә чәмәнзар» китабының эчтәлеге белән бәйле. Сүзлекнең әлеге китаптан чыгып эшләнүен истә тотканда, авторның өстәмә мәгълүматны шул рәвешчә бирүе аңлашыла.

Шуннан соң терминологик сүзлекләрдә кушымталар бирү XX гасырның 20–30 нчы елларында активлашып китә. Әле кушымта дип аталмасалар да, алар хезмәтләргә билгеле бер максатны күздә тотып өстәмә рәвештә эшләнәләр, лөгатьлектән аерып биреләләр. Мәсәлән, 1926 елда чыккан «Краткий русско-татарский словарь военных терминов (толмач)» сүзлегендә винтовка, пулемёт өлешләренең атамалары һәм командаларның татарчасы тәкъдим ителгән өстәмә өлеш, керештә әйтелгәнчә, эзләп табу уңай булсын өчен сүзлек ахырында китерелә [7: 4] һәм тәрҗемәчеләргә, хәрбиләргә терминнарны дөрес куллануга ярдәм итәргә тиеш була. Бу өлеш тә сүзлек кебек үк өч баганага бүлеп эшләнгән: беренче баганада кириллицада баш рус сүзе, икенче баганада гарәп графикасында аның татар эквиваленты һәм җәяләр эчендә рус сүзе, өченче баганада кириллицада татар эквиваленты бирелә. Шуңа да алар чын мәгънәсендә сүзлек мәкаләсе булып тора:

Подушка (پادوشکا۰) مندە ر Мендәр
Ползун (پالزون) شووعچ Шуёгөч [7: 172].

Монда теркәлгән берәмлекләрнең саны да аз түгел: винтовка өлешләренең атамалары бүлекчәсенә 100, пулемёт өлешләренең атамалары бүлекчәсенә 108 атама тупланган һәм 41 команданың татарчасы бирелә. Алар арасында китерелгән *заряд, затвор, калибр, отдача, смирно, стой* кебек кайбер атамалар соңрак чыккан сүзлекләрдә, мәсәлән «Русча-татарча хәрби терминнар сүзлеге»ндә, лөгатьлеккә кереп китә [13: 21, 22, 24, 34, 59, 61].

1927 елда дөнья күргән «РСФСР кодексларында очрый торган атамалар лөгатьчәсе»ндә 31–35 нче битләрдә төрле документларның үрнәкләре (карар, гаепләү нәтиҗәсе, хөкем) китерелә. Ул, керештән аңлашылганча, татар теленең, татар терминнарының суд эшендә дөрес кулланылуын күрсәтүгә, ныгытуга хезмәт итә [27: 2].

Билгеле булганча, татар телендә терминологик сүзлекләрне бер үк вакытта русча-татарча һәм татарча-русча итеп төзү тәҗрибәсе бар. Мәсәлән, «Политик экономик терминнар (русча-татарча һәм татарча-русча)» (1941) сүзлеге шундый. Ф. Фасеев ике яклы тәрҗемә сүзлекләренең татар кулланучысы өчен уңайлы булуын билгеләп үтә, ә инде «Русча-татарча терминологик сүзлекләргә кушымта итеп татарча терминнар исемлеген бирү, русча адәкватын белү өчен төп сүзлеккә цифрлар белән кайтару»ның тагын да экономияле булуына басым ясый [28: 115]. 50 нче елларда, мәсәлән, терминнар күрсәткече булган шундый сүзлекләр дөнья күрә. «Әдәбият белеме сүзлеге»нең (1950) «Төзүчедән» дип аталган керешендә хезмәтнең ахырында терминнарның кайсы биттә урнаштырылуы турында мәгълүмат булуы әйтелә. Ә «Терминнар күрсәткече»нең төзелеше турында астөшермәдә «цифрлар терминнарның кайсы биттә урнаштырылуын күрсәтә дип

аңлатыла [1: 4, 224]. Эшләнеше ягыннан ул К. Насыйриның «“Гөлзар вә чәмәнзар” китабына сүзлег»енә тартым: алфавит тәртибендә атамалар бирелә, аларның битләре күрсәтелә. Әмма бу очракта кушымтада башка хезмәттәге түгел, ә сүзлекнең үзендә инде теркәлгән терминнар урнаштырыла. 1958 елда Б.Н. Пономарев редакциясендәге русча сүзлекнең икенче басмасыннан тәрҗемә ителеп басылып чыккан «Политик сүзлек»нең күрсәткече катлаулырак төзелешкә ия. Анда төп мәкаләләр тематикалап бирелгән. Барлыгы 10 төркем, аерым төркемнәр төркемчәләргә дә бүленә. Мәсәлән, СССР төркемендә «Дәүләт һәм җәмәгать төзелеше», «Җәмәгать оешмалары», «КПСС, Совет дәүләте һәм армия эшлеклеләре», «Тышкы политика төркемчәләре бар [11: 693-696]. Ләкин андый бүленеш, белгечләргә җайлы булса да, гади кулланучы өчен тоташ алфавит тәртибендә бирүгә караганда авыррак. Моннан тыш «Кушымта» исеме астында «Үлчәүләр буенча кыскача белешмә», «Метр үлчәүләре» һәм таблицада төрле илләрдәге озынлык, мәйдан, масса, күләм һәм сыйдырыш үлчәүләре китерелә [11: 711–712]. «Русча-татарча техника терминнары сүзлеге»нең (1963) ахырында да кушымтага таблица урнаштырылган, анда «Берәмлекләрнең интернациональ системасы (CU)» урын алган [21].

Терминнар күрсәткечләре булган сүзлекләр ике яклы сүзлекләрне кысрыклап чыгармый, алар эшләнә тора. Мәсәлән, «Русча-татарча физика терминнары сүзлеге»нең (1972) икенче өлеше татарча-русча, мондагы сүзлек мәкаләләре, беренче өлештән аермалы буларак, инде аңлатмалар-сыз төзелгән. Бу сүзлекккә «Берәмлекләр системасы» «Системадан тыш берәмлекләр», «Берәмлекләрнең кабатлыларын һәм өлешләрен ясау өчен алкушымчалар кушымта итеп китерелгән [22: 132–135].

Татар теленең терминологиясе үсешен өйрәнгән Ф.С. Фасеев терминологик сүзлекләрне рәсемнәр, иллюстрацияләр белән эшләү мәсьәләсен күтәрә, бу проблеманың аерым өлкәләр, мәсәлән биология, өчен аеруча актуаль булуына басым ясый [28: 101]. 1971 елда чыккан «Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге»нә, әнә шуны күздә тотып, кушымта итеп рәсемнәр теркәлә. Барлыгы 92 рәсем кергән әлеге өлеш «Иллюстрацияләр» дип исемләнә. Рәсемнәр «Культуралы үсемлекләр», «Чүп үләннәр», «Үсемлек авырулары һәм корткычлары», «Хайваннар һәм кошлар», «Балыклар», «Авыл хуҗалыгы техникасы» тематик төркемнәренә туплана [19: 272–303]. Сүзлекнең махсус редакторы билгеләп үтүкәнчә, рәсемнәр гомуми билгеле булган объектларга, гадәттә, бирелми, ә бары «сүз белән генә аңлатып тиешле төшенчә тудыру кыен булган очракларда кулланыла» [19: 10]. Беренчедән, ят, яңа, сирәк очрый торган экзотик атамаларның төшенчәсен булдыру өчен; икенчедән, бер үк объектның сортларын, төрләрен, аерым өлешләрен күрсәтү өчен, аерым очракларда җенес буенча аерганда уңышлы дип табыла [19: 10]. Кушымтаның сүзлек белән бәйләнешен рәсемнәрнең номерлануы һәм сүзлек мәкаләләрендә әлеге рәсемнәргә сылтамалар тәэмин итә:

кукуруза (маис) кукуруз (1 нче рәс.).
~ **восковая** балавызсыман кукуруз
~ **зубовидная** тешсыман кукуруз (1 нче *б* рәс.)
~ **крахмалистая** крахмаллы кукуруз (1 нче *в* рәс.).
~ **кремнистая** чакма кукуруз, каты кукуруз (1 нче *а* рәс.) [19: 110–111].



1 нче рәс. Кукуруз чәкәннәре (кукурузные початки):
а) — чакматашсыман (кремнистая); *б*) — тешсыман (зубовидная); *в* — крахмаллы (крахмалистая).

Рәс. 1. «Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге»нең кушымтасыннан рәсем

«Русча-татарча астрономия терминнары сүзлеге» дә (1974) өстәмә мәгълүматны биш таблицага туплый: «Кайбер константалар таблицасы», «Җирнең геометрик һәм физик характеристикалары», «Планеталар системасы», «Планеталарның табигый иярченнәре», «Иң якын йолдызлар» [20: 58–63].

«Русча-татарча физика терминнары сүзлеге. Татарча-русча физика терминнары сүзлеге» (1996) дә кулланучыга файдалы, информатив, булган 20 таблицадан торган кушымта белән басылып чыга [23: 188–189]. Монда китерелгән мәгълүмат, әлбәттә, сүзлек мәкаләләрен баета, әмма таблицадагы кайбер атамалар лөгатьлеккә кертелмәгән. Мәсәлән, *почмакча тизлек, почмакча тизләнеш* шундыйлардан [23: 188]. Гомумән, табигать һәм төгәл фәннәрнең атамаларын туплаган сүзлекләрдә иң еш очрый торган кушымталар булып төрле берәмлекләрне күрсәткән таблицалар тора.

XX гасырның 90 нчы елларыннан терминологик сүзлекләрдә кушымталарга игътибар арта. Бу күренеш, безнеңчә, сүзлекләрдә күбрәк информация бирү омтылышы белән бәйле була. Бер төркем русча-татарча сүзлекләрнең кушымталары киң катлам татар кулланучысын күздә тотып эшләнә һәм терминнарның алфавит тәртибендәге күрсәткече итеп эшләнә. «Финанс, икътисад һәм юридик терминнар. Аңлатмалы сүзлек»нең (1996) күрсәткечендә атамалар һәм рус, һәм татар телендә бирелә [29: 207–221]. Ләкин, сүзлек русча-татарча булу сәбәпле, рус телендәге терминнарны яңадан төзеп китү, битләрен күрсәтү кирәксез эш кебек күренә. «Толковый русско-татарский словарь производственно-экономических терминов в области строительства» (2000) күрсәткечкә рус атамаларын гына кертә [26: 130–139]. «Агрохимия һәм туфрак белеме терминнарының русча-татарча аңлатмалы сүзлеге» (2003), «Агроэкология терминнарының русча-татарча аңлатмалы сүзлеге» (2008) һ. б.ш. сүзлекләр бары «Татарча терминнарның алфавит тәртибендәге күрсәткече»н тәкъдим итәләр [17: 104–134; 18: 147–189]. Соңрак мондый күрсәткечләрдә яңа элемент барлыкка килә: атаманың бите генә түгел, ә кайсы хәрефкә каравы да билгеләнә [14: 221–246; 5: 158–200].

XXI гасыр сүзлекләре кушымталарның төрле эчтәлектәгесен тәкъдим итә: төрле белешмәләр, өстәмә атамалар, иллюстрацияләр, мәкаль-әйтемнәр. Мәсәлән, «Русча-татарча аңлатмалы медицина терминнары сүзлеге»ндә (2004) кушымтада «татарларда медицина фәненең һәм теленең барлыкка килүенә, үсешенә кыскача күзәтү» ясала [16: 9, 340–348], «Математикадан русча-татарча аңлатмалы сүзлек»тә (2013) «математика тарихында эз калдырган галимнәр турында кыскача биографик белешмә бирелә» [8: 288–375]. Кушымтада рәсемнәр бирү татар терминографиясе тарихында киң таралган күренеш түгел. Мондый сүзлекләр бик аз. Шуларның берсе – «Офтальмология. Русча-татарча терминологик аңлатмалы сүзлек» (2011). Монда тугыз төсле рәсем бирелә. Медицинаның аерым тармаклары атамаларын туплаган сүзлекләрнең рәсемле булуы төшенчәләрне өстәмә рәвештә тасвирлауга, идентификацияләргә, күреп истә калдырырга, танырга ярдәм итүе белән кыйммәтле. Рәсемнәргә аңлатмаларның рус һәм татар телләрендә эшләнүе сүзлекнең русча-татарча булуы белән аңлатыла. Ләкин сүзлекнең әлеге өлешенең лөгатьлек белән бәйләнешен тиешле дәрәҗәдә түгел дип, чөнки рәсемнәрнең аңлатмаларындагы терминнарның барысы да сүзлеккә кереп бетмәгән. Мәсәлән, тугызынчы рәсемдә ике ягы кабарынкы линза һәм батынкы линза сурәтләнә. Әлеге атамалар *линза* мәкаләсендә чагылыш тапмый. Шулай да *батынкы линза вогнутый* мәкаләсенә мисал буларак кергән, ә *двояковыпуклый* баш сүзе сүзлеккә бөтенләй кермәгән [10: 25, 56–57]. Шунысын да әйтергә кирәк: хәзерге чорда, мәсәлән «Русча-татарча политехника сүзлегендә» (2016), рәсемнәр сүзлек мәкаләсе янына урнаштырыла [12]. Бу исә өстәмә мәгълүматның кушымтада гына түгел, ә сүзлек өлешендә бирелү мөмкинлеген күрсәтә.

Икенче яктан, XXI гасыр – терминологик сүзлекләрдә кушымталарның саны арткан чор. Мәсәлән, «Медицина терминнарының русча-татарча аңлатмалы сүзлеге»ндә (2004) [16], «Балык атамаларының татарча-русча-латинча аңлатмалы сүзлеге»ндә (2019) [5] һәм «Үсемлек атамаларының татарча-русча аңлатмалы сүзлеге»ндә (2020) [24] икешәр, «Татарча-русча-латинча кош атамалары сүзлеге»ндә (2018) [25] алты, «Русча-татарча тарих терминнарының аңлатмалы сүзлеге»ндә (2006) 12 кушымта бирелә. Кушымтада теге яки бу компонентлы мәкаль-әйтемнәрне, сынамышларны туплау милли компонентка игътибар, авторлар әйткәнчә, «татарча атамаларның эчтәлегенә, шигъриятенә төшенергә ярдәм итү» [24: 7–8] белән аңлатыла. Кушымтада диалектларда кулланылган атамаларның исемлеге дә бирелә [5: 201–202; 25: 156–159]. Мондый тупланмалар, тел байлыгын югалтмыйча, терминнарны диалекталь берәмлекләрдән аеруга максат итәләр.

Шул рәвешле, башта русча татарча сүзлекләргә кушымта буларак бирелгән терминологик сүзлекләр, аерым хезмәт буларак басыла башлагач ук кушымта белән эшләнәләр. Башта ул сүзлекнең үзе белән түгел, ә төп чыганак белән бәйле була һәм атамалар күрсәткече рәвешендә төзелә. Беренче тапкыр сүзлеккә кертелгәндә үк бу өлеш гыйләвә дип исемләнә. XX гасырның 20–30 нчы елларында чыккан сүзлекләрдә кушымта сүзлекнең махсус өлеше буларак күрсәтелми, ләкин мәгълүмат-

ның өстәмә китерелүе аларны кушымта дип бәяләргә мөмкинлек бирә. Ул сүзлекнең төп өлешенең дәвамы рәвешендә дә, терминнарны куллану үрнәкләре итеп тә эшләнә. Соңрак кушымталарның эчтәлеге төрлеләнә: сүзлекнең бу өлеше терминнар һәм терминоэлементлар күрсәткече, төрле берәмлекләр, зурлыклар китерелгән таблицалар, иллюстрацияләр, биографик белешмә, терминосистема тарихына күзәтү форматында оештырыла. Еш кулланыла торган терминнар күрсәткече терминологик сүзлекләр төзү тәҗрибәсенә нигезләнә: аның ике яклы сүзлекләрнең милли-чит тел өлешен гадиләштерү нәтиҗәсендә формалашуы мөмкин. Шул ук вакытта күрсәткечтә атамаларның билгеле бер хезмәттәге битен билгеләү К. Насыйри сүзлегендә үк күзәтелә. Ә инде хәрефне дә күрсәтү чагыштырмача яңа элемент булып тора. Иллюстрацияләр кушымталарга сирәк урнаштырыла. Хәзерге чорда рәсемнәрне сүзлек мәкаләсе янында бирү тәҗрибәсе кушымта буларак бирелгән мәгълүматның төп өлешкә кереп китү мөмкинлеген күрсәтә.

ӘДӘБИЯТ

1. Әдәбият белеме сүзлеге / төз.: Н. Гыйззәтуллин; ред.: Г. Халит. Казан: Татар. кит. нәшр., 1958. 230 б.

2. Балканов И.В. Мегаструктура отраслевого словаря (на материале военных двуязычных словарей XX века) // Вестник Московского университета. Сер. 22. Теория перевода. 2016. № 3. С. 101–113.

3. Берков В.П. Двуязычная лексикография: Учебник: 2-е изд., перераб. и доп. М.: ООО «Издательство Астрель»: ООО «Издательство АСТ»: ООО «Транзиткнига», 2004. 236 с.

4. Будкова С.С. Структурные параметры словарей, включающих термины подъязыка «Радиационные и плазменные технологии» // Ярославский педагогический вестник. 2012. № 1. Т. 1 (Гуманитарные науки). С. 175–179.

5. Галимова О.Н. Балык атамаларының татарча-русча аңлатмалы сүзлеге. Казан: ТӘһСИ, 2019. 204 б.

6. Гринев-Гриневич С.В. Введение в терминографию: Как просто и легко составить словарь: учеб. пособ. изд. стереотип. М.: Книжный дом «ЛИБРОКОМ», 2021. 222 с.

7. Краткий русско-татарский словарь военных терминов. М.: Искра революции, 1926. 176 с.

8. Математический русско-татарский толковый словарь / авт.-сост.: Л.И. Галиева, И.Г. Галяутдинов, М.З. Хуснетдинов и др.; под общ. ред. Л.И. Галиевой и Г.Г. Галяутдинова. Казан: Татар. кн. изд-во, 2013. 375 с.

9. Насыйри К. «Гөлзар вә чәмәнзар» китабына сүзлек. Казан, 1894. 16 б.

10. Офтальмология: русско-татарский терминологический толковый словарь / авт.-сост. Р.Ф. Гайнутдинова. Казань: Татар. кн. изд-во, 2011. 127 с.

11. Политик сүзлек: проф. Б.Н. Пономарев ред. чыккан русча сүзлекнең икенче басмасыннан тәрҗ. / тәрҗ.: Б. Шәрәфетдинов, С. Хафизов, Х. Сәмигуллин, Ә. Әскәров; ред.: Г.Ф. Шәрипов, С.Х. Сәмигуллин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1958. 173 б.

12. Русско-татарский политехнический словарь / под общ. ред. Р.А. Шакирзянова. Казань: Магариф-Вакыт, 2016. 658 с.

13. Русско-татарский словарь военных терминов / Авт.-сост Р.А. Мугинов. Казань: Татар. кн. изд-во, 2000. 151 с.

14. Русско-татарский словарь лингвистических терминов / Под ред. Ф.И. Тагировой и Ф.Ф. Гаффаровой. Казань: ИЯЛИ, 2016. 248.

15. Русско-татарский толковый словарь исторических терминов. Казань: Магариф, 2006. 224 с.

16. Русско-татарский толковый словарь медицинских терминов. Казань: Магариф, 2004. 351 с.

17. Русско-татарский толковый терминологический словарь по агрохимии и почвоведению / сост.: М.Ю. Гилязов, С.Г. Муртазина, Ф.Ф. Гаффарова. Казань: Магариф, 2003. 135 с.

18. Русско-татарский толковый терминологический словарь по агроэкологии / авт.-сост.: С.Г. Муртазина, М.Ю. Гилязов, Ф.Ф. Гаффарова, М.Г. Муртазин. Казань: Татар. кн. изд-во, 2008. 191 с.

19. Русча-татарча авыл хуҗалыгы терминнары сүзлеге / төз.: А.К. Тимергалин, Г.Г. Ахметов, Ш.Г. Садыйков; махсус ред. Ф.С. Фасеев. Казан: Татар. кит. нәшр., 1971. 304 б.

20. Русча-татарча астрономия терминнары сүзлеге / төз.: М. Галеев, А. Тимергалин. Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. 64 б.

21. Русча-татарча техника терминнары сүзлеге / төз.: А.К. Тимергалин, М. Галеев. Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. 216 б.

22. Русча-татарча физика терминнары сүзлеге / төз.: М. Галеев. Казан: Татар. кит. нәшр., 1972. 136 б.

23. Русча-татарча физика терминнары сүзлеге. Татарча-русча физика терминнары сүзлеге / төз.: Г.Ю. Даутов, Д.Г. Галимов, З.М. Вәгыйзова; ред. Г.Ю. Даутов. Казан: Таң-Заря, 1996. 200 б.

24. Сабитова И.И., Саберова Г.Г. Үсемлек атамаларының татарча-русча аңлатмалы сүзлеге. Казан: ТӘhСИ, 2020. 216 б.

25. Сафина Э.И. Татарча-русча-латинча кош атамалары сүзлеге. Казан: ТӘhСИ, 2018. 148 б.

26. Сафиуллова Л.Ш., Биктимирова Л.Ф. Толковый русско-татарский словарь производственно-экономических терминов в области строительства. Казань: РИЦ «Школа», 2000. 140 с.

27. Словарь терминов, встречающихся в кодексах РСФСР. Казан, 1927. 36 б.

28. Фасеев Ф.С. Татар телендә терминология. Казан: Татар. кит. нәшр., 1969. 200 б.

29. Финансово-экономические и юридические термины. Толковый словарь / сост.: К.М. Гарифуллин, Н.Г. Хайруллин, Ф.Н. Фаткуллин, Н.К. Гарифуллин, А.М. Ганеев, Ф.С. Зиятдинов, З.А. Ахметьянова, Р.А. Бурганова, М.Х. Ханнанов. Казань: Изд-во КФЭИ, 1996. 224 с.

УДК 811.512.145

Галиуллина Гульшат Раисовна
Казанский федеральный университет
Казань, Россия
Galiullina Gulshat Raisovna
Kazan (Volga Region) Federal University
Kazan, Russia
E-mail: caliullina@list.ru

ФРАЗЕОЛОГИЗМЫ, ВЫРАЖАЮЩИЕ *ГНЕВ* В ТАТАРСКОМ ЯЗЫКЕ

PHRASEOLOGICAL UNITS EXPRESSING *ANGER* IN THE TATAR LANGUAGE

Аннотация. *Изучение лексических единиц, выражающих эмоциональное состояние человека, дает ключ к пониманию национального характера. Объектом исследования выбраны фразеологизмы, выражающие гнев в татарском языке. В данном кратком обзоре рассмотрена эмоционально-оценочная семантика данной группы фразеологизмов. На основе анализа пришли к выводу, что ядерная лексема эмоции группы «гнев» ачу 'гнев, злоба, злость' в татарском языке является универсальной и участвует при выражении разные степени состояния гнева.*

Annotation. *The study of lexical units that express a person's emotional state provides a key to understanding the national character. The object of the research is idioms expressing anger in the Tatar language. This brief review examines the emotional-evaluative semantics of this group of phraseological units. Based on the analysis, we conclude that the core lexical unit for the emotion of 'anger' – açu (anger, rage, wrath) – is universal in the Tatar language and is used to express different degrees of the state of anger.*

Ключевые слова: *татарский язык, эмотивность, лексика, фразеологизмы*

Keywords: *Tatar language, emotiveness, vocabulary, phraseological units*

В языке каждого народа имеются образные выражения, отражающие национальный колорит и репрезентирующие внутренний мир человека. Среди таких единиц особое место занимают фразеологические единицы, которые обладают свойством выражения эмоционального состояния человека. Фразеологическая эмоциональная картина мира в татарском языке насыщеннее, чем номинативная лексическая картина мира, так как фразеологизмы выражают эмоции человека через многочисленные семантические модели, основанные на образной составляющей фразеологизмов. В татарском языкознании недостаточно уделяется внимание данному аспекту фразеологических единиц, хотя языковые и стилистические аспекты выражения эмотивности на различных уровнях языка освещаются в работах Л.К. Байрамовой [1], Д.К. Вахитовой [2], Г.З. Габбасовой [3], Г.Р. Галиуллиной [4; 5], Н.Ф. Галиевой [6], Э.Н. Денмухаметовой [7], Р.Р. Замалетдинова [8],С.А Косцовой [10], А.Э. Хабибуллиной [11] и др.

Целью нашей работы является анализ эмоционально-оценочной семантики фразеологизмов, выражающих гнев.

Эмоции группы «гнев» распределяются на шкале интенсификации состояния таким образом: 1) досада, раздражение; 2) озлобленность; 3) возмущение; 4) ярость. В татарской фразеологической картине мира функционирует довольно большое количество устойчивых словосочетаний, отражающие указанные стадии эмоционального состояния. Так, например, в двухтомном словаре Наки Исанбета «Фразеологический словарь татарского языка» [9] фразеологизмов с ядерной лексемой эмоции группы «гнев» *ачу* ‘гнев, злоба, злость’ только в начальной позиции словосочетаний зафиксировано около 25 единиц. Они выражают отрицательную семантику и разную степень оценочности, например, эмотивный компонент фразеологизма *ачу тоту* представлен минимальной интенсивностью, а в фразеологизме *ачудан кара яну* букв. «стать черным от гнева» в значении ‘*гореть от злости*’ мы замечаем наиболее высокую степень интенсивности эмоционального состояния.

В новом словаре фразеологизмов татарского языка Ф.С. Хакимзянова представлено 60 устойчивых словосочетаний и выражений с данной лексемой [12].

Дополняя денотативное содержание, эмотивный аспект фразеологических единиц выражает отношение субъекта к предмету, передает разнообразные эмоции. Как известно, изучаемые нами фразеологизмы передают отрицательно-оценочные эмоции. Они показывают неодобрительного или пренебрежительного отношения к субъектам или событиям. Денотативное значение фразеологизмов, входящих в данную группу, можно определить как состояние субъекта, при котором он испытывает негодование, озлобленность, не способен контролировать свои поступки. Основу данной группы составляют фразеологизмы, в составе которых встречается лексема *ачу* ‘гнев, злоба, злость’, имеющие значение ‘*затаить гнев*’: *ачу йоту* букв. «проглотить гнев»*; ачу тоту* букв. «держать злость»; *ачу килү* букв. «гневаться, злиться, сердиться» и др. Указанные фразеологизмы выражают досаду, раздражение, в которых гнев выражен в минимальной степени. Рассмотренные выше фразеологизмы выражают отрицательное эмоциональное состояние субъекта, преимущественно переживаемое изнутри. Нам кажется, что характерные для этнопсихологии татарского народа такие внутренние качества как терпение, скрытие своего эмоционального состояния легли в основу указанных фразеологизмов.

Эмоционально-оценочное отношение может варьироваться в зависимости от того, идет ли речь о третьем лице, обращена ли она к собеседнику или же является высказыванием говорящего о самом себе. Это в основном прослеживается в тех случаях, когда речь идет о глагольных фразеологизмах, которые выступают в роли сказуемого. Ниже рассматриваемые фразеологические единицы со значением ‘гнев’ представлены по мере возрастания интенсивности негативного эмоционального состояния. Так, например, фразеологизм *сул аягы белән тору* букв. «вставать с левой ноги» в значении ‘быть в мрачном, дурном настроении, в раздражении’ употребляется в отношении третьего лица. В ней отражается состояние

озлобленности. Культурно-коннотативная семантика фразеологизма связана с суевериями татар, что если все дела выполняются с правой руки, если с утра человек встает с правой ноги, то весь день будет легким и непринужденным. Если же человек отступит от данного поверья, то удачи и хорошего настроя не ожидай ни в чем. Данная фразеологическая единица употребляется в отношении человека, действия которого выходят за рамки общепринятых норм.

Фразеологизмы *кызу кул астына туры килү; кызган чакка туры килү* ‘под горячую руку’ употребляются для оценки состояния возбуждения, раздражения и гнева. Фразеологическое значение указанных единиц основывается на значении лексемы *кызу* (производное – *кызган*) ‘горячий’, которое передает представления о состоянии субъекта, реже какого-либо предмета или явления. Денотативный компонент данного слова способствует выявлению предметной отнесенности знака, вызывая в сознании предметное представление. Сигнификативный компонент определяет соотнесенность указанных фразеологизмов с представлением признака и имеет более высокую степень абстрактности. Денотативный и сигнификативный компоненты взаимодействуют и образуют единое предметно-логическое содержание рассматриваемых фразеологизмов. Коннотативный компонент, который выступает наиболее важным из всех компонентов в семантической структуре фразеологизмов, стимулирует высокую интенсивность меры признака (*кызу, кызган* ‘горячий’), вызывает ассоциации причинно-следственного характера и демонстрирует более высокую степень обозначения гнева.

Фразеологические единицы *үзен-үзе белешмәү; чыгырыннан чыгу* ‘вне себя’, ‘в крайнем возбуждении или раздражении’ выражают ярость и чаще являются высказыванием говорящего о самом себе, чуть реже – для описания эмоционального состояния третьего лица.

Наиболее высокая степень анализируемого негативного эмоционального состояния представлена в фразеологических единицах *авызыннан ут чәчү* букв. «извергать огонь со рта» в значении ‘рвать и метать’; *күк кебек күкрәп, яшен кебек ату* букв. «греметь как гром, сверкать как молния» в значении ‘говорить гневно, раздраженно’; *җене кузгалу* букв. «шайтан (бес) забеспокоился» в значении ‘в состоянии нервного возбуждения, негодования, возмущения’; *җене котыру* / *чыгу* / *кабыну* букв. «вселился бес и негодует», имеет значение ‘выходить из себя’. Два последних фразеологизма напрямую связаны с поверьями татарского народа, которые в старину считали, что нечистые силы (җен, шайтан и др.), вселяются в людей и доводят их до состояния нервного возбуждения, возмущения, гнева, что человек перестает контролировать себя, свои эмоции и действия.

Подытоживая представленный краткий обзор, отмечаем, что существуют доминантные, ключевые эмоции, носящие универсальный характер, однако, способы их выражения имеют национальную специфику. Ядерная лексема эмоции группы «гнев» *ачу* ‘гнев, злоба, злость’ является универсальной и участвует при выражении всех четырех степеней состояния гнева.

Таким образом, фразеологические единицы, выражающие эмоции человека являются одной из значимых областей фразеологического фонда. Они позволяют понять эмоциональное состояние не только отдельно взятой личности, но и народа в целом.

ЛИТЕРАТУРА

1. Байрамова Л.К. Счастье и несчастье как ценность и антиценность во фразеологической парадигме русского, татарского, английского, немецкого, французского языков: аксиологический фразеологический словарь. Казань: Центр инновационных технологий, 2012. 495 с.

2. Вахитова Д.К. Инвективная лексика татарского языка: функциональный и этноментальный аспекты: дис. … канд. филол. наук. Казан. гос. ун-т. Казань, 2013. 239 с.

3. Габбасова Г.З. Средства выражения экспрессивности в татарском литературном языке (на материале имен существительных и прилагательных): автореф. дис. ... канд. филол. наук. Башк. гос. ун-т. Уфа, 2002. 26 с.

4. Галиуллина Г.Р. Тюрко-татарская лексика как проекция национального менталитета / Г.Р. Галиуллина, А.Ш. Юсупова, Г.К. Хадиева, Э.Н. Денмухаметова. Казань, 2011. 120 с.

5. Galiullina G.R.; Khadieva G.K.; Mukhametgalieva Z.M.; Dubrovina M.E. Phraseological units as means of expressing the emotivity in the tatar language // Revista Entrelinguas. V. 7. № 1. 2021. P. 154–161.

6. Galieva N.F., Galiullina G.R. Emotive idioms Tatar language as national mentality reflection // Journal of Language and Literature. V. 6, Issue 1. 1 February 2015. P. 273–276.

7. Денмухаметова Э.Н. Фразеологическая синонимия в татарской прозе // Учен. зап. Казан. ун-та. Серия «Гуманитарные науки». 2008. Т. 150. № 8. С. 111–115.

8. Замалетдинов Р.Р. Татарская лингвокультурология: концепты духовного мира человека. Казань: Бриг, 2012. 300 с.

9. Исәнбәт Н. Татар теленең фразеологик сүзлеге: 2 томда / ф. ред. В.Х. Хаков. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. Т. 1 (А–К). 495 б.; 1990. Т. 2. (Л–Һ). 365 б.

10. Косцова С.А. Сайфулина Ф.С. Фразеологизмы-злопожелания, адресованные обманщику/клеветнику, в современном татарском языке: структурно-компонентный анализ // Филология и культура. 2025. № 2 (80). С. 41– 47.

11. Хабибуллина А.Э. Фразеологические единицы, выражающие эмоциональное состояние человека // Известия Волгоградского государственного педагогического университета. Филологические науки. 2016. С. 152–158.

12. Хәкимҗанов Ф.С. Татар теленең фразеологизмнар сүзлеге: тотрыклы сүзтезмәләр һәм тәгъбирләр: өч томда. I т. (А–Б). Казан, 2022. 672 б.

УДК 811.512.145

Гыйльманова Мөслимә Мәлик кызы
Казан федераль университеты
Казан, Россия
Гильманова Муслима Маликовна
Казанский федеральный университет
Казань Россия
Gilmanova Muslima Malikovna
Kazan Federal University
Kazan, Russia
E-mail: muslimag80@bk.ru

1960–1980 ЕЛЛАР ШИГЪРИЯТЕНДӘ ЙОЛА ТРАДИЦИЯЛӘРЕНЕҢ ЯКТЫРТЫЛУ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

СПЕЦИФИКА ИЗОБРАЖЕНИЯ ОБРЯДОВЫХ ТРАДИЦИЙ В ТАТАРСКОЙ ПОЭЗИИ 1960–1980-Х ГОДОВ

THE SPECIFICS OF THE DEPICTION OF RITUAL TRADITIONS IN TATAR POETRY OF THE 1960S AND 1980S

Аннотация. *Статья посвящена изучению особенностей освещения обрядовых традиций в поэзии 1960–1980-х годов. В рамках статьи рассматриваются как функции обрядов, развивающихся из устного народного творчества в поэтических произведениях, так и влияние мифических представлений на поэтическую картину мира. Обряд подчеркивает обновление ритуалов в поэтической плоскости, сохранение и передачу из поколения в поколение жизненного опыта (культуры), достигнутого в произведениях. Анализируются индивидуальные находки татарской поэзии 1960–1980-х годов.*

Annotation. *The article is devoted to the study of the peculiarities of the illumination of ritual traditions in poetry of the 1960s–1980s. The article examines both the functions of rituals that develop from oral folk art in poetic works, and the influence of mythical representations on human consciousness. The rite emphasizes the renewal of rituals in the poetic plane, the preservation and transmission from generation to generation of the life experience (culture) achieved in the works. The individual finds of Tatar poetry of the 1960s–1980s are analyzed.*

Ключевые слова: *обряд, татарская поэзия, мифология, обычаи, стиль*

Key words: *ritual, Tatar poetry, mythology, customs, style*

Фәндә «берәр коллективның (гаилә, тыру, кабилә кабиләләр берлеге) яисә аерым кешенең ижтимагый-хуҗалык һәм гаилә тормышында иң җитди мизгелләрдә башкарыла торган, борынгыдан килгән һәм төрле магик сүз, сүз тезмәләре, җыр-такмак-такмаза, музыка һәм бию белән барган традицион хәрәкәт-гамәлләрне йола дип атыйлар» [1: 110].

Йолалар кеше аңын мифологик карашлар билгеләгән дәвердә үк барлыкка килә башлаган. Бер яктан йола телдән сөйләнә торган мифларның гамәли гәүдәләнәшен тәшкил итә, икенче яктан, миф магия белән сугарылган әлеге хәрәкәтләрнең ни өчен башкарылуын дәлилли, йоланың мифологик эчтәлеген аңлата [2: 235]. Һәр халык буыннан-буынга күчә торган

гореф-гадәтләрен, яшәү рәвешләрен, үз-үзләрен тоту кагыйдәләрен, карашларын, зәвыкларын сакларга омтылган. Тормыш-көнкүрештә билгеле бер йолалар үтәү, гореф-гадәтләрне тоту һәм бәйрәмнәр үткәрү барлык халыкларга дә хас. Ул әлеге халык мәдәниятенең мөһим бер өлеше булып исәпләнә. Билгеле бер йолаларның үтәлеп килүе җәмгыятьне дә тотрыклы итә. Йолаларын, традцияләрен саклаган халык кына тулы кыйммәтле тормыш белән яши.

Йола традицияләре, алар белән бәйле образ-мотивлар 1960–1980 еллар татар поэзиясендә дә актив кулланылышта йөри. Мәсәлән, Әдип Маликов «Тормыш кичәм» (1964) шигырендә татар халкында борынгыдан килгән гадәт, йола – «ике куллап күрешү»турында бәян итә. Автор сабыйларга юл бирепузса, олылар белән кул бирепкүрешүе турында әйтә. Илдә яшәүче һәр милләтнең үз йоласы барлыгын искәртә. Илебез эчендә алар уникаль, шуңа да һәрбер милләтнең йоласына хөрмәт зур: Мин илемнең һәр каласы белән / Күрешеп йөрим ике кул бирепе. Шулай ук, Гамил Авзал «Авылга кайту» (1957) шигырендә дә татар халкының «ике куллап күрешү» йоласын искә ала: Ике куллап күрешә бабайлар дип күрешүне борыңгыдан калган йола икәнлегенә ишарә итә.Үзен туган җирен сагынып кайтучы кыр казлары белән чагыштыра. Ә менә Мөдәрис Әгъләмовның «Тынлык» (1967) шигырендә юлга чыкканда үтәлә торган йола искә алына. Бу йола буенча, юлга чыгар алдыннан «тезелеп утырып тын алалар», дога кылалар, аннан соң теләкләр теләп юлга кузгалалар: Тыгыз божра булып утырырлар/ Һәм теләрләр изге сәгатьне дип автор мондый йоланы онытмаска, йортка кайткач та әдәпне бозмаска чакыра. Әлеге йола традициясен поэтик дөнья картинасында кабат тергезү татар халкының үзенчәлеген, менталитетын, дөньяга карашын, аның йолаларын тергезергә, шул рәвешле киләчәк буыннарга җиткерергә мөмкинлек бирә.

Соңгы вакытларга кадәр килеп җиткән хуҗалык йолаларында үрчемуңдырышлылык культы белән бәйләнешнең бүген дә сизелеп торуы, гаилә-көнкүреш йола-ритуалларында мифологик ышануларның яки магия элементларының саклануы бер дә гаҗәп түгел, чөнки йола нигезендә яткан магия, бер яктан, табигатьтәге «кара көчләрдән саклану, икенче яктан адәм баласына кирәк булган уңыш, байлык, бәхет һ. б. кыйммәтләрне булдыру максатыннан һәр кылынган гамәлнең асылын нигезләгән» [3: 152]. Шагыйрь Харрас Әюп «Өй өмәсе» (1982) шигырендә авылларда йорт салу өмәсен сурәтли. Элек авылларда җәй көннәре өмә җыеп йорт салу эше башкарылган. Шушы өмә барышында бер борыңгы йола – «нигезгә тәнкә салып калдыру» йоласын үтәгәннәр. Бу кешеләрнең мифологик ышанулары, күзаллаулары буенча әлеге йотта тормыш бай, бәрәкатле булсын дигән ният белән эшләнгән: Нигезләргә тәңкә сала картлар / Бәхет бирсен гомер итәргә! ди автор. Мөдәрис Әгъләмовның «Дүрт почмакка дүрт бакыр» (1973) шигырендә дә шушы йола башкарылганлыгы ассызыклана: Нигезнең дүрт почмагына / Дүрт алтын салса халык ди автор. Халыкның рухи халәтен җиткерүне шагыйрь татар халкының йола традицияләренә төреп бирә.

Киленне каршы алу – туй йоласының иң әһәмиятле өлешләренең берсе. Егетнең әнисе, элек-электән килгән гадәт буенча, яшь киленне өй бусагасы каршында каршы ала, ак җәймәгә яки мендәргә бастырып, авызына балмай ипи каптыра «Телең майдай йомшак, балдай татлы булсын» дип теләк

тели. «Туй» (1967) шигырендә дә шагыйрь Мөдәрис Әгъләмов кызны йортка алып кергәндә «мендәргә бастыру» йоласы белән таныштыра: Алгы көнгә атлаганда халык/ Үткәненә карый текәлеп.. / Үткәннәрнең яхшыларын ала, / Яхшыларын бара күтәреп дип автор борыңгы гореф-гадәтләр, халык җәүһәрләрен саклау мөһим икәнлеген искәртә, «Пар атлардан төшеп мендәргә бас» дип киңәш итә. Ренат Харисның «Йола» шигырендә дә үзенчәлекле йола сүрәтләнә: яшь парларның түшәгендә сабый баланы аунаталар. Мифик ышанулар буенча, бу йола яшьләрнең тормышлары бәхетле, күп балалы булсын өчен үтәлә: Түшиләр түшәкне догалап, / Җәяләр җәймәнең яңасын. / Түшәктә аунатып алалар / Бәхетле гаилә баласын. Автор үзе дә шул йоланы «түшәккә салыштым» ди. Үзенең дә шул йолага тугъры калып «җир буйлап ауныйсы килә»дип шигырь укучыга рухи халәтен җиткерә.

Күмү йолалары ул – билгеле бер эзлеклелектә үтәлә торган гамәлләр җыелмасы белән бәйле дини күзаллауларның хикмәтле күренеше. Һәр халык мәет җирләүне дини йола буенча башкарырга тырыша. Ислам диине кабул ителгәннән соң, үлгән кешене җирләүләр һәм искә алулар нигездә, бертөрле итеп үткәрелә, ул инде калыплашкан гадәт [4: 541]. Л. Зөлкәрнәйнең «Зиратта» (1978) шигырендә бу йоланың үтәлеше халыкның менталитетын ассызыклый: Һәркем, бер уч кайгы салып, / Кабер өстен өйдеме?.. / Изге гадәт – чал карт сорый: / «Яхшы кеше идеме?.. »

Борынгыдан килгән йола-ритуалларның вазифалары күп төрле, полифункциональ характерда. Әмма аларның «иң төп хасяте-вазифасы уртак – традицион гореф-йолалар башкару яки үтәү юлы белән кешенең хуҗалык эшчәнлеген, шулай ук көндәлек тормышын ипле итеп оештыру һәм тәртипле итеп алып барырга ярдәмләшү. Йола ритуалларның башка вазифа-хасиятләре, әйтик, коммуникатив-эмоциональ бушану, ирешелгән тормыш тәжрибәсен (культураны) саклау һәм буыннан-буынга тапшыру кебек функцияләре исә башта аталган төп функциядән үсеп чыгалар һәм аны тулыландыралар» [5: 47]. Шагыйрь Шәүкәт Галиев «Ата-баба йоласы» (1983) шигырендә мунча керүне ата баба йоласы икәнлеген ассызыклый. Мөдәррис Әгъләмовның «Коймаклар» (1963) шигырендә татар халкының кунакларны сыйлау, кунакчыллык йоласы күзәтелә: Безнең халык ачы булса булды, / Дошманына төче булмады, дип автор үткен фикер үткәрә. Сажидә Сөләйманова «Йортыңа иминлек, кардәш» (1972) шигырендә барлык төрки халыкларның сәлам бирү рәвеше (әссәламәгаләйкем дип эндәшү) йола белән янәшәлектә бирелүе күзәтелә: Минем илдән синең илгә / Изгелек тели һәркем, дип автор сәлам бирүне изге бер йола дәрәҗәсенә күтәрә.

Фольклористика һәм этнография фәннәрендә кабул ителгән гомуми классификация нигезендә халыкның йола мәдәниятен ике төргә бүлеп йөртәләр: ел фасыллары белән календарь йолалар (хуҗалык йолалары) һәм гаилә-көнкүреш йолалары. Кешенең яшәеше борынгы заманнардан ук җирдән табигатьтән аерылмаган, кешеләр хуҗалык эшләрен ел фасылларына бәйле рәвештә, мифик көчкә ышанып алып барганнар. Ел фасылларына бәйле календарь йолалар язгы, җәйге, көзге һәм кышкы цикларга бүләләр. Ә гаилә-көнкүреш йолалары кешенең гаиләдә яшәешенә, көндәлек тормышына бәйле төрле гореф-гадәтләрне берләштерә.

Роберт Миңнуллинның «Каз өмәсе» шигырендә карурый сибү ырым-йоласын күрәбез: Су буена сипсәң каурыйларын / Яреңгә дә уңар казыгыз/

Каз өмәсен сүрәтли, кызларга бәхет тели. Мөдәрис Әгъләмов «Каз өмәсе» (1968) шигырендә исә, борыңгы йола белән авыл халкының бердәмлеге мәсәләсе күтәрелә: Канат теләп үсмер кызга, юлда ныклы аяк теләп малайларга, /Бәкегә эз суза-суза / Каз өмәсе авыл иңләп узып бара. Автор эпилогны да су юлы сукмагына каз канаты, каз мамыгы тарату гадәтен атап уза. Автор мондый өмәләр артырга тиешлеге ягъни гореф-гадәтләрнең сакланырга тиешлеге мәсәләсен күтәрә. «Бу өмәләр артсын һаман!» дип тели. Л. Зөлкәрнәй «Печән өсте» (1977) шигырендә халыкның печәнгә төшү йоласын күрәбез: Борыңгыдан калган йола, / Борыңгыдан болында: / Бабайларның чалгылары / Егетләрнең кулында. Шагыйрь Гамил Авзал «Болгарлар» (1977) шигырендә татарларда таралган Нардуган йола-бәйрәмен искә ала. Бу йола 25 декабрь – 5 гыйнвар аралыгында уздырыла. Кояш календаре буенча әлеге астрономик вакыт аралыгы көннәрнең кыскаруы тукталып, акрынлап озыная башлау чорына туры килә, һәм бу йола-күңел ачу чарасы сөрән салу белән башлана: Нәүрүз әйтегез / Нардуган керә дип автор йола бәйрәмне сүрәтли.

Татар халкының календарь йола-бәйрәмнәре арасында аерым урынны яз көне үткәрелә торган Сабан туе йоласы алып тора. Календарь йола буларак Сабан туе –ул кыр эшләренә чакыра һәм табигатьтә мул уңыш алуга юнәлдерелә. Сабан туе йолаларында мифологик ышанулар белән бәйле йола элементларын табу мөмкин түгел. Харрас Әюп «Сабантуй» (1971) шигырендә: Хәтфә кебек яшел аланнарга / Ачып салган халкым күңелен дип автор бу йола бәйрәмнең әхәмиятен арттыра. «Сабантуй булып узган мәйданда» (1982) шигырендә Сабантуй узган, әмма халыкның матур гадәт-йоласы күңелләрдә калган дигән фикер күзәтелә.

Йола фольклоры-ышануларны, шигъри сүзтезмәләрне, гамәлләрне, кешенең акыл тәҗрибәсен үзенә туплаган фольклор традицияләре системасының зур бер өлеше, мирасы. Әлеге мирастан файдалану 1960–1980 еллар шигъриятен халык иҗатына якынайта, халык иҗаты мотивларын яңарта.

ӘДӘБИЯТ

1. Урманчеев Ф.И. Татар мифологиясе. Энциклопедик сүзлек: 3 томда. Т. 2 (Д–С). Казан: Мәгариф, 2009. 110 б.

2. Мифы народов мира. Энцклопедия. М.: Сов.энциклопедя, 1980. Т. 2. 574 с.

3. Соколов Ю.М. Русский фольклор: учебное пособие. 3-е изд. / отв. ред. В.П. Аникин. М.: Изд-во Моск. ун-та, 2007. 152 с.

4. Татар халык иҗаты: 25 томда. Казан: Татар.кит.нәшр., 2021. 2 т.: Йола фольклоры. 2022. 541 б.

5. Бакиров М.Х. Татар фольклоры: югары уку йортлары өчен дәреслек. Казан: Мәгариф, 2008. 475 б.

УДК 811.512.145’367

Гыйниятуллина Лилия Миңнулла кызы
ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
Казан, Россия
Гиниятуллина Лилия Миннулловна
Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
Казань, Россия
Giniyatullina Liliya Minnulovna
G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art
of the Tatarstan Academy of Sciences
Kazan, Russia
E-mail: gin_liluk@mail.ru
Шәкүрова Мөслимә Мәгъсүм кызы
ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
Казан, Россия
Шакурова Муслима Магесумовна
Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
Казань, Россия
Shakurova Muslima Magesumovna
G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art
of the Tatarstan Academy of Sciences
Kazan, Russia
E-mail: vitorioarpad@gmail.com

СЫЙФАТЛАРНЫҢ ХАЛЫК ӘКИЯТЛӘРЕНДӘ ҺӘМ БӘЕТЛӘРДӘ КУЛЛАНЫЛЫШЫ

УПОТРЕБЛЕНИЕ ИМЕН ПРИЛАГАТЕЛЬНЫХ В НАРОДНЫХ СКАЗКАХ И БАИТАХ

USE OF ADJECTIVES IN FOLK TALES AND BAYITS

Аннотация. *Статья посвящена исследованию имени прилагательного в татарских народных сказках и баитах. Материалом для исследования послужили лексико-тематические разряды имени прилагательного. Имя прилагательное – несложная часть речи в тюркских языках. Интересна история формирования этой части речи и ее тематические разряды в сказках и баитах.*

Annotation. *The article is devoted to the study of the adjective in Tatar folk tales and baits. The material for the study was the lexical and thematic categories of the adjective. The adjective is a simple part of speech in the Turkic languages. The history of the formation of this part of speech and its thematic categories in tales and baits are interesting.*

Ключевые слова: *Татарский язык, имя прилагательное, тематические разряды, баит, сказка*

Key words: *Tatar language, adjective, thematic categories, bait, fairy tale*

Сүз төркемнәре арасында сыйфат аерым урын алып тора. Бу сүз төркеме укучыны бертөрлелектән, кабатлаулардан коткара, аралашу һәм тыңлаучыга уй-фикерне төгәл җиткерергә ярдәм итә. Лексик-семантик яктан сыйфат предметның билгесен белдереп, нинди? кайсы? кайдагы? кебек

сорауларга җавап булып килә. Сыйфатларның өйрәнелү тарихы, сөйләмдә белдергән мәгънә төсмерләре буенча сыйфатларны урынлы куллану белү – мөһим мәсьәләләрдән санала. Сыйфат сүз төркеме беренче грамматикаларда ук (И. Гиганов, М. Иванов, Г. Мәхмудов, К. Насыйри һ. б.) бүленеп чыгарыла [1: 67]. Октябрь кыйбласыннан соң М. Корбангалиев, Г. Сәгъди, Ж. Вәлиди, Г. Алпаров, Х. Бәдигый хезмәтләрендә сыйфатның төрләнешенә һәм ясалышына зур игътибар бирелә. 1913 елда Г. Ибраһимовның «Татар сарыфы» исемле китабы басылып чыга. Автор анда сыйфатларга туктала, аларны «күренешләрнең билгесен белдерүче мөһим кисәк» дип атый [2: 38]. Г. Алпаровның «Шәкли нигездә татар теле грамматикасы» гомуми тел белеме яссылыгында эшләнүе, сыйфатларны төркемнәргә аеруы ягыннан аерылып тора [3: 35]. Соңрак В.Н. Хангилдин, Д.Г. Тумашева, Ф.Ә. Ганиев, Ф.М. Хисамова, Ч.М. Харисоваларның китапларында сыйфатларның лексик-семантик, морфологик һәм синтаксик үзенчәлекләре, сыйфатларны тематик төркемләүгә кагылышлы мәсьәләләр өйрәнелгән [4: 35].

Рус тел белемендә күренекле тел галимнәреннән һәм педагогларыннан Ф.И. Буслаев, К.Д. Ушинский, А.М. Пешковский, А.А. Шахматов, Л.В. Щерба, В.В. Виноградов, А.А. Реформатский, А.В. Текучев, М.Т. Баранов, Н.М. Шанский һәм башкаларның хезмәтләре зур урын тота. Ф.И. Буслаевның 1844 нче елда «О преподавании отечественного языка» дигән китабы басыла. Ул дөрес язарга өйрәтүне ике дәвергә аера: «Берсе – әлифба өйрәнгән чорда, икенчесе – грамматика үзләштергәндә. Беренче дәвердә, ягъни әлифба өйрәнгән вакытта бала ничек ишетә, ничек әйтә – шулай язарга тиеш. Әгәр шул вакытта бала дөрес язарга өйрәнсә, күп сүзләрнең язылышын исендә калдырачак. Андый балаларга грамматика укытканда дөрес язарга өйрәтү җиңел һәм җайлы булачак. Икенче дәрәҗәдә инде укучы “ничек әйтсәң – шулай яз” дигән кагыйдә белән чикләнми, ә, грамматикага ияреп, сүзләрнең (мәсәлән, исемнәр, сыйфатларның) язылышы, төрләнеше, җөмләдә үзара бәйләнеше законнарына туры китереп яза», – ди Ф.И. Буслаев [5: 122].

К.Д. Ушинский да грамоталы булуның иң мөһим шарты – грамматиканы белү дигән карашта була, шуның белән бергә, Ф.И. Буслаев шикелле үк, күнегүләр тәкъдим итәргә кирәклеген әйтә, һәр сүз төркеменең дөрес язылышын аңлата [6: 122].

Профессор А.М. Пешковский исә үз хезмәтләрендә дөрес язарга өйрәткәндә яза торган сүзләрнең – исемнәр, сыйфатлар, фигыльләрнең мәгънәсен, аның формасын аңлап эш итүнең мөһимлеген, грамматик анализның роле зур булуны билгеләп үтә [7: 15].

Л.З. Шакирова «Обучение русскому языку в татарской школе: теория и практика» китабында грамматиканың ролен ачыклый, сөйләшергә, аралашырга өйрәтүдә сыйфат сүз төркеменең практик әһәмиятен күрсәтә: *На лугу стоит* ***зеленый*** *одинокий клен. – На лугу стоит* ***зеленом*** *одинокий клен* (прилагательные **зеленый, зеленом** согласуются с существительными клен, (на) лугу) [8: 175].

Димәк, татар һәм рус галимнәре, педагогларының күпчелеге дөрес итеп сөйләшергә, язарга өйрәтүнең сыйфатларга да бәйле булуын әйтәләр. Сыйфатларда предметларның билгесе төп үзенчәлек булып карала. Мәсәлән, *кара каш, күк күз, ак сакал, озын кул* һ. б. Бу очракта аларда

сурәтләү функциясе аеруча калку күренә. Татар халык әкиятләрендә, бәетләрендә сыйфатның лексик-тематик төркемнәрен карап үтик.

1. Тышкы кыяфәтне, характерны, аң-белем дәрәҗәләрен белдергән сыйфатлар: *гүзәл,* мәхәббәтле, *чибәр, матур, зифа, сөйкемле, күркәм, үткен, баһадир, таза; явыз, куркак, батыр; акыллы, надан, башсыз: Чәршәмбе көн кер юадыр, атна кичкә туй икән;* ***Озын чәчле, кара кашлы, нечкә зифа буйлы*** *икән* («Гайшә матур белән гашыйк Камил бәете», 188 б.) [10]. *Чирмешәннең һәр өендә кайнар яшьләр актылар;* ***Күркәм, зифа*** *егетләрне сугышка озаттылар* («Тыл бәетләре», 241 б.); *Карлыгачсылу –* ***үткен*** *кыз,* ***матур*** *кыз,* ***батыр*** *кыз: «күлгә казлар төшкән, атып алыйм әле» дип, Алпамшаның ук җәясен алып казга ата* («Алпамша», 57 б.) [9]. *Падишаны үтерергә киңәшләр; Үзенең* ***явыз*** *хатыны һәм сенатлары* («Екатерина напша бәете», 34 б.); ***Зифа*** *буем үсеп җиткәч, әткәй бирде наданга;* ***Надан*** *егетләр саналыр шайтаннан да яманга* («Наданга бирелгән кыз бәете», 157 б.).

2. Төсне белдергән сыйфатлар: *ак, кара, чем-кара, кызыл, зәңгәр, ал, алсу, сары, яшел:* ***Сары*** *атым бәйләп куйдым, салкын су алсын диеп; Туган илне ташлап киттем, башым гыйбрәт алсын дип* («Беренче Бөтендөнья сугышы бәетләре», 73 б.); *Яшь хатын балыкларны тагын да* ***кара*** *күмергә әйләндереп чыгып китә* («Алтын чүлмәк», 140 б.).

3. Тәмне, урын-вакыт, күләм-дәрәҗәләрне белдергән сыйфатлар: *татлы, баллы, тозлы, озын, биек, ерак, куе, калын* һ. б.: *Чәй янында бал булса, бал шикәрдән* ***татлырак*** («Чәйне мактау», 185 б.); *Алда шикәр,* ***куе*** *каймак, шоколад та мармелад* («Чәйне мактау», 185 б.); ***Биек*** *тауның башында борылып үскән бер богдай* («Бән китмәдем базарга», 201 б.) һ. б.

Бәетләрдә сыйфатларны мул куллану татар сөйләменең бай, аһәңле, хисле булуын күрсәтеп тора:

Чигә башлаган чиңүең калган,
Тегә башлаган тегүең калган.
Баскан эзләрең, әйткән сүзләрең,
Зәңгәр күзләрең, нурлы йөзләрең («Хәсрәтем авыр», 258 б.)

Ап-ак итеп карлар яуган биек тауның башына.
Үзем үлдем, кайгым калды атам-анам башына
(«Шофер Әнәс бәете», 252 б.)

Пейзажны детальләп тасвирлаганда да бәетләрдә сыйфатлар күпләп кулланыла, табигать күренешләре дә геройлар белән аваздаш кебек:

Иртән тордым, тышка чыктым, ***салкын*** *гына җил исә,*
Туган *илләр искә төшкәч, йөрәк бәгыремне кисә* («Рус-төрек сугышы бәете», 44 б.).

Тулган *айлар тотылды* ***газиз*** *шәгъбан аенда,*
Якты *көннәр* ***караңгы*** *булды без сугышкан чагында* («Рус-төрек сугышы бәетләре», 41 б.).

Шулай итеп, сыйфат сүз төркеме сөйләмнең стилистик яктан җыйнак һәм дөрес төзелүенә ярдәм итәләр һәм урынсыз кабатлаулардан коткаралар. Әдәби әсәрләргә анализ ясаганда сыйфатларның сөйләмдә тоткан урыны

бик зур булуына игътибар итәсең. Алар геройларның фикерен тулыландыруда, хис-тойгыларны арттыруда мөһим роль уйныйлар.

Тарихи вакыйгалар һәм шәхси фаҗигаләргә багышланган бәетләрнең нигезендә җәфа чиккән татар солдаты туган илен, авылын, гаиләсен, ата-анасын сагына, сагынганда айга карый, Дунай елгасына карап, челтерәп аккан салкын чишмәләрне искә төшерә, моңлана. Болар барысы да телнең лексик, грамматик һәм стилистик мөмкинлекләре гаять күп булуын күрсәтеп тора.

Нәтиҗәләр ясап шуны әйтәсе килә: халкыбызның поэтик иҗатында әкиятләр,бәетләр, мөнәҗәтләр иң бай һәм иң мөһим жанрлардан санала. Мәктәптә бу жанрларны өйрәнү укучының зәвыгын, әдәби тел байлыгын үстерә. Фольклор текстларына лингвистик анализ ясау укучыны халык авыз иҗаты белән тагын да кызыксындырып җибәрер, бик сирәк очрый торган сүзләр, сүзтезмәләр, чагыштырулы төзелмәләр, фигыльләр белән таныштырырга мөмкинлек бирер иде (*ике кабып бер йоту, гәүдәсе чуклы булыр, «әүвәл, әүвәл заманда... булган, ди, торган. ди»* һ. б.).

Халык авыз иҗаты әсәрләренең теле сыйфатларның күплеге белән дә характерлана. Матур әдәбият телен тикшергәндә, сыйфатлар өстәмә бизәк, колорит тудыралар. Сыйфатлар сәнгати текстның идеясен укучыга җиткерүдә, персонажны теге яки бу дәрәҗәдә характерлаганда мөһим урын билиләр. Алар әдәби телдә еш очрый торган кешедәге уңай сыйфатларны калку итеп күрсәтүгә хезмәт итәләр. Бу сүз төркеме сөйләмне баетуда, аны тәэсирлерәк һәм үтемлерәк итүдә, әдәби әсәр стиленә сәнгатьлелек бирүдә, фикерне тулырак ачуда, һичшиксез, мөһим роль уйныйлар. Һәр телнең байлыгы иң беренче чиратта сыйфатларның күплеге белән билгеләнә. Бер үк төзелмәләрне кулланмау сөйләмне җыйнак, аһәңлерәк итәргә, бертөрлелектән котылырга, фикерне төгәл, анык итеп формалаштырырга мөмкинлек бирә.

ӘДӘБИЯТ

1. Мифтахова И.Г. История татарских грамматик: исследование именных частей речи (XIX – начало XX в.). Ч. I. Казань: Хәтер, 1998. 168 с.

2. Ибраһимов Г. Татар сарыфы / Г. Ибраһимов; Ф.С. Сафиуллина, Б.Э. Хәкимов (төз.). Казан: Казан ун-ты нәшр., 2003.118 б.

3. Алпаров Г. Сайланма хезмәтләр. Казан, 1945. 195 б.

11. Шәкүрова М.М. Укырга-язарга өйрәтүдә Г. Ибраһимовның методик системасы // Фәнни Татарстан. 2024, № 4 (44). С. 102–107

4. Буслаев Ф.И. О преподавании отечественного языка. М.: Просвещение, 1992. 512 с.

5. Ушинский К.Д. Собр. соч.: Т. 7. М.-Л.: Изд-во АПН РСФСР, 1949. 358 с.

6. Пешковский А.М. Русский синтаксис в научном освещении. 1-е изд. М.; Л.: Госиздат, 1914. 37 с.

7. Шакирова Л.З. Основы методики преподавания русского языка в татарской школе. Казань: Татарское кн. изд-во, 1990. 278 с.

8. Татар халык иҗаты. Әкиятләр. Казан: Татарстан Республикасы «Хәтер» нәшрияты, 2007. 287 б.

9. Татар халык иҗаты. Бәетләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. 351 б.

УДК 81`2

Демидова Евгения Евгеньевна
АНО ВО «Международный гуманитарный университет
им. П.П. Семенова–Тян-Шанского»
Санкт-Петербург, Россия
Demidova Evgenia Evgenievna
International Humanitarian University
named after P.P. Semenov–Tyan-Shansky
Saint-Petersburg, Russia
E-mail: mgu-spb@bk.ru

ТАТАРСКИЕ ПОСЛОВИЦЫ И ПОГОВОРКИ О ВЛАСТИ И СИЛЕ

TATAR PROVERBS AND SAYINGS ABOUT POWER AND STRENGTH

Аннотация. *Цель статьи – описать пословицы и поговорки татарского народа в сопоставлении с русскими, в которых затрагиваются аспекты власти и силы. В научной литературе не отмечены работы на данную тему, в этом видится научная новизна исследования. Было выявлено 5 групп татарских пословиц и поговорок, в которых: 1) смысл и образы власти и силы полностью совпадают с русскими аналогами; 2) по смыслу частично совпадают, но используемые образы разные; 3) образы частично совпадают, но смысл паремий иной; 4) ни смысл, ни образы не совпадают; 5) безэквивалентные пословицы и поговорки. Паремиологический фонд отображает представления народа о силе и власти, передаваемые через зооморфные и антропоморфные символы, основная часть которых выражает национально-культурную специфику. Зооморфными символами власти татарского народа являются баран и рыба, русского – медведь и рыба.*

Annotation. *The purpose of the article is to describe proverbs and sayings of the Tatar people in comparison with Russian ones, which touch upon aspects of power and strength. There are no works on this topic in the scientific literature, which is the scientific novelty of the study. Five groups of Tatar proverbs and sayings were identified, in which: 1. the meaning and images of power and strength completely coincide with Russian analogues; 2. the meaning partially coincides, but the images used are different; 3. the images partially coincide, but the meaning of the paremias is different; 4. neither the meaning nor the images coincide; 5. proverbs and sayings without equivalents. The paremiological fund reflects the people's ideas about power and authority, transmitted through zoomorphic and anthropomorphic symbols, the main part of which expresses national and cultural specificity. The zoomorphic symbols of power of the Tatar people are a ram and a fish, of the Russian people – a bear and a fish.*

Ключевые слова: *паремии, языковая картина мира, лингвокультура*

Key words: *proverbs, language picture of the world, linguoculture*

Введение. Актуальность проводимого исследования заключается в определении сходства и национальной специфики отображения сфер власти и силы в татарской и русской лингвокультурах. Материал исследования взят с сайтов «Миллиард.татар» и «Национальный акцент» [Поговорки на татарском языке: интернет-ресурс; Топ-20 татарских пословиц и поговорок: интернет-ресурс]. Основными методами исследования выступают сравнительный, интерпретативный и описательный.

Литературный обзор. В научной литературе отсутствуют работы, в которых анализируются пословицы и поговорки татарского и русского народов в аспекте власти и силы. В этом состоит научная новизна

исследования. Символы тюркских лингвокультур рассматривались учеными: в хакасской обрядовой практике [1: 110–121], на материале башкирского языка [2: 235–241], в культуре монгольского народа [4: 126–138].

Результаты и обсуждения. Власть осмысляется и как право, как управление, как политика, и как господство. Власть осуществляют государственные органы. Наделенный властью повелевает людьми и распоряжается делами госструктур [7: 184]. Власть – это сила и могущество, и сила дает власть.

Пословицы и поговорки на заданную тему силы и власти можно разделить на пять групп.

1 группа. Пословицы и поговорки о власти и силе, полностью совпадающие по смыслу и образам с русскими аналогами.

В русской и татарской лингвокультурах власть ассоциируется с человеком – управленцем (метонимическая связь). Отсюда использование соматического кода для передачи образа управления: *глава* (государства, муниципалитета и т. д.). Однако соматический код может быть не только антропоморфным, но и зооморфным:

тат. *Балык башыннан чери*; рус. *Рыба гниет с головы*.

Зооморфный соматический код обусловлен древними воззрениями о матери-рыбе и что «души нерожденных обитают в воде». Рыба «ассоциируется с богинями луны, материнством и деторождением. Рыба служила также в качестве пищи на всех празднествах, посвященных Великой Матери и поедалась в ее день – пятницу» [3].

Исполнительная власть заключается в жёсткой иерархии и правилах управления и подчинения. Относительно религиозной власти – правила мирской жизни в ней не применяются – перед высшей (божественной) властью все равны:

тат. *Син дә мулла, мин дә мулла, атка кем печән сала* «Ты мулла, я мулла, кто сено лошади насыплет?»; рус. *Ты мулла, я мулла, а кто накормит коня*?

2 группа. Пословицы и поговорки о силе и власти, частично совпадающие по смыслу, но не по образам.

Охотничий код русской лингвокультуры меняется на доместический код татарский лингвокультуры при передаче смысла одоления врага: для русских в пословице фиксируется совет не устраивать врагам ловушек, для татар – совет вовремя укрыться в непредсказуемом месте:

тат. *Дошманыңа кое казыма, үзең төшәрсен* букв. «Не рой врагу колодец, дай себе в него упасть»; рус. *Не рой другому яму, сам упадешь*.

Обычная стратегия получения управления в свои руки: добиться власти посулами богатства:

тат. *Агыйделнең аръягында бер энәгә бер сыер, барып карасаң, берни дә юк* букв. «По ту сторону забора стоит корова, но если пойти и посмотреть, там ничего нет»; рус. *По ту сторону Белой за иголку, якобы, корову дают, а сходишь – нет ничего*.

В татарской лингвокультуре для передачи этого смысла используется образ коровы, в русской – помимо этого образа, отступающего на второй план, первичен артефактный образ (иглы).

Вариантами, передающими нужный смысл, служат такие русские пословицы:

У соседа и трава зеленее;
Хорошо там, где нас нет.

3 группа. Пословицы и поговорки о силе и власти, частично совпадающие по образам, но не по смыслу.

В борьбе нельзя показывать свою слабость. В татарской и русской лингвокультурах воин скрывает свою физическую уязвимость до конца битвы и силён духом. Именно в духе, терпении и выносливости заключается сила победителя:

тат. *Авызың тулы кан булса да, дошманың алдында төкермә* буквально переводится так: «Даже если рот твой полон крови, не плюй перед врагом своим»; рус. *Если истекаешь кровью, все равно не показывай свою слабость перед врагом*.

Правовая сфера в татарской лингвокультуре обусловлена совместным проживанием на одной территории с представителями других народов, что отразилось на политике добрососедства:

тат. *Күрше хакы – Алла хакы* букв. «Долг соседа – долг Бога»; рус. *Право соседа – право Бога*.

В русской лингвокультуре акцентируется смысл права, в татарской – долга. В двух лингвокультурах правовая сфера диктуется свыше – от Аллаха и Бога. Образ вертикали власти общий, но это – власть не социальная, а религиозная.

4 группа. Пословицы и поговорки, не совпадающие ни по смыслу, ни по образам, передаваемым в них.

Экономическая власть состоит в перераспределении ресурсов. Местные власти не знают, как сверху перераспределяются денежные потоки:

тат. *Ашаган белми, тураган белә* букв. «Тот, кто ест, не знает, а тот, кто стоит, знает»; рус. *Знает не тот, кто ест, а тот, кто нарезает* (готовит еду).

Вертикаль власти – устойчивый образ в русской лингвокультуре. Скрытый образ вертикали власти совпадает, а образ повара или официанта, подающего еду, национально специфичен.

Зооморфный код характерен для описания сферы распределения власти:

тат. *Ике тәкә башы бер казанга сыймый*, что буквально переводится как «Две бараньи головы не поместятся в один котел»; рус.: *Два медведя в одной берлоге не уживутся*.

В русской лингвокультуре медведь – царь лесной, в английской лев – царь зверей, в татарской баран – национальный символ власти. Здесь следует дополнить, что в русской лингвокультуре зооморфные символы используются для передачи смысла социальной власти; для описания внутрисемейных отношений применимы иные – антропоморфные – образы:

рус. *Две хозяйки на одной кухне не уживутся*.

5 группа. Пословицы и поговорки, которым нет эквивалента в русском языке.

Для татарского народа ценна идея совместного проживания нескольких поколений одной семьи и всего народа в целом:

тат. *Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар* букв. «Кто отделится, того съест медведь, кто разделится, того съест волк».

Можно предположить, что частично передает смысл татарской пословицы русская. *Один в поле не воин*. Татарская пословица широко

использует зооморфный код лингвокультуры, смысл пословицы отсылает не только к идее единения и консолидации сил, но и идее сохранения жизни и достояния всего народа.

тат. *Хәйләсез дөнья файдасыз* букв. «Мир без фокусов/ трюков бесполезен», передаваемый смысл: *Без хитрости этот мир не в радость*.

Утилитарный смысл пословицы о манипуляциях и цирковом искусстве – искусстве создания иллюзий и управления вниманием зрителей трудно передаваем на русский язык, что обусловлено историческими реалиями. В русской лингвокультуре скоморошество стало под запретом со времён Ивана Грозного.

Государственная власть крепка службой – работой на благо страны:

тат. *Ватанга хезмәт итү – безнең бурыч* букв. «Служение стране – наш долг».

Отсутствие указаний и распоряжений в приоритете для татарского народа, даже если на кону будет достаток и сытая жизнь:

тат. *Ач тамагым, тыныч колагым* букв. «Голодное горло, тихие уши» или «Голодно брюхо (глотка), да уши спокойны». Передаваемый смысл: Лучше жить впроголодь, но без власти и указаний.

Власть понимает, что народ не должен быть голодным:

тат. *Ачның ачуы яман* букв. «Гнев голодного плох». Смысл: Страшен гнев голодного, который поднимет бунт.

Заключение. Как показало проведенное сопоставление, сфера силы и власти в русской и татарской лингвокультурах частично совпадает, на что указывают схожие образы и передаваемые посредством них смыслы. В описаниях этой сферы жизнедеятельности частотны зооморфные образы, часть которых передает забытые символы культуры Великой Богини-матери, скрываемой в образе рыбы, а другая их часть обусловлена культурными стереотипами (баран – для татарского народа, медведь – для русского народа и др.). В татарской лингвокультуре ценится сфера досуга и выдумки для того, чтобы расцветить жизнь окружающих.

ЛИТЕРАТУРА

1. Бурнаков В.А. Баран в традиционной обрядности хакасов, связанной с жизненным циклом человека: свадьба и похороны (конец XIX – середина XX века) // Вестник НГУ. Серия: История, филология. 2022. Т. 21, № 3: Археология и этнография. С. 110–121. DOI 10.25205/1818-7919-2022-21-3-110-121.

2. Илимбетова А.Ф. Символика овцы (барана) в фольклоре, обрядах и обычаях башкир // Самарский научный вестник. 2021. Т. 10, № 4. С. 235–241. DOI: 10.17816/snv2021104217.

3. Краткая энциклопедия символов [Электронный ресурс]. URL: http://www.symbolarium.ru/index.php/Щука,_рыба (дата обращения: 08.08.2024).

4. Очир-Горяева М. А. О значении коня и овцы в обрядовой культуре кочевников // Монголоведение. 2011. № 5. С. 126–138.

5. Поговорки на татарском языке. [Электронный ресурс]. URL: https://nazaccent.ru/phrase/pogovorki-na-tatarskom-yazyke/ (дата обращения: 10.08.2024).

6. Топ-20 татарских пословиц и поговорок [Электронный ресурс]. URL: https://milliard.tatar/news/top-20-tatarskix-poslovic-i-pogovorok-173 (дата обращения: 10.08.2024).

7. Словарь русского языка: в 4 т. Изд. 2-е, испр. и доп. М.: Русский язык, 1981. Т. I. 696 с.

УДК 81-26

Денмөхәммәтова Эльвира Николаевна
Казан федераль университеты
Казан, Россия
Денмухаметова Эльвира Николаевна
Казанский федеральный университет
Казань, Россия
Denmukhametova Elvira Nikolayena
Kazan Federal University
Kazan, Russia
E-mail: elvir25@mail.ru

ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ГАРӘП АЛЫНМАЛАРЫ ҺӘМ ТӨРКИ СҮЗЛӘР СИНОНИМЛЫГЫ

СИНОНИМИЯ ТЮРКСКОЙ ЛЕКСИКИ И АРАБСКИХ ЗАИМСТВОВАНИЙ В ТАТАРСКОМ ЯЗЫКЕ

SYNONYMY OF TURKIC VOCABULARY AND ARABIC BORROWINGS IN THE TATAR LANGUAGE

Аннотация. *В работе рассматриваются вопросы синонимии арабских слов и тюрко-татарской лексики. Опираясь на словарь синонимов татарского языка, изучаются синонимические ряды, куда входят арабские заимствования. Выявляются особенности арабизмов в составе синонимических рядов как доминанты, характеризуется активность их функционирования в татарском литературном языке и языке фольклора.*

Annotation. *The paper examines the issues of synonymy of Arabic words and Turkic-Tatar vocabulary. Based on the dictionary of synonyms of the Tatar language, synonymous series, which include Arabic borrowings, are studied. The features of Arabisms in the composition of synonymous series as a dominant are revealed, the activity of their functioning in the Tatar literary language and the language of folklore is characterized.*

Ключевые слова: *татарский литературный язык, лексика, синонимия, арабские заимствования, доминанта, язык фольклора*

Keywords: *Tatar literary language, vocabulary, synonymy, Arabic borrowings, dominant, folklore language*

Телдә синонимик мөнәсәбәттә йөргән сүзләр никадәр күп булса, бу тел шулкадәрле үскән, камилләшкән, бай санала. Бу критерийдан чыгып карасаң, татар теле – дөнья телләре арасында иң бай телләрнең берсе. АШ. Ханбикова һәм Ф.С. Сафиуллиналар тарафыннан 1999 елда төзелгән «Синонимнар сүзлеге»ндә үк 25 меңгә якын синонимик берәмлекне берләштергән 4500 дән артык оя тупланып бирелгән була [1: 3]. Сүзлеккә җирле сөйләм берәмлекләре, диалекталь сүзләр һәм соңгы елларда телгә кабул ителгән алынмалар, сөйләмдә барлыкка килгән яңа сүзләр теркәлмәгәнлекне исәпкә алганда, мондый төр сүзләрнең күләме шактый артуын күзалларга мөмкин. Алар төрле стильләрдә, төрле өлкәләрдә кулланыла торган мәгънәдәш сүзләрне тәкъдим итәләр, тел байлыгын тулырак күзалларга мөмкинлек тудыралар.

Шунысы кызыклы: эзләнүләр күрсәткәнчә, «Синонимнар сүзлеге»ндә урын алган 4500 дән артык синонимик ояның 1287 се составында гарәп яки фарсы алынмалары бар; шуларның 61 оясы бары бу тел сүзләреннән генә тора. Бу хәл гарәби һәм фарсы чыгышлы берәмлекләрнең татар теленең лексик фондында зур урын биләвен күрсәтә, синонимиядә тотрыклы үз урыны барлыгын раслый.

Галимнәр тарафыннан төрле аспектларда өйрәнелә, сүзлекләргә теркәлеп килә торган синоним берәмлекләрнең бүгенге әдәби телдә кулланылышын күзәтү татар теленең актив лексикасы үзенчәлекләрен ачыкларга ярдәм итә. Бу максаттан чыгып, төрки-татар чыгышлы сүзләр һәм аларның гарәби тамырдан барлыкка килгән мәгънәдәш берәмлекләренең татар мәкальләрендә һәм әдәби текстларда кулланылыш үзенчәлекләрен тикшерелде. Чыганак вазифасын Н. Исәнбәтнең «Татар халык мәкальләре» җыентыгы [2–4] һәм tatzet платформасында урнаштырылган Татар матур әдәбияты корпусында [5] урын алган материаллар тәшкил итте.

Алынма сүзләрнең күпчелеге бирелә торган төшенчәнең татар телендә төрки чыгышлы эквиваленты булмаган очракта кулланыла, төрки-татар сүзләре белән синонимик мөнәсәбәттә торган лексик берәмлек тәшкил итә торганнары да бар. Паремияләрнең бер төре булган мәкальләрне туплаган әдип Н. Исәнбәт мондый күренешне мәкальнең аерым төбәкләрдәге әйтелеш үзенчәлекләре белән аңлата һәм, беренче мәкальне биргәннән соң, аның төрле вариантларын төрдәшләре баш астында тәкъдим итүне кулай саный. Галим фикеренчә, «төрдәш мәкальләрдә форма һәм эчтәлек ягыннан уртаклыклар булса да, мәгънә төсмерләнешендә бик әһәмиятле төгәлләмә һәм аермалар бар. Бу төрдәшләрдә мәкальләрнең тарихи эволюциясен күрсәтә торган кызыклы төгәлләмәләр дә очрый» [4: 253–254]. Мондый берәмлекләрне хәзерге матур әдәбият әсәрләре җирлегендә дә очрату исә, татар телелексик фондының тотрыклылыгын да һәм үсеш тенденцияләрен дә билгели.

Әдәби телдә, сөйләм телендә синонимик парлар еш файдаланылсалар да, мәкальнең махсус төзелеше, яңгыраш үзенчәлекләре мондый берәмлекләрнең кулланылыш мөмкинлеген чикли. Шул сәбәпле афористик тәгъбирләрдәге гарәп һәм фарсы берәмлекләренең һәркайсы мәгънәви йөге, аһәңлелеге һәм әйләнә-тирәсендәге сүзләргә охшашлыгы, ятышлыгы ягыннан да сайланып алына.

Телдә, сөйләмдә синонимнар барысы бергә йөрмиләр; һәр сүз мәгънәсе, үзенчәлекләре белән үз урынында кулланыла. Бары синонимнарны өйрәнгәндә генә, аларны бергә туплап, мәгънәдәш сүзләр, сөйләүченең сүзлек запасы рәвешендә, тулы һәм анык мәгънәле сүзне сайлап алу өчен чыганак хезмәтен үти.

Синонимнарның төп функциясе һәр очракта фикерне тулырак һәм аныграк бирү дип билгеләнә. Тикшерелә торган материалда төрле телдән кергән мәгънәдәш сүзләр урын алганлыктан, берәмлекләр арасында идеографик синонимнар мәкальдә ешрак очрыйлар һәм паремияләрнең сөйләү моментына туры килерлек кирәкле төсмер белән әйтелү мөмкинлеген киңәйтәләр. Матур әдәбият текстларында исә мондый чикләүләр күренми, автор сөйләмен бирүдә дә, персонаж сөйләмендә дә мәгънәдәш сүзләр төрлечә кулланылалар.

3. Сафиуллина Ф.С. Башы бер, мәгънәсе мең... // Тел дигән дәрья бар... Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. 136 б.

4. Ситдыкова А.Ф. Когнитивное исследование цветового пространства в татарском языке : автореф. дис. ... канд. филол. наук : 10.02.02. Казань. 2013. 22 с.

5. Ситдыкова А.Ф. К вопросу определения базового концепта «төс» и его семантического поля на примере цветообозначений в татарском языке // Филологические науки. Вопросы теории и практики. 2013. № 5. С. 163–168.

6. Усманова Л.А. Функциональные особенности цветообозначений в русском и татарском языках (на материале языка художественных произведений) // Научный Татарстан. 2009. № 1. С. 182–186.

7. Фахретдинов Р.М. Некоторые особенности цветовосприятия во французском и татарском языках // Казанский лингвистический журнал. 2018. № 3. С. 31–41.

УДК 811.512.

Кадирова Энҗе Хәнәфи кызы
ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
Казан, Россия
Кадирова Энзе Ханафиевна
Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
Казань, Россия
Kadirova Enze Khanafievna
G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art
of the Tatarstan Academy of Sciences
Kazan, Russia
E-mail: enge@inbox.ru

XV–XVI ГАСЫРЛАР ИСКЕ ТАТАР ЯЗМА ӘДӘБИ ТЕЛЕНДӘ АКЫЛ ЭШЧӘНЛЕГЕН БЕЛДЕРӘ ТОРГАН ФИГЫЛЬЛӘРНЕҢ КУЛЛАНЫЛЫШЫ

ПРИМЕНЕНИЕ ГЛАГОЛОВ, ВЫРАЖАЮЩИХ УМСТВЕННУЮ ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ В СТАРОТАТАРСКОМ ПИСЬМЕННОМ ЛИТЕРАТУРНОМ ЯЗЫКЕ XV–XVI ВЕКОВ

THE USE OF VERBS EXPRESSING MENTAL ACTIVITY IN THE OLD TATAR WRITTEN LITERARY LANGUAGE OF THE 15TH–16TH CENTURIES

Мәкалә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 16.07.2024 ел № 565 Карары нигезендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе ярдәмендә әзерләнде

Статья подготовлена при поддержке Академии наук РТ по Постановлению КМ РТ № 565 от 16.07.2024

Аннотация. *Глагол занимает центральное место в лексической системе татарского языка. Изучения глагола в функциональном аспекте помогает раскрыть семантические закономерности и их способы употребления в тексте.* Целью данной статьи является выявление семантики глаголов, выражающих умственную деятельность в старотатарском письменном литературном языке *XV–XVI веков. Особенно мало изучены памятники средних веков, что делает данное исследование актуальным и необходимым.*

Annotation. *The verb occupies a central place in the lexical system of the Tatar language. The purpose of the article is to identify the semantics of verbs expressing mental activity in the Old Tatar written literary language of the 15th–16th centuries. Monuments of the Middle Ages have been studied especially little, which makes this study relevant and necessary. Studying the verb in the functional aspect helps to reveal semantic patterns and their methods of use in the text.*

Ключевые слова: *Татарский язык, старотатарский язык, глагол, Казанское ханство, семантические классы лексики*

Keywords: *Tatar language, Old Tatar language, verb, Kazan Khanate, semantic classes of vocabulary*

Текстны аның составындагы лексемалар күзлегеннән өйрәнү әсәрнең мәгънәсен җентекле аңларга мөмкинлек бирә. Урта гасыр истәлекләре бу юнәлештә аеруча аз өйрәнелгән булуы хезмәтнең актуальлеген билгели. Тикшеренү объекты сыйфатында фигыльне сайлау очраклы түгел, чөнки функциональ аспектны өйрәнү тел берәмлекләренең семантикасын аңлау һәм билгеләү һәм текстның мәгънәсен ачыклау өчен мөһим. Мәкаләдә Казан ханлыгы чоры язма истәлекләрендә теркәлгән әлеге төркемгә караган лексемаларның семантикасы, аларның хәзерге татар әдәби телендә кулланылу үзенчәлекләре ачыклана. Өйрәнү материаллары булып XV–XVI йөзләрдәге иске татар язма истәлекләренең текстлары тора. Тикшеренү өчен Мөхәммәдьяр поэмалары һәм шигыре, Колшәриф, Өмми Камал әсәрләре, «Кыз хикәяте», «Сираҗел-колуб», «Зафәрнамәи вилаяте Казан», «Могҗизнамә» истәлекләре текстларыннан акыл эшчәнлеген белдерә торган фигыльләр сайлап алынды. Анализ вакытында, борынгы төрки чор, урта гасыр сүзлек фондын чагылдырган сүзлекләрдән һәм татар теленең төрле сүзлекләреннән алынган мәгълүматлар кулланылды.

«Татар грамматикасы»нда тәкъдим ителгән классификациядә эш-гамәл фигыльләренең бер төркеме буларак, акыл эшчәнлеген белдерә торган фигыльләр карала. Алар а) фикерләү, ә) фикерләү нәтиҗәсен белдерүче, б) гөман итү, в) төрле өлкәләргә караган акыл эшчәнлеген белдерә торган фигыльләргә бүленәләр [9: 96].

Акыл эшчәнлеген белдерә торган фигыльләрдән Казан ханлыгы чоры язма истәлекләрендә *уйлау, төшенү, аңлау, фикер итү, фикер кылу, фикер әйләү, фикер дөшү, әндиша кылу, белү, үгрәтү, тәфәккергә бару* ‘фикерләү, уйлау’ лексемалары очрый.

Казан ханлыгы чоры язма истәлекләреннән Мөхәммәдьярның «Төхфәи мәрдан» поэмасында, «Сираҗел-колуб» әсәрендә, Өмми Камал иҗатында акыл эшчәнлеген белдерә торган лексемалардан сагын- / сакын- фигыле очрый. Әлеге лексема бу чорда ук күпмәгънәле. *Кем үзүңә ни теләсәң, үзгәгә аны сакын, Йыгълатыб йемә үксүзнүң хәкын* [6: 54]; *Теләген табмагай һәргиз бәд әндиш, һәр ни сагынса – кәлүр үзенә биш* [6: 53]; *Сагынгайлар мөхибби бинәуаны, Дога берлә сәүегдергәйләр аны* [6: 228]; *Һәм бери аның сакынмакдур йима Шул фигыльләрдән кә кемсә энҗене* [12: 336] кебек мисалларда сакын- фигыле ‘уйларны кемгә яки нәрсәгә дә булса юнәлдерү, уй йөртү, фикерләү’ мәгънәсендә килә. Алдагы очракта бу лексема

‘алдагы уйлауларының нәтиҗәсеннән туган уйлауны белдерә’ һәм уйлауның объекты булып, дип сүзе белән бәйләнгән исем яки иярчен җөмлә тора: *Өчәгүси булар худ мәгзул китти, Аңа тиб сағынды, үзүнгә йетти* [6: 53]; Андаг сакынгайлар һәркем дә: «Кем бу сурны ялгуз мәнем колакымга өрделәр, булгайлар», – диб [8: 29]. *Атасы андаг сакынур ирде: углум җадулык үгрәнүр диб* [8: 74]. Сакын фигыленең этимологиясенә килгәндә, Дж. Клаусон сак- сүзе ‘уйлау’ яки ‘берәр нәрсә турында уйлау яки борчылу’ дигәнне аңлата, һәм бу фигыльгә юнәлеш кушымчасы өстәлгән дип саный [13: 812]. Борынгы төрки сүзлектә ‘уйлау, санау, нәрсәдер дип белү’ мәгънәсендә saq- формасы теркәлгән [1: 486]. Борынгы бу фигыльнең кайтым юнәлеше кушымчасы алган сакын- формасы урта гасыр әдәбияты ядкәрләрендә дә урын ала [2: 79].

Казан ханлыгы чоры чыганакларында ‘уйларны кемгә яки нәрсәгә дә булса юнәлдерү, уй йөртү, фикерләү’ мәгънәсендә уйла фигыле бары тик Кол Шәрифнең «Кыйссаи Хөбби Хуҗа» әсәрендә очрый: *Ауга чыкган Хөббигә өлеш-бәхеш онутды. Шул пәрәстә ир Хөбби бер мәгънәни уйлады* [3: 46]. «Кыз хикәяте» истәлегендә *Торды йегет, күр, нә дир атасына: «Бер фикер дөшде үгүмә уш йәнә* [4: 50] мисалы бар. Борынгы төрки сүзлектә ö- фигыле белән бәйле берничә сүз күрсәтелгән: ög ‘акыл, уй’; ög- ‘акыл, уй’ «мактау, мактау»; ögä ‘акыл, уй’ «акыллы»; ogälä- ‘акыллы дип атау’; ögdi, ögdü ‘мактау’; ögä ‘зирәк’; ögdüči ‘мактауxs’ h. б. [1: 378–379].

Күпчелек чыганакларда уйлау, сакыну фигыльләренә синоним буларак, фикер лексемасы ярдәмендә ясалган фикер итү, фикер кылу, фикер әйләү, тәфәккергә бару кушма фигыльләре килә: *Анда әйдемсә сүзүми алмадың, Фикер итеб, қолақыңа салмадың* [6: 71]; *Кыз калды анда каты әндишдә, Мәсьәлә фикер идүбән әйтә* [4: 74]; *Тәфәккергә барды, ул заман Җәбраил галәйһиссәлам хәзер булды* [8: 72]; *Хәрамә бакмады һәргиз газабин фикер идүбән тиз Хәлялдән әилде пәрһиз хисабындан хәзәр кыйлды* [12: 288]. Әмма, мисаллардан күренгәнчә, бу фигыльләр кемдер, нәрсәдер турында тирәнтен уйлауны аңлата.

Алдагы «Кыз хикәяте»ннән китерелгән мисалда хәзерге татар телендәге уй сүзе урынына әндиш лексемасы кулланыла, ә «Сираҗел-колуб» әсәрендә уйла- функциясендә әндиша кылу фигыле килә: *Габдулла күрде, әндиша кылды* [8: 74]; *Ул ишәккә менүб, Бабилдин Шамга килүб, бер вайранә әйләде, күңеле берлә әндиша кылды* [8: 71].

«Сираҗел-колуб» әсәрендә күңел белән әйтү гыйбарәсе очрый һәм ул ‘уйлануларга бирелү’ мәгънәсендә килә: *Ул күңеле берлә әйтүр ирде: «ул йүтүрмеш тәвә бәһасене хасил кылдым имди* [8: 79].

Акыл эшчәнлеген белдерә торган фигыльләрдән, истәлекләрдә *ö- ‘уйлау’ тамырыннан ясалган *ög [7: 429] лексемасына бәйле, үгрәтү, үгрәнү фонетик вариантларында, өйрәтү, өйрәнү фигыльләре очрый. *Бер доға үгрәтәйем, йегет, сәна. Аны уқуб кер бу сағәт йулыңа* [6: 196]; *Торды, бақты, күрде: ул – җөһүд ирүр, Әйде: «Самит, мәңа иман үгрәт тәйүр* [6: 211].

Атасы андаг сакынур ирде: углум җадулык үгрәнүр диб [8: 74]; *Шаһзадә әйде: «И шаһи җәһан, Бер хәдис үгрәндем ирди ул заман* [6: 208]; *Габдулла бу авазны ишетүб, заһид катыга керде. Катында ултурды тәкый әйде: «Әй, заһид сәнең укыган кәлямеңне үгрәнмәккә килдем,*

мәңа хуш булды кәрәк. Бу көндин соң иртәсе кәчә сәңа килсәм сәнең укуган кәлямеңне үгрәнсәм сәнең динең үзә тәрбияләнсәм [8: 74], *Атам мәне җадулык үгрәнсүн диб йибәрде, мән йалган динне куйуб, ислам динен тутуб, күни йулга кереб, гам үгрәнермән* [8: 74] мисалларында бу лексема ‘фәнни әдәбият укып, тиешле мәгълүмат алу, нинди дә булса белемгә ия булу’ мәгънәсендә килә.

Чыганакларда аңла фигыле бик актив. Мөхәммәдьяр поэмаларында һәм шигырендә ул 43 урында кулланыла. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә бу сүзнең алты мәгънәсе китерелсә [11: 204], аларның күбесе XV–XVI гасыр ядкәрләрендә үк урын ала. Мәсәлән, *Чын мөселман ул булур, аңла йәкин, Кем хәйа берлә бәзәнүр күңле чын* [6: 187]; *Ул хикайәт қылды мәңа тыңлаңыз, Газилар әхуалени хуш аңлаңыз* [6: 194]; мисалларында аңла- лексемасы ‘кемнең, нәрсәнең яки нинди дә булса күренешнең, эш-хәлнең асылын, барлыкка килү сәбәбен, мәгънәсен ачыклау’мәгънәсендә килә.

Әлеге лексеманың чыганакларда очраган башка мәгънәләрен дә санап һәм мисаллар белән раслап китик:

1. *Чөн китабым атыны аңладыңыз, Шаһ догасы сүзләрен тыңладыңыз* [6: 174] – ‘уйлау, күз алдына китерү, күзаллау’ мәгънәсендә.

2. ‘Өйрәнү, уку һәм аңлашу процессында билгеле бер катлаулы нәрсәне аңлау’ мәгънәсендә: *Әйтәйем барчәсыни, хуш тыңлаңыз, Фикер итеб, шаһи ғаләм, аңлаңыз* [6: 180]; *Ғишық берлә сидық сүзен тыңлаңыз, Тәқрир итәйем аны – хуш аңлаңыз* [6: 205]. Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасында еш кына бел- фигыле ‘нәрсәнең дә булса асылын, мәгънәсен, эчтәлеген аңлап алу, төшенү’ мәгънәсендә килә һәм аңла-, төшен- лексемаларына синоним була: *Йахшы уқуб мәғнәләрен белеңез, Шаһи ғаләмға доғалар қылыңыз* [6: 176].

3. Берәр нәрсәне белү, ачык итеп күз алдына китерү: *Ул ғәрәбнең йирен, йортын аңлаңыз, Барчәси шурстан ирди, тыңлаңыз* [6: 188].

4. Берәр нәрсәнең, күренешнең һ. б.ш.ларның асылына акыл белән ирешү, сәбәбен аңлау: *Эчеб аның ләззәтени аңлағыл, Мәңа инғам, күб нәмә бағышлағыл* [6: 191].

5. Нәрсәнең дә булса мәгънәсенә, асылына төшенү, эчтәлеген ачыклау. *Ханға қылғай даимән үгүш доға, Мәғнә аңлаб, табса лу сүздин сафа* [6: 223]; *Барчә эшдә сабыр қылғыл, и ғәзиз, Сабыр сүзен аңла, и ғәқлы тәмиз* [6: 198]; *Шаһзадә әйде ул сағәт, ишет, Бу хәдис мәғнәсени аңла, йегет*: [6: 207].

6. Бәяләү, тану (кешене, хезмәтне һ. б.ш.). *Ул вәзирнең сүзен солтан тыңлады, Гақиланә сүзләгәнен аңлады* [6: 200]; *Чөн аның ғақиллығыны белде ул, Мәмләкәтни аңа тәслим қылды ул* [6: 201].

Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасында *Нәқел итәйем бер хәдис үзендин уш, Төрк теленчә мәғнәсен аңла хуш* [6: 203]; *Төркү теленчә сидық мәғнәсен белең – Күнилек берлә һәмишә эш қылың* [6: 205] мисалларындагы аңла һәм бел лексемалары мәгънәләре белән бер-берсенә якын торалар һәм икенче бер телдә сөйләгәнне яки чит тел сүзенең эчтәлегенә төшенүне күрсәтәләр.

Аңла- фигыленең йөкләтү юнәлеше мәгънәсен биргән тәкрир ит кушма фигыле Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасында кулланыла:

*Ғишық берлә сидық сүзе*н *тыңлаңыз, Тәкрир итәйем аны – хуш аңлаңыз* [6: 205]. Бу очракта автор кабатланмас өчен дә, әлеге лексемага мөрәҗәгать иткән дип уйларга нигез бар.

Бел- фигыленең ‘нәрсә яки кем турында мәгълүматлы булу’ мәгънәсе алдагы мисалда урын ала: *Ул жәзирә тәңиз ичрә ирди, бел, Бөтмеш ирди анда бер тағ, аңлағыл* [6: 219]. Бәеттә бел, аңла сүзләренең мәгънәләре шулай ук якын, ягъни герой тыңлаучыга яңа мәгълүмат хәбәр итә һәм шуны ассызыклый.

Казан ханлыгы чоры язма истәлекләрендә акыл эшчәнлеген белдерә торган фигыльләрнең мәгънәләрен анализлау нәтиҗәсендә алардагы бу төркемгә кергән күпчелек лексик берәмлекләрнең хәзерге татар әдәби телендә кулланылуы ачыкланды. Күп сүзләрнең XV–XVI гасыр чыганаклары текстларындагы мәгънәләре сакланган һәм киңәйгән; сакын- фигыленең семантикасы өлешчә сакланган: Казан ханлыгы чоры язма текстларында әлеге лексема ‘уйларны кемгә яки нәрсәгә дә булса юнәлдерү, уй йөртү, фикерләү’ төшенчәсен бирсә, хәзерге татар телендә сагыну формасында ‘кемне яки нәрсәне дә булса искә төшереп күрәсе килү, юксыну, аның янәшәсендә булырга теләү; тансыклау, күңел теләү’ мәгънәләрендә кулланыла [10: 23]. Ә аның XV–XVI гасырлардагы белдергән семантик функциясен уйлау фигыле үти. Аңла- фигыленең Мөхәммәдьярның «Нуры содур» поэмасында актив кулланылганын ачыкладык. Семантик мәгънәләрнең нечкәлекләрен оста белеп эш итү авторга бу лексеманы еш файдаланырга мөмкинлек бирә.

ӘДӘБИЯТ

1. Древнетюркский словарь. Л.: Наука, ЛО АН СССР, 1969. 677 с.

2. Кадирова Э.Х. Поэмы Мухаммедьяра «Тухфа-и Мардан» и «Нур-и Содур»: лексика. Казань: Фикер, 2001. 230 с.

3. Кол Шәриф. И күңел, бу дөньядыр: газәлләр, кыйсса. Казан Татар. кит. нәшр., 1997. 94 б.

4. Кыз хикәяте / төз.-авт.: Мәрданов Р.Ф. Казан: Милли китап, 2012. 184 б.

5. Мөхәммәт Әмин Могҗизнамә. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 295 б.

6. Мөхәммәдьяр Нуры содур. Поэмалар, шигырь. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. 336 б.

7. Севортян Э.В. Этимологический словарь тюркских языков. Общетюркские и межтюркские основы на гласные. М.: Наука, 1974. 768 с.

8. Сиражел-колүб. Казан: Казан ун-ты табгыханәсе, 1903. 126 б.

9. Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев. Тулыл. 2 нче басма. Казан: ТӘһСИ, 2016. Т. II. 432 б.

10. Татар теленең анлатмалы сүзлеге. V т.: С–Т. Казан: ТӘһСИ, 2019. 908 б.

11. Татар теленең анлатмалы сүзлеге: 6 томда. I т. Тулыл. һәм төзәт. 2 нче басма. Казан: Татар. кит. нәшр, 2020. 751 б.

12. Фатхтдинов Ф.К. Книга Умми Камала. Өмми Камал китабы (на русском, старотатарском (рукопись, транскрипция рукописи), современном татарском языках). Казань: ИЯЛИ, 2022. 648 с.

13. Clauson G. Etymological Dictionary of Pre-Thirteenth Century Turkish. Oxford, 1972. P. 988.

УДК 811.512

Кадирова Энҗе Хәнәфи кызы
ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
Казан, Россия
Кадирова Энзе Ханафиевна
Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
Казань, Россия
Kadirova Enze Khanafievna
G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Arts
of the Tatarstan Academy of Sciences
Kazan, Russia
E-mail: enge@inbox.ru

XV–XVI ГАСЫР ИСКЕ ТАТАР ЯЗМА ИСТӘЛЕКЛӘРЕНДӘ ФИЗИОЛОГИК ХАЛӘТНЕ БЕЛДЕРӘ ТОРГАН ФИГЫЛЬЛӘРНЕҢ ФУНКЦИОНАЛЬ СЕМАНТИКАСЫ

ФУНКЦИОНАЛЬНАЯ СЕМАНТИКА ГЛАГОЛОВ ФИЗИОЛОГИЧЕСКОГО СОСТОЯНИЯ В СТАРОТАТАРСКИХ ПИСЬМЕННЫХ ПАМЯТНИКАХ XV–XVI ВЕКОВ

FUNCTIONAL SEMANTICS OF VERBS OF PHYSIOLOGICAL STATE IN THE OLD TATAR WRITTEN MONUMENTS OF THE 15TH–16TH CENTURIES

Мәкалә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 16.07.2024 ел № 565 Карары нигезендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе ярдәмендә әзерләнде

Статья подготовлена при поддержке Академии наук РТ по Постановлению КМ РТ № 565 от 16.07.2024

Аннотация. *В данной статье рассматриваются лексико-семантические группы глаголов физиологического состояния в текстах старотатарских памятников периода Казанского ханства. Наиболее распространенными по семантике являются глаголы, передающие физиологические состояния болезни, усталости, жажды, сна, которые имеют различную сочетаемость. Анализ языкового материала показывает, что большая часть выявленных в письменных памятниках старотатарского языка XV–XVI вв. глаголов сохранилась в современной татарской лексике.*

Annotation. *This article examines the lexical and semantic groups of verbs of physiological state in the texts of Old Tatar monuments of the Kazan Khanate period. The most common in semantics are verbs conveying physiological states of illness, fatigue, thirst, sleep, which have different combinability. Analysis of the language material shows that most of the verbs identified in the written monuments of the Old Tatar language of the 15th–16th centuries have been preserved in modern Tatar vocabulary.*

Ключевые слова: *татарский язык, старотатарский язык, глагол, семантика, глаголы физиологического состояния*

Keywords: *Tatar language, Old Tatar language, verb, semantics, verbs of physiological state*

Фигыльләрне мәгънәләре буенча төрле төркемләүдә төрле фикерләр бар. Күпчелек классификацияләрдә алар, төп мәгънәләреннән чыгып, эшгамәл һәм хәл-торыш фиыльләренә аерыла. Хәл-торыш фигыльләренә яшәешне, сыйфат ягынан хәл-торышны, аның барлыкка килүен, социаль хәл-торышны, эмоциональ халәтне, хис-кичерешне, физиологик халәтне белдерә торган фигыльләр керә [10: 99]. Татар әдәби телендә хәл-торыш фигыльләрен өйрәнгән аерым мәкаләләр басылса да [14; 2], иске татар телендә бу төркем фигыльләрнең семантикасына багышланган фәнни хезмәтләр хәзергә юк.

Тел белемендә тел берәмлекләрен функциональ аспектта өйрәнү актуаль. Фигыль телнең лексик системасында үзәк урынны алып тора, әдәби текстта мөһим роль уйный. Хәл-торыш фигыльләре субъект белән чикләнгән процессларны, субъектка хас халәтне, аның вакыт эчендә агышын белдерәләр [10: 93]. Аны функциональ юнәлештә өйрәнү текстта һәм сөйләмдә фигыльләр куллануның семантик закончалыкларын һәм ысулларын ачарга ярдәм итә.

Ф.М. Лельхова ханты телендә физиологик халәт фигыльләрен тикшереп, аларны түбәндәге лексик-семантик төркемнәргә бүлә:

1. Авыру халәтендә булуны белдерүче фигыльләр;
2. Сәламәтләнү, савыгу, терелүнең гомуми мәгънәсен белдерүче фигыльләр;
3. Йокы, ярым йокы хәлендә булуны белдерүче фигыльләр;
4. Уяну, йокыдан уяну, җанлану мәгънәсен белдерүче фигыльләр;
5. Тәненә суык үтү, салкынның тәнгә чамадан артык тәэсир итүен тою мәгънәсен белдерүче фигыльләр;
6. Арыганлык, талчыкканлык, алҗыганлык мәгънәсен белдерүче фигыльләр;
7. Үлгәннән соң тормышка кайту, терелү мәгънәсен белдерүче фигыльләр;
8. Карындагы баланы күтәрүче хатын-кызның физиологик халәтен белдерүче фигыльләр;
9. Сусау, ачлык халәтендә булуны белдерүче фигыльләр;
10. Исерү халәтенә килүне белдерүче фигыльләр;
11. Көтелмәгән яки уңайсыз шартлар йогынтысында хәрәкәтләнә алмау халәтенә килүне белдерүче фигыльләр;
12. Нинди дә булса мәгълүматны, тәэсирне истә тотуны югалту мәгънәсен белдерүче фигыльләр [6: 30–35].

«Татар грамматикасы» авторлары физиологик халәтне белдерә торган фигыльләрне төркемнәргә бүлми генә санап чыгалар. Бу группага түбәндәге лексемаларны теркиләр: җәфа чигү, азаплану, йоклау, уяну, карын ачу, ис тию, ару, тынычлану, сусау, теләү, тазару, ябыгу, сәламәтләнү, суык тию, авыру, туңу, туңдыру, өшү, өшетү, калтырану, дерелдәү, эч кату, тын бетү, сулыш кысылу, эсселәү, кычыттыру, кымыржып тору, чәнчеп китү, чәнчеп алу, чемердәп тору, аяк ою, баш кату, баш чатнау, колак чыңлау, сулкылдау, әрнү, әчетү, әчеттерү, сызлау, чемету, күңел болгану, хәлсезләнү һ. б. [10: 99].

Казан ханлыгы чоры язма истәлекләрендә физиологик халәтне белдерә торган фигыльләрнең саны чикле булу сәбәпле, без аларны төркемләргә бүлми генә карауны кулай күрдек.

‘Физик көч, егәр бетү; хәлсезләнү’, ягъни арыганлык, талчыккан-лык, алҗыганлык мәгънәсен белдерүче фигыльләр арасында иске татар язма истәлекләрендә ару лексемасы еш очрый. Ул ‘ару, талчыгу, хәл-сезләнү’ мәгънәләрендә борынгы төрки истәлекләрдә, «Әт төхфәт әз зәкийә фил-лөгат әт-төркийә» истәлегендә, Ибне Мөханна, Әбу Хаян сүзлекләрендә, Сәйф Сараиның «Гөлстан», Котбның «Хөсрәү вә Ши-рин», Мәхмүт Болгариның «Нәһҗел-фәрадис» әсәрләрендә урын ала [12: 60]. Казан ханлыгы чоры язма чыганакларында ару фигыле Мөхәммәдь-ярың «Төхфәи мәрдан», «Нуры содур» поэмаларында кулланыла: *Күб йөкүрдүң, һич арыб ултурмадуң, Арығаныңны кешегә белдүрмәдүң* [8: 183]; *Ул қуй арыды, ғақибәт тотдуң аны, Рәхим қылыб ул дәм урутдың аны* [8: 183]; *Әйдең аңа: и мөбарәк җануар, Күб йөкүрдүң сән қачыб, ар-дуң мәгәр* [8: 183]; *Үзүң арыб һәм мәне арғуздуң уш, Бер зәман қылғыл асайеш имди хуш* [8: 183]; *Ничә кем қайтардылар, – ул қайтмады, Күб йөрүде ақсаб, арыб йатмады* [8: 202]. Шулай ук «Нуры содур» әсәрендә ‘арып хәлсезләнү, талчыгу, йончу’ мәгънәсендә талу сүзе дә килә: Килди бер турғай йырак йирдин талыб, Бер саричә буйнын ағзыға алыб [7: 226]. Ул кешегә түгел, кошка карата кулланыла.

‘Йокы хәлендә булу’ны белдерүче фигыльләр Мөхәммәдьяр иҗатын-да урын ала. Үтүб кәрван, қалур ғафил уйқуда, ғафил улмас кем уйқарса (бер) хода [8: 74] мисалында уйкуда калу йоклау, йокыда калуны аңлата. Әсәрдә йоклау фигыле дә шул мәгънәдә очрый: Булар дәрхал қылычын бағладилар, Йоқлайурда барысын бағладилар [8: 92]. Ул кичә йатты, ойу-ды, нагәһан Йоклайурда төшүндә Фәхри җәһан [8: 92] бәетендәге ойу лексемасы шулай ук йоклауны белдерә. Чыганакларда теркәлгән бу лек-сик берәмлекләр һәммәсе уйку сүзенә барып тоташа. Л. Будагов аларның уйкуламак, уйкылмак, укламак, йукламак вариантларын күрсәтә [2: 166]. «Могҗизнамә» әсәре авторы йоклыйсы килүне гарәп сүзе хаб (хаб ‘йокы, йоклау’) [3: 643] ярдәмендә ясалган хаб тоту тезмәсе белән белдерә: Ял-варыркән Хакка, аны тотты хаб Улды хәзрәттән догасы мөстәҗаб [7: 122]. «Кыз хикәяте»ндә ‘йоклыйсы килмәү’ мәгънәсе уйку кәлмәү, күзенә уйку кәлмәү гыйбарәләре аша бирә: *Шад улубән йатдылар ул кэчә. Уйку кәлмәз ул йегетә, әй, хуҗа* [5: 61]; *Әндишәдән уйку кәлмәз күзенә,* Хәйран улды ул йегетүң сүзенә [5: 67]. ‘Йокыдан уяу хәлгә килү, йокыдан тору’ мәгъ-нәсендә XV-XVI гасыр чыганакларында, нигездә, уйгану формасы кулла-ныла: Адәм уғлы уйғаныб торса рәуан Сабах йатқан йерендин нагәһан [8: 183]; Уйғаныб, возу итеб вақтқа бақар, Нагәһан берәгү уш ишик қақар [8: 183]; Қайчан мөэмин мөвәххид хуш татлиғ уйуғында уйғаныб бу кәлимәне әймеш булғай [8: 15]. Өмми Камал иҗатында уйану варианты килә: Ди-рилде һәр үлү йирләр уйанды ойурлар, Тунанды кирү йәшәрде тулды һәр кор вә йуш [13: 273]; Гамь шадлыга дүнди уйурлар уйанды Һәр дөрлү нә-батат чәчәкләр бетер улды [13: 280]. Бу ике вариантны Л. Будагов төрек (уйану) һәм чыгтай (уйгану) телләрендәге кулланылыш дип аңлата [2: 165]. Кол Шәриф йокыны тәмамлап, уяу хәлгә килүне түбәндәгечә бирә: Башың күтәр гафләтдин, гафил торма, һу тигел, Күзең ачкыл уйкудин, гафил тор-ма, һу тигел [4: 280].

Казан ханлыгы чоры язма истәлекләрендә ‘бик нык эчәсе килү; та-мак кибү, ачлык халәтендә булу’ны белдерүче фигыльләргә дә мисаллар

очрады. Мөхәммәдьярың «Нуры содур» поэмасында ‘организмның суга мохтаж булуы’ мәгънәсендә сусау лексемасы теркәлгән: Сусамыш ирди ул ғәрәб би ғөман, Эчте ул балчыклы судин нагәһан [8: 189]. Әлеге әсәрдә артык нык сусау халәтен бирү максатыннан, автор шулай ук физиологик халәтне белдерүче фигыль буларак теркәлгән йөдәү ‘азаплану, җәфалану, интегү’ [11: 723] лексемасын файдалана: Ул ғибәдәт қылмаға тәүфиқ йәнә Рузи қылдым, и фозул Заһид, сәңа» [8: 220]. Сусау сүзе «Сираҗел-колүб» әсәрендә дә очрый: Җөмлә халаиклар Гарасатга бара булсалар, тәкый сусасалар, ул көн, ул Кәүсәр хаузыдин әүвәл шәраб эчкән кемләр булур? [9: 16]. «Кыз хикәяте» истәлегендә ашыйсы килмәүне, ашыйсы килү теләге булмауны автор әлен ашына сонмау, ягъни кулын ашка сузмау сүзтезмәсе белән бирә: Қыз қаты пошуқды углан эшенә, Ул кэчдә сонмады әлен ашына [5: 66].

«Сираҗел-колүб» әсәрендә авыру халәтендә булуны белдерүдә зәхмәт тикү, агыриг тикү кушма фигыльләре очрый: *Һичкем ирсә ки зәхмәт тикмәде* [8: 3]; *Әгәр Адәм галәйһиссәламгә андин агыриг тиксә ирде, Адәм галәйһиссәламнең күңеле Хәува үзә мәһәрйан булмагай ирде* [9: 35]. Мескинләр, дәрвишләр, мөбталәләр әйделәр: Тәңре Тәгалә кодрәте берлә нә кем голләт рәнҗләре бар ирсә, барчасы хуш булды [9: 53].

Шул ук истәлектә авыру хәләтен тәннең бер өлешен белдерә торган исем + авыру сүзе ярдәмендә ясалган тезмә сүз һәм очра- фигыле аңлата: *Ул сәгать эчендә Фиргавен ләгыйнь ул һәйбәтне күрүб, карын агрыгына очраб, бер сәгатьдә дүрт йөз атлә кабемкәһгә керде* [9: 43].

Шулай итеп, кешенең физиологик халәтен характерлаучы фигыльләр тикшеренүнең объекты буларак алынып, аларның Казан ханлыгы чоры татар язма истәлекләрендәге мәгънәви вазифалары каралды. Анализ күрсәткәнчә, текстлардагы физиологик халәтне белдергән фигыльләр, лингвистик корал булудан тыш, әсәрнең семантик дөньясын киңәйтә торган хикәяләү элементы да булып торалар. Алар кешенең талчыгу, ару, авыру, савыгу, терелү, йокысы килү, сусау, ачыгу һәм башка халәтләрен күрсәтү чарасы булып хезмәт итә.

ӘДӘБИЯТ

1. Будагов Л. Сравнительный словарь турецко-татарских наречий, со включением употребительнейших слов арабских и персидских и с переводом на русский язык: в 2-х т. СПб.: Тип. АН, 1869. Т. 1. 810 с.

2. Галиева А.М. Представление глаголов физиологического действия и состояния в лексикографической базе данных татарских глаголов // Ученые записки Казанского университета. Серия Гуманитарные науки. 2018. Т. 160, кн. 5. С. 1219–1234.

3. Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге. Казан: Иман, 2018. 856 б.

4. Кол Шәриф. И күңел, бу дөньядыр: газәлләр, кыйсса. Казан Татар. кит. нәшр., 1997. 94 б.

5. Кыз хикәяте / төз.-авт.: Мәрданов Р.Ф. Казан: Милли китап, 2012. 184 б.

6. Лельхова Ф.М. Глаголы физиологического состояния в хантыйском языке (на материале сынского диалекта) // Вестник угроведения. № 1 (4). 2011. С. 30–37.

7. Мөхәммәт Әмин. Могҗизнамә. Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. 295 б.

8. Мөхәммәдьяр. Нуры содур. Поэмалар, шигырь. Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. 336 б.

9. Сираҗел-колүб. Казан: Казан университеты табгыханәсе, 1903. 126 б.

10. Татар грамматикасы: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев. Тулыл. 2 нче басма. Казан: ТӘһСИ, 2016. Т. II. 432 б.

11. Татар теленең анлатмалы сүзлеге: II т.: Г–Й. Казан: ТӘhСИ, 2016. 748 б.
12. Фазылов Э.И. Староузбекский язык. Хорезмийские памятники XIV в. Т. II. Ташкент: Фан, 1971. 777 с.
13. Фатхтдинов Ф.К. Книга Умми Камала. Өмми Камал китабы (на русском, старотатарском (рукопись, транскрипция рукописи), современном татарском языках). Казань: ИЯЛИ, 2022. 648 с.
14. Шарифуллина А.Г. Семантика глаголов эмоционального состояния в татарском и английском языках // Филология и культура. 2013. №. 1(31). С. 24–127.

УДК 81’373

Камаева Рима Биҗан кызы
Казан (Идел буе) федераль университеты
Алабуга, Россия
Камаева Рима Бизяновна
Казанский (Приволжский) федеральный университет
Елабуга, Россия
Kamaeva Rima Bizyanovna
Kazan (Volga Region) Federal University
Elabuga, Russia
E-mail: kamaeva-r@mail.ru

ТАТАР ӘДӘБИ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ МЕДИЦИНА ТЕРМИННАРЫНЫҢ РОЛЕ

РОЛЬ МЕДИЦИНСКИХ ТЕРМИНОВ В ТАТАРСКИХ ХУДОЖЕСТВЕННЫХ ПРОИЗВЕДЕНИЯХ

THE ROLE OF MEDICAL TERMS IN TATAR FICTION

Аннотация. *В данной статье с целью уточнения особенности употребления медицинских терминов в художественных текстах была исследована лексика романов татарских писателей А. Абсалямова «Ак чәчәкләр» («Белые цветы»), М. Хасанова «Язгы аҗаган» («Весенние зарницы»), повести З. Хакима «Хирург». В произведениях авторы стараются привлечь внимание читателя к проблеме медицины и подчеркнуть необычность событий, уделяют место описанию характерных признаков болезней, медицинские термины в произведениях являются и стилистическим средством создания речевых и портретных характеристик персонажей.*

Annotation. *In this article, in order to clarify the specifics of the use of medical terms in literary texts, the vocabulary of the novels of Tatar writers A. Absalyamov «Ak Chachaklar» («White Flowers»), M. Khasanov «Yazgi aҗagan» («Spring lightning strikes»), the story of Z. Hakima is a “Surgeon». In their works, authors try to draw the reader’s attention to the issue of medicine and emphasize the unusual nature of events. They also provide descriptions of the characteristic symptoms of diseases, and medical terms serve as a stylistic tool for creating speech and portrait characteristics of characters.*

Ключевые слова: *татарская лексика, художественное произведение, медицинский термин, стилистическое средство*

Keywords: *Tatar vocabulary, literary work, medical term, stylistic device*

Медицина терминнарының әдәби әсәрләрдә кулланылу үзенчәлекләрен ачыклау өчен, без Габдрахман Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр», Мәхмүт Хәсәновның «Язгы аҗаган» романнарындагы, Зөлфәт Хәкимнең «Хирург» повестендагы терминнар кулланылышын тикшердек. Тикшеренүләр шуны күрсәтә: язучылар терминнарны төрлечә кулланып эш итәләр.

Габдрахман Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романы – табибларга багышланган әсәр. Беренче чиратта әсәрдә врачлар дөньясы сурәтләнә. Врачлар дөньясы белән янәшә, бергә үрелеп, үзенең кайгы хәсрәте һәм савыгу шатлыгы белән аврулар дөньясы бирелә. Шуларның бер-берсенә мөнәсәбәтеннән романның мавыктыргыч сюжеты туа. Автор геройларның рухи халәтен оста күрсәтеп, кеше күңеленең нечкәлеген һәм катлаулылыгын тирәнтен ачарга тырыша. Табибларның хезмәтен барлык нечкәлекләре белән күрсәтү максатыннан автор әсәрдә медицина белән бәйле терминнарны еш куллана. Романның кайбер урыннарында автор укучының игътибарын медицина проблемасына да җәлеп итәргә һәм тасвирланган вакыйганың гадәти булмаганлыгын ассызыкларга тырыша, терминнар сөйләмнең төрле өлешләрендә кулланыла.

«Зиннуровны *больницага* бик авыр хәлдә носилка белән китереп салганнар. Авырту күкрәк сөяге астында башланган һәм *нитроглицерин* каптыргач та басылмаган. Больницада аңа *ашыгыч медицина ярдәме* күрсәткәннәр: кабат *морфий, атропин, кордиамин уколлары ясаганнар, кислород сулатканнар.* Шуннан соң гына авыруның йөзендә аз гына алсулык беленеп, тыны ачыла төшкән, *тамыр тибеше* әзрәк сизелә башлаган һәм аны өскә, *палатага* менгереп яткырганнар»[2: 26].

«Вера Павловна тиз генә *кислород мендәре* алып килеп, *кордиамин уколы* ясады. *Врачлар бүлмәсендә* Мәһира ханым Гөлшәһидәләргә *электрокардиаграмма* лентасын, *кан анализларын* күрсәтте. Шик юк *диагноз* раслана: *миокард инфаркты*.

«–Үзгәрешсез, Гөлшәһидә апа, – дип җавап бирде сестра һәм күз ачып йомганчы *приемный покойга* кереп югалды» [2: 27].

«– Мәһирә Хәбировна, – дип, профессор дәвалаучы врачка таба борылды, – *үпкәләрнең томографиясен*, һәм *бронхография снимокларын* әзерләргә кушыгыз» [2: 63].

Әсәрдә авыруларның характерлы билгеләрен тасвирлауга да урын бирелә.

«Иң элек Галина Петровнаның йөзе. *Рак белән авыручыларның* йөзләре гадәттә җир төсле була. Галина Петровнаның йөзе алай ук кебек түгел» [2: 64].

Зөлфәт Хәкимнең «Хирург» повестен автор Финляндиядә дәвалану вакытында яза. Бу повесть «Шифалы куллар» конкурсында беренче урынны яулый. Әсәрдә автор медицина белән бәйле яңа лексиканы күбрәк куллана. Кайбер терминнар аңлатма белән бирелгәннәр.

«Аңа бик куркыныч хәбәр әйткәннәр бит әле. *«Рак предстательной железы»* дигән шик белдергәннәр. *ПСА* нәрсә ул? – *Простато специфический антиген. Онкомаркер. – Канында* менә шул *ПСА* дигән нәрсә егермене тәшкил итә икән. Күпме ул? – Күп. Нормада дүрттән артмаска тиеш. *Томография* үткәнме? – Үткән. *Томографиядә* төгәл ачыклый алмаганнар. – *ПСА* саны егерме булгач, кичектермичә, *биопсия* ясатырга кирәк. – Анысы

нәрсә тагы? – Анализ өчен *простатаның җепселләрен алалар да, гистология* үткәрәләр» [5: 12].

Автор бу әсәрдә авыруның барышын тасвирлап яза, терминнар рус сүзләре белән дә, башка алынмалар белән дә бирелә.

«Бу *яман чиргә* каршы көрәш дәвам итә, әмма чарасызлык дигән төшенчә *табиб белән пациент* арасында һәрвакыт уяу тора. Дөрес, аның механизмы аңлашыла шикелле – әйбәт күзәнәкләр зәгыйфьләре һәм комсызлары белән алмашына. Бу *агрессив клеткалар* бернинди кирәкле хезмәт күрсәтмиләр, әмма тиз үрчиләр, таралалар һәм организмны дөрес яшәүдән мәхрүм итәләр. Шул агрессив күзәнәкләр аркасында, *эчке әгъзалар*, *тамырлар, нерв юллары* урынына мәгънәсез, кирәксез тукымалар барлыкка килә. Организм үзенчә көрәшә. *Лимфалар системасы рак күзәнәкләрен* үтерергә тотына, бавыр аларны, үзе аша үткәреп, эшкәртергә маташа, *бөерләр фильтрация ясый, тир аларны тышка чыгарып ташлый*. Әмма *рак күзәнәкләре* нормаль күзәнәкләр белән чагыштырганда, бик гади вә әшәке. Андый *гарип күзәнәкләрне,* әйбәтләренә караганда, «ясау» бик җиңел. Рак күзәнәген тудыру өчен көч бик аз сарыф ителә. Ә бит туклану организмга тигез бирелә – әйбәте дә, примитивы да бертигез ала ризыкны. Нәтиҗәдә, яман күзәнәк тизрәк үсә – аны бары тик үз массасын үстерү генә кызыксындыра. Үзенә тиешле размерга үскәч тә, аңа һаман туклану килә тора – димәк, аңа үрчисе генә кала. *Сәламәт организм* ул хәшәрәтне тиз генә чыгарып атарга да мөмкин. Ә карт, *хәлсез организм* моны булдыра алмый. Шунысы да бар: *рак күзәнәкләрен* төзү җиңелрәк» [5: 23].

Мәхмүт Хәсәновның «Язгы аҗаган» романы XX гасырның 70–80 нче елларында иҗат ителгән. Роман тормыш материалларының катлаулылыгы, сюжетның күптармаклылыгы белән аерылып тора. Әсәр хатирәләр рәвешендә язылган. Әсәр өермәле вакыйга белән башланып китә – коммунист Хажи үтерелә, аның Зәйтүнә исемле хатыны бу тетрәндергеч хәл тәэсирендә баласын вакытсыз тудыра. Ана Гази, Тажи, Һади исемле балалары белән тол кала. Хикәяләүчене иң кызыксындырган кешеләр – шушы бертуган Зәкиевләр. Романда төп игътибар олы малай Газигә юнәлә. Гази – әтисе гомерен биргән эшкә тугрылыклы малай. Комсомол активисты, курку белмәс көрәшче. Рабфак укучысы, медицина институты студенты. Фронтта хирург. Әсирлек. Аннан соңгы газаплар, кыерсытылулар, әсир дигән яман исемнең үз артыннан тагылып йөрүе. Гази аңа бәйләнешле кешеләр турында язганда, автор шактый оста эш итә. Тикшеренү өчен алынган медицина белән бәйле лексика нәкъ менә шул урыннарны тасвирлаганда файдаланыла.

«Илья Олеговичка шундук ярдәм күрсәтә башладылар: *ясалма сулыш алдырдылар: укол кададылар*, авыз-борыныннан ниндидер сыекчыклар белән чылатылган *марля-маскалар* куйдылар. Һәм шундук күләгәдә торган бөркүле арбага сузып салып, әрәмәлек эчләтеп кенә каядыр алып киттеләр» [6: 133].

Без романда хирургларның хезмәтен барлык нечкәлекләре белән чагылдырган урыннарны еш очратабыз.

«Бездә: “*Операция* вакытында *хирург* дирижер булса, *анестезиолог* беренче скрипка”, – диләр... » [6: 36].

«*Операцияне* Дисә ясады. Тынлыкны бары тик инструментларның сирәк-сирәк чыңлап куюлары һәм *хирургның* кыска боерыклары гына боза иде:

–*Тампон... пинцет... зажим...ланцет...* » [6: 30].

«Газизның бәхетенәме, бәхетсезлегенә каршымы, *медсанбат* әллә ни зур түгел иде, персоналы да алты-җиде кешедән генә тора. Шуларның берсе *санитар, өч медсестра*. Бәлки шуңадыр, эш шулкадәр күп, вакыт белән санашу юк. Көнме? Төнме? Еш кына аяк асты йокларга туры килә иде.

Операциягә керешкәнче үк *кан* бирү чарасын күрделәр. *Операция* шактый катлаулы буласы. Иң әүвәл, көч-хәл белән генә гәүдәгә эләгеп торган кулны аерып алдылар. Вак *сөякләрне* чүпләделәр. *Кан тамырларын* бәйләп, каппилярларны томалап, яраны тегү эшенә керешергә генә торганда, Чумаковны чакырып алдылар.

Өлкән хирург, Газига ияк кагып операцияне төгәлләргә кушып, җәһәт кенә чыгып китте» [6: 392].

Персонажларны характерлаганда да автор терминнарны уңышлы куллана, шулай ук терминнар персонажларның сөйләм һәм портрет характеристикасын булдыруның стилистик чарасы да булып тора.

«Ул *баш врачның* ышанычын тулысынча аклады кебек, тиз арада үзен чын *хирург* итеп танытып өлгерде. Хамзин *баш хирург* белән мактанып туя алмады. Больницаның даны тиз арада бик ераклarга таралып өлгерде.

Чаллыга башка тирә-юнь районнардан да килә башладылар. Ә Гази турында: “Булмасны да булдыра, соңгы сулышы өзелгән авыруларны да аякка бастыра ала”, – дигән сүзләр йөрде» [6: 33].

«Аның каравы массажистканың килүен ул һәрвакыт түземсезлек белән көтә һәм еш кына, кафедрадан әйткән кебек тантана белән:

– Массаж – бөек нәрсә ул! – дип әйтеп куя торган иде.

– Кешегә тормыш ритмы кирәк. Киеренкелек артыннан йомшару, эш артыннан ял булырга тиеш» [2: 154].

Терминнар әдәби әсәрләрдә туры мәгънәдә дә, күчерелмә мәгънә дә кулланыла. Терминнар күчерелмә мәгънәдә фразеологизмнарның компонентлары буларак бирелә.

1. *Медицина терминнарының туры мәгънәдә кулланылуы*.

«Шуннан Гөлшәһидә, борчылып, аны *район больницасына ренгентка* алып барды һәм авыруны *ренгентолог* белән бергә үзе карады. *Үпкәләрнең тамыр төпләре карала башлаган* иде! Бәхеткә, Әбүзәр абзый *больницада* туры килде. Ул *онколог* чакырырга киңәш итте. Шулай ук *ракмы* икәнни? » [2: 243].

2. *Медицина терминнарының күчерелмә мәгънәдә кулланылуы.*

Медицина терминнары З.Хәким иҗатында троплар буларак кулланыла. Шулай ук терминнар фразеологизм составында да очрый.

«Оятсыз, намуссыз кешегә залимлек нәрсә ул? Кем икәнен чыраена бәреп әйтсәң дә, төкерә ул синең сүзеңә һәм синең үзеңә.

Дөрес, аның механизмы аңлашыла шикелле – әйбәт күзәнәкләр зәгыйфьләре һәм комсызлары белән алмашына. Бу агрессив клеткалар бернинди кирәкле хезмәт күрсәтмиләр, әмма тиз үрчиләр, таралалар һәм организмны дөрес яшәүдән мәхрүм итәләр. Шул агрессив күзәнәкләр

аркасында, эчке әгъзалар, тамырлар, нерв юллары урынына мәгънәсез, кирәксез тукымалар барлыкка килә. Организм үзенчә көрәшә. Лимфалар системасы рак күзәнәкләрен үтерергә тотына, бавыр аларны, үзе аша үткәреп, эшкәртергә маташа, бөерләр фильтрация ясый, тир аларны тышка чыгарып ташлый. Әмма рак күзәнәкләре нормаль күзәнәкләр белән чагыштырганда, бик гади вә әшәке. Андый гарип күзәнәкләрне, әйбәтләренә караганда, «ясау» бик җиңел. Рак күзәнәген тудыру өчен көч бик аз сарыф ителә. Ә бит туклану организмга тигез бирелә – әйбәте дә, примитивы да бертигез ала ризыкны. Нәтиҗәдә, яман күзәнәк тизрәк үсә – аны бары тик үз массасын үстерү генә кызыксындыра. Үзенә тиешле размерга үскәч тә, аңа һаман туклану килә тора – димәк, аңа үрчисе генә кала» [5: 23].

«Кешелек дөньясының төпкелендә, ягъни кешенең үзәгендә ниндидер яман шеш ята. Анда син скальпель белән керә алмыйсың. Бернинди УЗИ, МРТ, компьютер томографиясе күрсәтми аны» [5: 26].

«Бәлки алар без чишә алмаган мәсьәләләрне күптән чишкәннәрдер, үзәкләрендәге *яман бер шешне* күптән инде алып ташлаганнардыр» [5: 30].

«Француз врачы бик дөрес әйткән: *буыннарны һәм буыннар өстендәге ярыны ревматизм ялый гына, йөрәкне тешли*» [2: 9].

«Биредә, больницада, бөтенләй башкача. *Инфаркт* мине көтмәгәндә-уйламаганда кайнар эш өстендә *аяктан бәреп екты*» [2: 185].

«Башка берәү *хәл эчендә ятканда,* врачның үз хәле турында уйларга хакы юк» [6: 30].

Язучылар табибларның һөнәри эшчәнлеген күрсәтүне үз бурычлары итеп куймыйлар. Шул ук вакытта әсәрләр медицина терминологиясе белән тулы. Авторлар укучыга тәэсир итәргә омтылалар, аларны кызыксындырган проблемалар турында уйланырга яки ниндидер ситуацияләргә һәм процессларга башкача карарга мәҗбүр итәләр.

ӘДӘБИЯТ

1. Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге / төз.-авт.: Д.Ф. Заһидуллина, В.Р. Әминева, М.И. Ибраһимов, Н.М. Йосыпова, Ә.М. Закиржанов, Т.Ш. Гыйлаҗев, Г.Р. Гайнуллина. Казан: Мәгариф, 2007. 231 б.

2. Әпсәләмов Г. Ак чәчәкләр. Роман. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 510 б.

3. Әхмәтьянов Р.Г. Татар терминологиясенең тарихи чыганаклары. Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. 174 б.

4. Сәлимов Х.Х. Тел гыйлеме терминнары сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 143 б.

5. Хәким З. Хирург // Казан утлары, 2019. № 12. Б. 8–55.

6. Хәсәнов М.М. Язгы аҗаган: Роман. Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. 607 б.

7. Шамсутдинова Р.Р. Медицинская терминология в татарском языке: дис. … канд. филол. наук. Казань, 2000. 219 с.

УДК 811.161.1’38:821.161.

Касьяненко Наталья Евгеньевна
ФГБОУ ВО «Донецкий государственный университет
Донецк, ДНР, Россия
Kasyanenko Natalya Evgeievna
«FSBEI HE Donetsk State University»
Donetsk, DPR, Russia
E-mail: kasyanenko_natusya@mail.ru

РОЛЬ АЛЛЮЗИИ В ПЕРЕДАЧЕ КУЛЬТУРНО ЗНАЧИМОЙ ИНФОРМАЦИИ В ПРОИЗВЕДЕНИЯХ Е.Г. ВОДОЛАЗКИНА

THE ROLEOF ALLUSIONIN CONVEYING CULTURALLY SIGNIFICANT INFORMATIONIN E.G. VODOLAZKIN’S WORKS

Аннотация. *В статье на материале романного творчества Е.Г. Водолазкина рассматриваются особенности аллюзий автора. Аллюзия при этом характеризуется как стилистический прием и фигура интертекста. Предметом анализа становится та роль, которую выполняют аллюзивные проявления в процессе передачи культурно-ценностной информации.*

Annotation. *The article examines the features of the author’s allusions based on the novel works of E.G. Vodolazkin. Allusion is characterized as a stylistic device and an intertextual figure. The analysis focuses on the role played by allusive manifestations in the process of conveying cultural and value-based information.*

Ключевые слова: *Е.Г. Водолазкин, аллюзия, идиостиль, интертекст, код культуры, стилистический прием, функции*

Keywords: E.G. Vodolazkin, allusion, idiostyle, intertext, cultural code, stylistic device, functions

Современная гуманитарная наука в своей основе является когнитивной и направлена она на отражение картины мира, в том числе языковой. Это не случайно, поскольку отличительной чертой объекта изучения (языка) является антропоцентризм, рассматриваемый современными учеными как онтологическая установка, как «переключение интересов исследователя с объекта познания на субъект» [8: 6], как познание языка с позиций отражения в нем человека. Язык при этом рассматривается как культурный код нации, как своеобразное «зеркало культуры», отражающее окружающую действительность, образ жизни носителя языка, его менталитет, специфику национального характера. Э. Сепир под подлинной культурой понимает, с одной стороны, некий культурный идеал, определяемый традицией (или общественным классом), а – с другой, систему ценностей, характеризующую народ как нацию. При этом носитель языка, конкретный индивид должен быть духовно органично связан с национальной культурой (см. об этом [9: 16–117]).

Учитывая все сказанное, стоит еще раз акцентировать тот факт, что язык является продуктом культуры, он предполагает формирование лингво-культурных кодов, обеспечивающих трансляцию культуры в системе языковых знаков.

Существенную роль в передаче культурного кода играет и художественная речь, воплощающая индивидуально-авторское видение мира и оригинальные приемы передачи эстетически значимой информации, в том числе культурно-ценностной. В этом смысле представляется интересным обратиться к изучению аллюзии как средства трансляции культуры и выявить ее роль в этом, привлекая язык художественных произведений.

Вполне закономерно, что материалом для реализации отмеченной цели избрано романное творчество Е.Г. Водолазкина, которое, безусловно, является нестандартным и востребованным среди нынешнего поколения. Кроме того, сам факт включения произведений писателя в программу по литературе для поступающих в высшие учебные заведения некоторых вузов (например, Санкт-Петербургского университета) свидетельствует о высокой их оценке и значимости – не случайно Е.Г. Водолазкин является трижды лауреатом только премии «Большая книга», не говоря о других его заслугах. Список исследований этого интереснейшего автора постоянно пополняется (см. например [12], [13] и др.), однако стилевые особенности его прозы изучены на сегодняшний день только фрагментарно. Между тем изучение идиостиля писателя не только проливает свет на особенности мировосприятия художника слова, но и является важнейшей составляющей теории интерпретации художественного текста. Наконец, главным, конечно, при выборе материала исследования рассматривается то обстоятельство, что произведения Е. Г. Водолазкина насквозь пронизаны аллюзиями.

Стоит отметить, что аллюзия как явление не ново. Оно имеет достаточно давнюю традицию изучения как лингвистами, так и литературоведами в самых разных аспектах. Множество же определений этого феномена свидетельствует о его многогранности. Кроме того, некоторые ученые считают аллюзию «одной из наименее определенных категорией стилистики» [15: 43].

Слово «аллюзия», по мнению исследователей, появилось в европейских языках с XVI века и в переводе с французского означает «намек». В русском языке оно входит в научный оборот в XVIII в. («Словарь русского языка XVIII века» фиксирует данное слово как новое).

Аллюзию определяют как «употребление в речи или в художественном произведении ходового выражения в качестве намека на хорошо известный факт, исторический или бытовой» [10] или на прецедентный текст [14]. Это явление характеризуют как «специфический намек, особенность которого состоит в иносказании» [7: 9], ссылку «на какой-либо исторический, мифологический, литературный факт», не имеющий прямого указания на источник [5: 124], как проявление «непрерывной диалогичности текстопорождения, в частности художественного творчества» [17: 24]. При этом подавляющая часть исследователей рассматривает аллюзию как категорию стилистики, как стилистический прием, риторический прием усиления речи (см., например, [5], [10], [16]), прием художественной выразительности [18].

Кроме того, лингвисты подчеркивают то обстоятельство, что аллюзия относится к интертекстуальным категориям ([1], [14], [15] и др.), являясь определенным средством проявления интертекстуальности, или фигурой интертекста.

Как отправное в этом смысле можно рассматривать определение интертекстуальности, данное И.В. Арнольд: «Под интертекстуальностью понимается включение в текст либо целых других текстов с иным субъектом речи, либо их фрагментов в виде маркированных или немаркированных, преобразованных или неизменённых цитат, аллюзий, реминисценций» [1: 346]. Иначе говоря, аллюзия является реализацией интертекстуальности, «отголоском, эхом» чужого текста в авторском, его «опознаваемым» элементом.

В аспекте интертекстовых характеристик аллюзии лингвисты выделяют исходный текст, или текст-донор и модифицированный текст, или текс-реципиент, а также рассматривают средства объективации таких аллюзий, или репрезентанты.

Ну и наконец, целесообразно еще раз подчеркнуть, что аллюзия обладает культурологической маркированностью, поскольку она, с одной стороны, событийна, а с другой – «проецирует упоминание того или иного факта на порождаемый текст» [6: 1431], насыщая последний культурной информацией и объективируя ее для социума.

Рассмотрим подробнее, какова роль аллюзий в передаче культурного кода в произведениях Е.Г. Водолазкина.

Спектр аллюзий в романном творчестве писателя достаточно широк. При этом они отражают индивидуальную языковую личность автора, его культурный багаж, систему оценок и включают когнитивную составляющую, позволяющую выявить индивидуальную картину мира творца.

Определенная часть аллюзий у Е.Г. Водолазкина соотносится с библейскими текстами и насыщена культурологической информацией. Так, из разрозненных сведений о главном герое романа «Авиатор» – Платонове – читающий знакомится в том числе с кругом его чтения: это, прежде всего, любимый с детства «*Робинзон Крузо*» Д. Дефо. Стремясь передать краткое содержание любимого в детстве произведения, Платонов проводит параллель с евангельской Притчей о блудном сыне, делая при этом значимые выводы: «*Если бы он* [Робинзон Крузо – **Н.К.**] *с самого начала вел себя благоразумно…Я не знаю, как это выразить, чтобы не впасть в менторский тон. Такая как бы* ***притча о блудном сыне***» [3: 16].

Данная аллюзия демонстрирует стремление автора пролить свет на нравственную позицию своего героя, возможно, обусловленную не столько религиозным чувством, сколько привычкой, воспитанной традицией, соизмерять свои действия и поступки с библейскими заповедями.

Обращение к подобным аллюзиям Е.Г. Водолазкина наблюдается и в романе «Оправдание острова», что можно рассматривать как попытку объяснить историю, дать собственную оценку событиям, поскольку, по его собственным словам в одном из интервью, «история является одним из главных персонажей этого романа». Один из Председателей вымышленного Острова Маркел учредил Трудовой лагерь из четырех тысяч крестьян, в котором возникли трудности со съестными запасами. В ответ на эту ситуацию Маркел вместо того, чтобы решать проблему, заявил начальнику Лагеря: «*Бог темного прошлого, которого мы отменили,* ***пятью хлебами накормил пять тысяч человек***» [4: 241], цинично при этом возразив: «*Так неужели же ты <…>тем же количеством хлеба не можешь накормить*

всего четыре тысячи». В ответ начальник ответил, что «***алчущие этим не насытятся***».

Здесь мы наблюдаем отсылку автора к известному евангельскому сюжету (см. Евангелие от Матфея, 14) и нагорной проповеди Иисуса, которая рассматривается как своеобразная нравственная концепция христиан и составляет неотъемлемую базисную часть национальной культуры русского человека. Кроме того, аллюзия в этом случае выступает средством продемонстрировать единство индивидуального и исторического времени.

Культурной информацией пронизаны и литературные (или, правильнее сказать, литературно-исторические) аллюзии Е.Г. Водолазкина. Например, в романе «Лавр» один из значимых персонажей – Амброджо, – рассуждая о дате рождения Иисуса Христа в связи с возможным концом света, приводит убедительные, как он считает, доказательства. Относительно непоколебимости последних главный герой романа Арсений высказывает сомнение, приводя в качестве аргумента фразу из трагедии А. Пушкина «Моцарт и Сальери», репрезентантом которой в тексте-реципиенте выступает трансформант – риторический вопрос: *«Какой, спрашивается,* ***гармонией ты поверишь*** *всю эту* ***алгебру****?»* [2: 247]. Ставшее уже крылатым выражение *поверить алгеброй гармонию* из текста пушкинской трагедии и имеющее значение ‘попытка проверить точным расчетом то, что относится к области чувств’, опровергается Амброджо философствованием о небесной гармонии, отраженной в высшем смысле чисел. Данная аллюзия содержит намек на прецедентный текст и выполняет традиционную для нее когнитивно-информативную функцию. Она не только описывает определенный фрагмент культурного пространства, не только сообщает культурно-ценностную информацию, но и подтверждает присутствие базовых знаний в сознании большинства носителей русского языка и русской культуры. Широко известное высказывание Аполлона Григорьева «*А Пушкин – наше всё: Пушкин – представитель всего нашего душевного, особенного, такого, что остается нашим душевным <…>*» лишний раз находит свое подтверждение.

Одним из ключевых достижений стало создание стандартизированных цифровых цветовых палитр, основанных на моделях RGB, HEX и CIELAB. Эти модели позволяют точно задавать цвета в цифровой среде, что критически важно для воспроизводимости экспериментов.

Онлайн-платформы, такие как PsychoPy, Gorilla.sc или jsPsych, позволяют проводить массовые эксперименты по идентификации цветов. Данные программы предоставляют исследователю возможность создавать зрительные стимулы, в нашем случае цветовые, одновременно фиксируя и анализируя их поведенческие реакции, мозговую активность или любую другую физиологическую активность. Участники из разных стран могут в реальном времени выбирать названия для представленных цветов, а данные автоматически собираются и структурируются. Такой проект, как ColourLex, результатом которого является создание 772 цветовых образца с соответствующим наименованием этого цвета на основе произведений искусства живописи, уже собрали данные по цветовой лексике более чем из 100 языков мира [5].

Корпусная лингвистика, в свою очередь, даёт возможность анализировать не только нормативные, но и употребительные особенности цветообозначений. Например, в НКРЯ (Национальный корпус русского языка) можно проследить, что слово голубой чаще употребляется в контекстах, связанных с небом, глазами или одеждой, в то время как синий – с техникой, документами или эмоциями (синяя тоска). Сравнительный анализ английского blue и русского синий/голубой в параллельных корпусах показывает, что английский язык, не разделяя эти оттенки лексически, компенсирует это модификаторами (light blue, sky blue, navy blue). Анализ частотности и контекстов позволяет выявить культурно обусловленные универсалии употребления терминов цвета в определенной языковой картине мира [5].

Цифровые инструменты также позволяют строить семантические карты цветовых терминов. Метод многомерного шкалирования (Multidimensional Scaling) применяется для визуализации воспринимаемого сходства цветов на основе данных от носителей языков. Например, исследования показывают, что в русском языке «голубой» и «синий» образуют два отдельных кластера, в то время как в английском blue остаётся одним полем с градиентными переходами [6].

Интерактивные карты, такие как те, что представлены в базе данных WALS (World Atlas of Language Structures), позволяют сравнивать языки по

наличию базовых цветовых терминов, а также визуализировать географическое распространение тех или иных терминов цвета [7].

Следует отметить и тот факт, что цифровизация способствует развитию междисциплинарности проводимых исследований. Например, данные о цветовом восприятии из нейропсихологии (электроэнцефалографии, eye-tracking) можно сопоставлять с лингвистическими реакциями. Исследования показывают, что носители языков с раздельными терминами для «синего» и «голубого» быстрее различают эти оттенки в перцептивных задачах. Данный эффект лингвистической относительности, который становится измеримым благодаря цифровым экспериментам с носителями различных языков.

Подводя некоторые итоги, мы можем выделить определенные преимущества и риски цифровизации лингвистических исследований. Среди преимуществ, прежде всего, следует отметить следующие:

– масштабируемость проводимых исследований: возможность охватить сотни языков и тысячи участников;

– точность определения цветового оттенка и соответственно точность полученных данных: стандартизированные цветовые модели и автоматизированный сбор данных;

– воспроизводимость модели проводимых экспериментов: открытые данные и коды экспериментов позволяют реплицировать исследования;

– интеграция полученных данных: объединение лингвистики с данными из психологии, антропологии, дизайна.

Однако не следует забывать и о возникающих рисках использования цифровых технологий:

– техническая неоднородность: различия в калибровке экранов могут искажать восприятие цвета;

– этические вопросы: защита персональных данных;

– языковая и культурная предвзятость: большинство цифровых платформ ориентированы на английский язык и западные цветовые образцы как базу данных;

– нехватка специалистов лингвистов-программистов: требуется синтез лингвистических, программных и когнитивных компетенций.

Перспективы и заключение. Цифровизация открывает новые горизонты для изучения терминов цвета в различных языках. В качестве перпективных результатов лингвистических исследований цветовой терминологии можем предположить следующие:

– создание глобального цифрового атласа цветовой лексики с интерактивными картами и ИИ-анализом;

– использование машинного обучения для прогнозирования развития цветовой лексики в языках;

– разработку стандартов для цифровых цветовых экспериментов;

Однако необходимо понимать, что цифровые методы не отменяют, а дополняют традиционные подходы. Они позволяют перейти от описательных моделей к аналитическим, от локальных наблюдений – к глобальным сравнениям. Изучение цветообозначений становится не только лингвистической, но и междисциплинарной задачей, отражающей сложную связь языка, восприятия и культуры в цифровую эпоху.

ЛИТЕРАТУРА

1. Мичугина С.В. Денотативное пространство прилагательных цвета в английском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. М., 2005. 24 с. EDN NIMRMR.

2. Мичугина С.В. О некоторых подходах к изучению цвета и цветонаименований // Аракинские чтения. Актуальные проблемы лингвистики и методы преподавания английского языка: Сборник научных трудов. Москва: МГПУ, 2002. С. 97–109. EDN SRFFEA.

3. Рош Э.Х. «Естественные категории». Когнитивная психология. 1973. 4 (3): 328–50.

4. Berlin B., & Kay P. Basic Color Terms: Their Universality and Evolution. University of California Press. 1969.

5. ColourLex. Sience and Art. URL: https://colourlex.com/das-farbenbuch/

6. Regier T., Kay P., & Khetarpal N. Color naming universals: The role of color stability and salience. Proceedings of the National Academy of Sciences. 2005. 102(43), 15278–15283.

7. Monaghan P., et al. The role of experience in the acquisition of color terms. Cognitive Science. 2018. 42(2). 397–429.

8. WALS Online – World Atlas of Language Structures. https://wals.info

9. Taylor K.I., de Bruin, H., & Ruesch, J. ColourLex: A database of colour terms in 100 languages. Proceedings of the 19th Workshop on the Semantics and Pragmatics of Dialogue. 2015. P. 147–155.

УДК 811.512.212 + 215

Морозова Ольга Николаевна
Амурский государственный университет
Благовещенск, Россия
Morozova Olga Nikolaevna
Amur State University
Blagoveshchensk, Russia
E-mail: morozova_olga06@mail.ru

ФОНЕТИЧЕСКАЯ АДАПТАЦИЯ В ТУНГУСО-МАНЬЧЖУРСКИХ ЯЗЫКАХ: ТИПЫ ВЛИЯНИЯ КОНТАКТИРУЮЩИХ ЯЗЫКОВ

PHONETIC ADAPTATION IN TUNGUSIC LANGUAGES: TYPES OF INFLUENCE FROM CONTACT LANGUAGES

Аннотация. *Контактное влияние вызвало дивергенцию фонетики эвенкийского (РФ) и орочонского (КНР) языков. Русский язык спровоцировал смену апикального уклада на дорсальный у эвенков, а орочоны сохранили апикальность благодаря контактам с китайским и даурским. В эвенкийском ослабла роль аспирации, тогда как в орочонском возникло противопоставление по придыхательности. Выявлены интерференционные явления в орочонском, включая маркировку конечного гласного. Интонационные системы дивергируют: орочонскому свойственна слоговая мелодичность, эвенкийскому – речитативный контур. Внешние факторы приводят к трансформации артикуляционно-акустических баз и взаимному непониманию носителей тунгусских языков разных стран.*

Annotation. *Contact influence has caused a divergence in the phonetics of the Evenki (RF) and Oroqen (PRC) languages. Russian triggered a shift from an apical to a dorsal articulation setting among the Evenki, while the Oroqen retained apicality due*

to contacts with Chinese and Daur. The role of aspiration has weakened in Evenki, whereas a contrast based on aspiration has emerged in Oroqen. Interference phenomena have been identified in Oroqen, including the marking of the final vowel. The intonation systems diverge: Oroqen is characterized by syllabic melodicity, while Evenki has a recitative contour. External factors lead to a transformation of the articulatory-acoustic bases and mutual unintelligibility among Tungus speakers of different countries.

Ключевые слова: *тунгусо-маньчжурские языки, фонетическая адаптация, артикуляционный уклад, аспирация, интерференция, интонация*

Keywords: *Tungusic languages, phonetic adaptation, articulation setting, aspiration, interference, intonation*

В настоящее время в языках тунгусов северо-востока Азии зафиксированы фонетические инновации, которые мы связываем с адаптацией их звуковых систем к фонетике контактирующих с ними языков.

Речь идет о двух типах такой адаптации в регионе Верхнего Приамурья. А.М. Певнов называет Верхнее Приамурье географическим центром интенсивных языковых контактов, способствующих появлению новых языков [5: 194]. Ю. Янхунен придерживается такого же мнения и считает регион Большого Хингана на правобережье Амура в КНР колыбелью зарождения тунгусских и монгольских языков [9].

На примере Верхнего Приамурья можно выделить два типа адаптации звукового строя тунгусских языков: 1) современный левобережный эвенкийский (говоры эвенков Амурской области, РФ), который несет в себе явления взаимодействия фонетических систем русского и якутского языков; 2) правобережный орочонский (говоры орочонов провинции Хэйлунцзян КНР), адаптирующийся под слоговой китайский язык, что проявляется в воздействии на звуковую систему орочонского языка в целом, и на отдельные участки речевой цепи в частности.

Результаты нашего исследования основаны на применении экспериментальных методик, как артикуляционных, так и акустических. Материал для фонетических исследований в формате аудио записывался в лабораторных условиях Амурского государственного университета и, в дальнейшем, проводился его анализ в компьютерных программах по обработке звукового сигнала PRAAT, Audacity. Для получения данных об артикуляции языков коренных народов Амурской области мы сотрудничали с Дальневосточным научным центром физиологии и патологии дыхания, расположенном в г. Благовещенске и использовали методики МРТ (магнито-резонансной томографии). В ходе таких медицинских и акустических процедур мы получаем томограммы, где отчетливо можно проследить артикуляционно-акустическую базу и динамику её развития у современных эвенков Амурской области.

В ходе сопоставления сегментных и супрасегментных характеристик звуковых единиц эвенкийского языка России и орочонского языка Китая, мы постарались определить изменившуюся специфику артикуляционно-акустических баз современных тунгусов Приамурья.

У рассматриваемых языков прежде всего хотелось бы отметить разный артикуляционный уклад. У орочонов артикуляционный уклад остался этнически неизменным – апикальным – поскольку окружающие его язы-

ки такие же апикальные. У современных эвенков России артикуляционный уклад – дорсального характера. Процесс артикуляционных изменений у эвенков России в историческом развитии периода последних 80-ти лет зафиксирован данными экспериментальной фонетики.

Как показывали экспериментально-фонетические исследования артикуляции у эвенков России, постепенная смена апикального тунгусского уклада на дорсальный русский происходила, начиная с конца 30-х гг. прошлого века [3; 1; 7]. В первых фонетических экспериментах 1930-х гг. по изучению артикуляторных привычек эвенков фиксируется общий апикальный уклад артикуляторных органов при производстве тунгусской речи. Например, эвенкийский /l/ в 1937 году в речи ербогаченских эвенков представлял собой переднеязычный апикальный щелевой звонкий согласный [3: 158], уже через 50 лет в конце 1980-х аналоговыми приборами регистрируются редко апикальные, чаще дорсальные настройки эвенкийских переднеязычных согласных [1: 62].

В эксперименте М.И. Матусевич, проводившимся в 1937 г. в Ленинграде, были получены палатограммы эвенкийских переднеязычных согласных, исследование которых доказывало апикальную артикуляцию в ротовой полости говорящих на эвенкийском языке [3]. В эксперименте Т.Е. Андреевой, проведенном 50 лет спустя в 1987 г. в Новосибирске, на дентопалатограммах и рентгеносхемах уже фиксируются слабоапикальные артикуляции переднеязычного латерального /l/ в словах *лу* ‘смола’, *ала* ‘вкусный’, *дял* ‘ум, разум’ [1: 62]. Наконец, спустя уже 30 лет в Лаборатории экспериментально-фонетических исследований им. В.М. Наделяева новосибирского академгородка по данным рентгенографирования и магнитно-резонансной томографии группа ученых получает данные о кардинальной смене этнической артикуляции эвенков России с апикальной на дорсальную. Их вывод: переднеязычные настройки согласных звуков в эвенкийском языке являются дорсальными, кончиковых (апикальных) не зафиксировано [7].

За пределами нашей страны, у орочонов КНР, не имеющих контактов с носителями русского языка, сохраняется этнический апикальный уклад речи. Соматические данные, полученные нами от орочонов провинции Хэйлунцзян (орочонская деревня Синьшэн), методом статического магнитно-резонансного томографирования (МРТ), показывают сохранность апикальной артикуляции у переднеязычных /t^h/, /t/, /s/, /n/. Тем не менее, дорсальные реализации [ʃ]-аллофона переднеязычной щелевой фонемы /s/ имеются, а плавный переднеязычный /l/ реализуется в своей какуминальной артикуляции. Причины сохранности апикального типа настройки основного произносительного органа (языка) у орочонов, по нашему мнению, объясняются отсутствием коммуникации с представителями других этносов, в артикуляторной базе которых имеются дорсальные типы переднеязычных. Орочоны правобережья Амура уже более ста лет проживают в тесном соседстве с носителями китайского и даурского языков, тип артикуляционного уклада которых учеными определяется как апикальный (см. о китайском языке [8: 34, 39, 41, 45], даурском [6: 128]).

Таким образом, эвенкийский и орочонский языки разошлись прежде всего в артикуляционном укладе, который в языке эвенков под влиянием

русского языка стал дорсальным, а в языке орочонов при поддержке китайского остался апикальным (хотя и не без дорсальных реализаций).

Кроме того, одной из современных тенденций в развитии языка эвенков России является уход от придыхательности речи, под которой вслед за Л.П. Зиндером мы понимаем выдох, продолжающийся некоторое время после взрыва, главным образом, у смычных согласных до начала следующих гласных [2: 120]. Аспирация у эвенкийских шумных смычно-взрывных перешла из дифференциального в интегральный признак и в настоящее время не участвует в противопоставлении фонем /p/ – /b/, /t/ – /d/, /k/ – /g/ [4: 342]. И, напротив, звуковая картина орочонского языка Китая отличается от эвенкийского языка России большей интенсивностью (громкостью) и насыщенностью шумовыми параметрами сегментов с дополнительными гортанными артикуляции. На слух русскоязычного человека орочонский язык в отличие от эвенкийского более громкий и шумный.

С другой стороны, в ходе экспериментов нами была зарегистрирована реализация аспирированных шумных смычных в орочонском языке КНР, которая отсутствовала у аналогичных согласных в языке эвенков России. Оказалось, что орочонские пары губно-губных, переднеязычных и заднеязычных смычных согласных фонем /p^h/ – /p/, /t^h/ – /t/, /k^h/ – /k/ противопоставлены не по признаку глухости/звонкости, а по придыхательности/непридыхательности, вероятно, при поддерживающем влиянии соответствующих пар инициалей доминирующего китайского языка. Как уже указывалось, данное противопоставление в языке селемджинских эвенков не фиксируется. Например, в орочонских словах *малу* [t^halu] ‘береста’ и *таусун* [tausun] ‘соль’, первые согласные звуки данных слов противопоставлены не по признаку глухости/звонкости (как это было бы в эвенкийском языке), а по наличию аспирированного шума и его отсутствию.

Данностью современности становится факт, что китайский язык для орочонов, усвоенный вторым, стал в настоящее время функционально первым (что также верно и для русского языка эвенков России). Представим некоторые выявленные нами фонетические факты интерференционного влияния китайского языка на орочонский, которые проявляются в: 1) эллиптировании либо рефлексе конечного сонорного при сохранности назализации предшествующего гласного; 2) глухости этнически звонких шумных и оглушенности (по крайней мере, начала реализации) сонорных согласных; 3) включенности гортанных дополнительных артикуляций в фонацию конечной фазы орочонского слова.

Последние данные акустического анализа орочонской речи позволили выявить синергетический комплекс фонетических характеристик конца орочонского слова (изолированно произнесенного). Можно говорить об особом механизме маркировки орочонского ауслаутного гласного. Маркеры последнего следующие: 1) увеличение интенсивности (громкости); 2) увеличение длительности; 3) усиление плотности колебания голосовых связок; 4) усиление надсвязочных качественных модуляций фарингализации, эпиглоттализации; 5) крутое движение гортани сверху вниз (интонограмма показывает крутое падение интонационного контура вниз).

Наблюдаются отличные тенденции в реализации эвенкийских и орочонских интонационных конструкций. Самой яркой чертой в интонации

орочонского языка является то, что каждый слог получает самостоятельное мелодическое оформление.

Основной отличительной особенностью интонации в речи эвенков является наличие речитативных мелодических отрезков и небольших восходящих и нисходящих переходов между ними. Контрастные изменения уровня высоты основного тона в эвенкийской речи обусловливают ступенчатый характер мелодического рисунка в целом и реализуются в сравнительно небольшом мелодическом диапазоне. Это находит отражение в общей монотонной интонации утвердительных предложений эвенкийского языка.

В настоящее время в данном трансграничном регионе северо-востока Азии имеется ситуация резкого языкового контраста, когда тунгусы-билингвы, общаясь на своих родных языках (эвенкийском и орочонском), понимают друг друга плохо либо вообще не понимают. Использующие в своем повседневном общении разные доминирующие языки, эвенки России и орочоны Китая адаптировали свои артикуляционно-акустические базы, что вызвало кардинальную трансформацию тунгусских звуковых систем РФ и КНР.

Выводы. 1. Дивергенция звуковых систем левобережного эвенкийского и правобережного орочонского языков Приамурья породила ряд фонононваций, которые, детерминированы взаимодействием внутренних лингвистических факторов и внешних лингвистических и экстралингвистических факторов, включающих диалектное разнообразие и давление фонологических систем и моделей их реализации контактирующих языков.

2. При сопоставлении сегментных и супрасегментных характеристик звуковых единиц эвенкийского и орочонского языков на современном этапе их развития, были выявлены факты изменившейся специфики артикуляционно-акустических баз современных тунгусов Приамурья.

3. Возникшие в относительно недавнем прошлом фонетические новации в генетически родственных тунгусских языках коренного населения северо-восточной Азии показывают, каким образом происходит адаптация языков (в данном случае сингармонических) в ситуации их глобализационного вытеснения доминирующими языками из всех сфер функционирования, включая семейно-бытовую коммуникацию.

ЛИТЕРАТУРА

1. Андреева Т.Е. Звуковой строй томмотского говора эвенкийского языка. Новосибирск: Наука, 1988. 142 с.

2. Зиндер Л.Р. Общая фонетика: Учеб. пособие для филол. фак. ун-тов. 2-е изд., перераб. и доп. М.: Высш. школа, 1979. 312 с.

3. Матусевич М.И. Очерк системы фонем ербогоченского говора эвенкийского языка на основе экспериментальных данных // Учёные записки ЛГУ. Сер. филол. наук. 1960. Вып. 40. № 237. С. 132–169.

4. Морозова О.Н. Парадигматика и синтагматика звуковых систем тунгусских языков верхнего приамурья (на материале эвенкийского и орочонского языков): дис. ... д-ра филол. наук. Благовещенск, 2021. 481 с.

5. Певнов А.М. Работа над рукописью С.М. Широкогорова «Ороченско-русский словарь (1912–1913)» // Социальные взаимодействия, языки и ландшафты в Сибири и Китае (эвенки, эвены, орочоны и другие группы: Сб. тр. Третьей международной

междисциплинарной Тунгусской конф. / гл. ред. С.В. Андросова. Благовещенск: ООО «ИПК «Одеон», 2019. С. 187–196.

6. Поппе Н.Н. Дагурское наречие. Ленинград: Изд-во Акад. наук СССР, 1930. 174 с.

7. Селютина И.Я., Уртегешев Н.С., Добринина А.А. Типологическая специфика эвенкийского консонантизма (по данным рентгенографирования и МР-томографирования) // Сибирский филологический журнал. 2014. С. 186–191.

8. Спешнев Н.А. Фонетика китайского языка. Учеб. пособие. Л.: Изд-во Ленинград. ун-та, 1980. 141 с.

9. Janhunen J. A. Prolegomena to a Comparative Analysis of Mongolic and Tungusic // Proc. of the 38th Permanent International Altaistic Conference (PIAC), Kawasaki, Japan: August, 7–12, 1995. Ed. by G. Stary. Harrassowitz Verlag, Wiesbaden, 1996. P. 209–218.

УДК 811.512.14

Мөгътәсимова Гөлназ Ринат кызы
Казан (Идел буе) федераль университеты
Казан, Россия
Мугтасимова Гульназ Ринатовна
Казанский (Приволжский) федеральный университет
Казань, Россия
Mugtasimova Gulnaz Rinatovna
Kazan (Volga Region) Federal University
Kazan, Russia
E-mail: Gulnaz.Mugtasimova@kpfu.ru

ГАИЛӘДӘ КАБУЛ ИТЕЛГӘН ТРАДИЦИЯЛӘРНЕ РЕПРЕЗЕНТАЦИЯЛИ ТОРГАН ТАТАР МӘКАЛЬЛӘРЕ

ТАТАРСКИЕ ПОСЛОВИЦЫ, РЕПРЕЗЕНТИРУЮЩИЕ СЕМЕЙНЫЕ ТРАДИЦИИ

TATAR PROVERBS REPRESENTING FAMILY TRADITIONS

Статья посвящена семейным ценностям, которые отражены в татарских пословицах. В работе представлено понятие и назначение пословиц, их связь между человеком и обществом. Через интерпретацию пословиц раскрываются взаимоотношения между супругами, родственниками, детьми, определяется смысл существования человека в семье. Объясняется роль семейных традиций, совместного труда, уважение старшего поколения, воспитание детей.

Annotation. *The article is devoted to family values, which are reflected in Tatar proverbs. The paper presents the concept and purpose of proverbs, their connection between man and society. Through the interpretation of proverbs, the relationship between spouses, relatives, and children is revealed, and the meaning of a person's existence in the family is determined. The role of family traditions, joint work, respect for the older generation, and parenting is explained.*

Ключевые слова: *татарский язык, пословица, семья, семейные ценности, семейные традиции, семейные взаимоотношения*

Keywords: *Tatar language, proverb, family, family values, family traditions, family relationships*

Татарларда хатынның һәм ирнең гаиләдәге урынын билгели торган мәкальләр шактый күп. Алар гаилә тормышының үзәген тәшкил итәләр. Мәкальләрдә алар һәрвакыт бергә. Алга таба без аларны берничә төркемчәгә бүлеп карарбыз.

Беренче төркем – хатынның һәм ирнең бер бөтен булуын күрсәтүче мәкальләр. Мәсәлән, *Бизмән белән гер бергә, хатын белән ир бергә; Ир белән хатын арасына кыл да сыймый; Ир белән хатын – бер җан, бер тән; Ир белән хатын – икесе бер камырдан; Ир белән хатын бер балчыктан коелган; Ир белән хатын икесе бер чыбыктан сөрелгән; Ир белән хатын керешеп беткән; Ир белән хатын куш тирәк, төбер бер дә тамыры бер; Ир белән хатын – игезәк җан; Ир белән хатын – куш тирәк, төбе бер дә тамыры бер; Ир белән хатынның туфрагы бер.*

Рухи бергәлек ир белән хатын арасындагы бәйләнешнең ныклыгын күрсәтеп тора. Гаилә проблемалары бергә хәл ителүе турында сөйли. Татар халык мәкальләре ир белән хатын арасына чит кешеләрнең кысылмавын киңәш итә: *Ир белән хатын арасына кергәнче, кылыч белән кылыч арасына кер; Ир белән арасына кергәнче, утка кер; Ир белән хатын арасына күзе чыккан керер; Ир белән хатын арасына кыл да сыймый; Ирле-хатынлы арасына иске киткән катышыр.*

Мәкальләрдә ирсез калуның хатын-кыз өчен иң начар җәза булуы әйтелә: *Ятим хатын – канаты сынган кош; Тол хатынга мунчаның актыгы, түшәкнең ястыгы; Ялгыз хатын – канатсыз кош* һәм башкалар.

Икенче төркем – гаиләдәге бәхәсләр турындагы мәкальләр. Бу турыда татар халкы болай ди: *Атына ачуланган хатынын кыйнаган; Ахмак хатыны белән булашыр; Ир белән хатын талашыр, түшәгендә ярашыр; Ир какканны ил кагар; Ирне үзеннән чыгарма!* һәм башкалар.

Өченче төркем – гаиләдә ирләрнең баш булуы турындагы мәкальләр. Гаиләдә ирләрнең баш булуы, ә хатыннарның буйсынып яшәве татар мәкальләрендә чагылыш тапкан. Мәсәлән, *Ир – баш, хатын – муен; Ир – ат, хатын – арба; Ир – аяк, хатын – олтырак; Ир – беләк, хатын – терәк; Ир – келәт, хатын – йозак, Ир хакы – тәңре хакы* һәм башкалар.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, ир белән хатын образларының метафоралары татар гаилә-никах традицияләренең мөһим компоненты булып тора. Мисаллардан күренгәнчә, ир белән хатын образларының кеше органнарын тасвирлау аша кызыклы метафорасы барлыкка килгән.

Болар барысы да татарларда патриархаль гаилә мөнәсәбәтләре булуы турында сөйли. Г.Б. Сайфутдинова, Ю.Е. Железнякова һәм Т.А. Титова да үзләренең «Семья и брак у татар Поволжья: культура, традиции и обряды» мәкаләсендә татар гаиләсенең патриархаль һәм авторитар принципларга нигезләнүен искәртәләр, гаилә әгъзаларының – өлкәннәргә, хатыннарның ирләренә берсүзсез буйсынуын билгеләп үтәләр [4].

Күпчелек очракта гаиләдә төп рольне өлкән ир-ат башкарган. Җир, җитештерү чаралары һәм акча гаилә башлыгы – ир кулында тупланган булган. Гаиләдә татар хатын-кызлары өстенлек итү очраклары бик сирәк күренеш булган [1: 121].

Әйе, алда каралган мисаллар галимнәрнең фикерләрен раслап, ирнең хуҗалык һәм гаилә башлыгы булып килүен күрсәтәләр. Шул ук вакытта *Ир – баш, хатын – муен* дигән татар мәкале хатынның муен булып, ирне кая тели шунда борып йөртүен, хатыннан башка ирнең беркая да борыла

алмавын күрсәтә. Мондый мәкаль башкорт, казах халкында да бар: *Ир – баш, ҡатын – муйын; Еркек – бас, ургашы – моен.*

Шуңа күрә татар мәкальләрендә ир кешенең гаиләдә баш булуы уңай дип каралса, хатыннарның баш булуы – бик тискәре күренеш. Мәсәлән, *Заман ахыры булганда, һәркем хатын сүзе белән йөрер имеш; Ире басынкы булса, хатыны дуамал булыр; Ир кеше үз вазифасын белмәсә, аңа хатыннар баш була, ди; Бер әтәч тугыз тавыкка баш, бер ир бер хатынга баш булалмаган; Әкрен иргә хатын баш.*

Дүртенче төркем – хатыннарның гаилә терәге булуы турындагы мәкальләр. Чыннан да, гаилә учагын саклауда хатын-кыз аерым урын тота: *Йорт тоткан да хатын, йорт бетергән дә хатын; Начар гармун көй бозар, начар хатын өй бозар; Хатын булмый, өй булмас; Хатынсыз йорт – ел кебек* һәм башкалар.

Мәкальләрдә ата-аналар һәм балалар арасындагы мөнәсәбәт тә ачык чагыла. Әлбәттә, монда әнинең роле бик зур икәне ачыклана. Кыз яки хатын белән чагыштырганда, ана гаиләдә бик зур йогынты көченә һәм абруйга ия. Бу, әлбәттә инде, халык авыз иҗатында да чагылыш таба: *Ана хакын уч төбендә тәбә кыздырып ашатсаң да кайтара алмассың; Ананың бер догасы җиде мулла догасына җитә; Кояш янында – җылылык, ана янында – изгелек; Ана җылысы – кояш җылысы; Җәннәт аналарның аяк астында* һәм башкалар. Монда анасын кадерләгән, хөрмәт иткән кеше генә бәхеткә лаек була алуы турында ассызыклана.

Ата-ана дигәндә, ата сүзе алга куелган. Әти кеше гаиләне яшәтүче, тукландыручы, сакчысы булып санала. Татар халкында ир, егет, балалар – әтиләре янында, кыз бала әниләре янында, аларның үрнәгендә үсәргә тиеш дигән караш яши. Мәсәлән, *Ата аркасы – кала аркасы; Атаңа ни кылсаң-алдыңа шул килер; Атасына күрә баласы; Ата булмаган ата кадерен белмәс* һәм башкалар.

Әлеге мәкальләр әти белән әнинең гаиләдәге абруен, хөрмәтен күрсәтә. Яшь чактан ук алар балаларда олыларга карата хөрмәт хисе, мөхтәрәмлек хисе тәрбиялиләр. Һәр кешедә җиденче буынга кадәр үзенең ата-бабаларын белергә тиеш. Баласыз өй тулы булмый. Балалары булмаган гаилә бхетсез гаилә булып санала. Әгәр дә гаиләдә балалар булмаса кешеләр аны бозым яки каргыш белән аңлаталар. Кызларны әни белән әбиләре өй хуҗалыгын алып барырга аш-су әзерләргә өйрәтә. Шулай ук яшь балаларны карау да алар өстенә төшә. Шуңа күрә яшүсмер чагына кыз бала инде бар эштә дә әнисенә ярдәмче. Кияүгә чыккач, ул ире гаиләсенә күченә. Анда ул кайана сүзен тыңларга тиеш һәм үзенең эш сөючәнлеге белән ихтирам яулап алырга тиеш . йорт хуҗалыгын алып бару тәҗрибәсен туплап балалар үстереп ул тулы хокуклы хуҗабикә була. Татар телендә гаилә һәм гаиләнең көнкүреше темасы белән бәйләнгән күп кенә мәкаль әйтемнәр бар. Аларда традицион гаилә моделе, рухи байлыклар чагылдырыла.

Балалар тәрбияләү процессында гаиләнең иң мөһим вазифаларының берсе этномәдәният кыйммәтләрен тапшыру һәм этник үзаң тәрбияләүдән гыйбарәт.

Мәкальләрнең төп эчтәлеге өлкәннәргә охшарга тырышуга кайтып кала. Кияүгә чыкмаганнар – киленнәргә, энеләре – абыйларына, кызлары – әниләренә, уллары әтиләренә охшарга тырыша: *Аганы күреп, эне үсәр, апаны күреп сеңел үсәр.*

Гаиләдә улларның варис булуын, ә кызларның бернинди хокуклары да булмавын мәкальләр дә күрсәтеп тора: *Ир бала туса, сөнече күбрәк була; Ул туганга көн туа.*

Гаиләдә кабул ителгән традицияләрне репрезентацияләүне өйрәнгәндә, татар паремиологик сурәтендә чагылыш тапкан ир туганнар һәм кыз туганнар арасындагы традицион гаилә мөнәсәбәтләренә дә тукталу сорала. Һичшиксез, татар гаиләсе традицияләрендә ир туганнар һәм кыз туганнар арасында «туганлык» традициясе саклана. Татар телендә туганлык сүзе түбәндәгечә билгеләнә: 1) Кардәшлек. 2) күч. Үзара дуслык, иптәшлек мөнәсәбәтләре, бердәмлек, бергәлек [5: 559]. Димәк, бу сүзнең беренче мәгънәсе һәм аның тамырдаш сүзләрендәге мәгънәсе (мәсәлән: туганлыклы, туганнарча, туган-тумача, туган-тумачалык, туганчыл, туганчыллык һәм башкалар) татар гаиләсе тормышында кешеләр арасындагы якын эмоциональ мөнәсәбәтләрне белдерә ала. Моны раслау өчен, мисаллар китерик: *Агайлар булса, аш килер, туганнар булса, ту килер; Ата белән ул йөрәге бер булса, баскан туфрагың алтын булыр; туганнар көче бер булса, таулар җәүһәр булыр; Ике туган бергә килсә, сандугачтай сайрашыр; Ике туганнан аю да курка; Туган кеше – якты таң; Туган күп тә, бертугандай булмый, таныш күп тә, кардәшеңдәй булмый; Туган-кардәш, дус-иш белән бер утыру – бер гомер.*

Туганлык хисе кан кардәшлеге нигезендә барлыкка килү белән генә чикләнми, ә татар гаиләсенең яхшы гадәтләре аркасында да ныгый, алар буыннан-буынга күчә.

Татар гаилә традициясендә «абый һәм апа кебек» дигән язылмаган кагыйдә бар: *Аганы күреп эне үсәр, апаны күреп сеңел үсәр; Агам кемне алса, җиңгәм шул, апам кемгә барса, җизнәм шул; Агасының кигәнен энесе дә кияр, апасының кигәнен сеңлесе дә кияр; Ага-эне – ага-эненең көзгесе; Агай-эне белән аш татлы; Агасы барның ырысы бар, энесе барның тынычы бар.*

Күп балалы гаиләдә олы абый үз буыны башлыгы буларак кабул ителә һәм һәрвакыт кече балаларны яклауны үз өстенә ала. Шул ук вакытта алар олы абыйларына күбрәк бәйле булалар һәм соңрак аңсыз рәвештә аның тәртипләрен үрнәк итеп тоталар. Менә шушы гадәт татар мәкальләрендә чагылыш тапкан да инде. Гадәттә, эти-әнисе үлгәч, аңа этисенең йорт хуҗасы вазифасын үз өстенә алырга туры килә. Мәсәлән, татар мәкалендә болай дип әйтелә: *Атаң үлсә, олы абзыең – атаң, анаң үлсә, аның урынында олы апаң; Олы ага – икенче ата.*

Шул ук вакытта кече абый-кардәшләр дә өй эшләрендә ярдәм итәргә тиеш. Борынгы заманнардан ук татар гаиләсендә эшләрнең төгәл бүленеше булган. Абыйлар аучылык, игенчелек, балык тоту кебек ирләр эше белән шөгыльләнә. Кыз туганнар өйдә ризык әзерли, кием юа яки чигү чигә.

Татар гаиләсендә олы апа еш кына эти-әниләренә өй эшләре белән шөгыльләнергә, кече балаларны карарга ярдәм итә. Шулай итеп, ул традицион рәвештә әнисенең ярдәмчесе яки «урынбасары» дип санала. Олы апаның үрнәге хәтта сеңлесенең кияүгә чыгуы белән тыгыз бәйләнештә тора. Күп балалы гаиләдә кече апаны олысының шәхси сыйфатларын исәпкә алып бәялиләр һәм кияүгә алалар. Шуңа күрә ул гадәттә үз тәртибенә игътибар итә, гаиләсенең, аерым алганда, сеңелләренең намусын яклый. Моны татар мәкальләре дә раслап тора: *Апасын күзәт, сеңлесен ал.*

Кайвакыт туганнар арасындагы мөнәсәбәтләр гаилә милке, шәхси мәнфәгатьләр, көнчелек яки дошманлык аркасында бозыла. Моны раслау өчен, мисаллар китерик: *Агай-эне азса, ала булыр; Агай-эне, ерак булса, кешнәшә, якын булса, тешнәшә; Агай-эне якын йөрсә, кадере юк; Агай-эненең ызгышы – авызның сасысы белән бер; Агай-эне талаша, атка менсә яраша.*

Бу шуны күрсәтә: кан кардәшлеге туганнар арасындагы яхшы мөнәсәбәтләрне тулысынча тәэмин итә алмый.

Әмма татар гадәтләре арасында милли лингвомәдәни күренеш ачыклана: *Ашамасаң да, май яхшы, яманласаң да агай яхшы; Яхшы ага энесенең хәтерен калдырмас.* Күрәсең, кайвакыт гаилә конфликтлары кардәшләргә гомуми гаилә аңын саклап калу мөмкинлеге бирә.

Ир туганнар һәм кыз туганнар арасындагы традицион гаилә мөнәсәбәтләре гаилә традицияләренең бер өлешен тәшкил итә һәм дөньяның милли тел картинасында лингвомәдәни стереотипларга әверелә.

Шулай итеп, тәкъдим ителгән мәкальләрнең мәгънәсе татар халкының гаилә кыйммәтләрен чагылдыра, ир белән хатын, ата-аналар һәм балалар арасындагы мөнәсәбәтләрдә гаять зур тәҗрибә туплый, гаилә мөнәсәбәтләрен төзүдә хәзерге буынга киңәшләр бирә. Халык зирәклеге юл куярга, рәнҗетүне онытырга, яхшылык белән җавап бирергә яки дәшмәскә өйрәтә. Бу мираска ихтирам белән карарга кирәк. Гаилә үзенең актуальлеген югалтмас, ә акыллы сүзләр хәзерге гасырда юкка чыкмас дип өметләнергә кала.

ӘДӘБИЯТ

1. Бусыгин Е.П. Сельская женщина в семейной и общественной жизни. Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1986. 144 с.

2. Замалетдинов Р.Р. Конструирование картины мира и паремиологический фонд языка // Филология и культура. 2010. № 19. С. 54–58.

3. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. Т.1. Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. 913 б., Т. 2, 1963. 959 б., Т. 3, 1967. 1013 б.

4. Сайфутдинова Г.Б., Железнякова Ю.Е., Титова Т.А. Семья и брак у татар Поволжья: культура, традиции и обряды // Проблемы современного педагогического образования. 2019. № 62-4. URL: https://cyberleninka.ru/article/n/semya-i-brak-u-tatar-povolzhya-kultura-traditsii-i-obryady (дата обращения: 10.09.2025).

5. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / Баш ред. Ф.Ә. Ганиев. Казан: Матбугат йорты, 2005. 848 б.

УДК 372.882

Мөхәрләмова Гөлназ Нурфат кызы
ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
Казан, Россия
Мухарлямова Гульназ Нурфатовна
Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
Казань, Россия
Mukharlyamova Gulnaz Nurfatovna
G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art
of the Tatarstan Academy of Sciences
Kazan, Russia
E-mail: mukharlamgul@gmail.com

ТЕЛ ЧАРАЛАРЫ ЯРДӘМЕНДӘ ЭМОЦИОНАЛЬ ИНТЕЛЛЕКТНЫҢ РЕПРЕЗЕНТАЦИЯСЕ
(Г. Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» повестен өйрәнү мисалында)

РЕПРЕЗЕНТАЦИЯ ЭМОЦИОНАЛЬНОГО ИНТЕЛЛЕКТА С ПОМОЩЬЮ ЯЗЫКОВЫХ СРЕДСТВ
(На примере изучения повести Г. Баширова «Родимый край – зеленая колыбель»)

USING LANGUAGE TOOLS REPRESENTATION OF EMOTIONAL INTELLIGENCE
(based on the example of studying G. Bashirov's novel «My homeland is the green cradle»)

Мәкалә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 16.07.2024 ел № 565 Карары нигезендә Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе ярдәмендә әзерләнде

Статья подготовлена при поддержке Академии наук РТ по Постановлению КМ РТ № 565 от 16.07.2024

Аннотация. *В статье рассматриваются вопросы репрезентации эмоций в художественных текстах с помощью языковых средств татарского языка, которая является одним из приемов формирования эмоционального интеллекта обучающихся на уроках родного (татарского) языка и литературы. Репрезентация эмоций, будучи важной частью языковой картины мира любого языка, занимает одно из главных мест в лингвистике и осуществляется посредством слов, номинирующих различные эмоции и чувства человека; с помощью эмотивных средств; слов, описывающих эмоции и чувства человека.*

Annotation. *The article discusses the representation of emotions in literary texts using the linguistic means of the Tatar language, which is one of the methods of developing students' emotional intelligence in the lessons of the native (Tatar) language and literature. The representation of emotions, being an important part of the linguistic worldview of any language, occupies a central place in linguistics and is carried out through words that nominate various emotions and feelings, as well as words that describe emotions and feelings.*

Ключевые слова: *эмоциональ интеллект, эмоция, чувства и переживания, репрезентация, языковые средства, художественный текст, эмотивная лексика*

Keywords: *emotional intelligence, emotion, feelings and experiences, representation, linguistic means, literary text, emotive vocabulary*

XXI гасырда тиз үзгәрүчән җәмгыятьтә кешеләрнең үзара хезмәттәшлекнең нәтиҗәлелеген билгеләүче иң мөһим күнекмәләреннән берсе булып эмоциональ интеллект тора. Эмоциональ интеллект «эмоция» һәм «эмоциональлек» төшенчәләре белән бәйле. Кешенең тормыш эшчәнлегендә мөһим роль уйнаган эмоцияләр аны яшәүгә, объектив чынбарлыкны танып белүгә, иҗади эшчәнлеккә, үз хис-кичерешләре аша үз-үзен билгеләүгә, тирә-юньдәгеләр белән аралашуга сәләтле итә [5: 58].

Эмоциональ интеллектны өйрәнү тел белемендә дә, әдәбият белемендә дә бүген актуаль мәсьәләләрдән санала. Художестволы текстның идея-мәгънә эчтәлеген тапшыру чарасы – тел, ә аның семантик яктан интерпретациясе формасы, ягъни хис-кичерешләрнең дөньяга бәяләү мөнәсәбәтен чагылдыру формасы булып эмоция тора. С.Дж. Стейн һәм Говард Бук фикеренчә, тел системасының лексик, грамматик һәм синтаксик дәрәҗәләрендә чагыла торган эмоциональ интеллект «башка кешеләрнең эмоцияләрен танып белү аша интуитив рәвештә башка кешеләрнең «теләкләрен» аңлата» [3: 40]. Моннан тыш, тел эмоцияләр белән, шул исәптән башка кешеләрнең эмоцияләре белән дә идарә итү, аларның ниятләрен, мотивациясен һәм теләкләрен аңлау сәләте турындагы күзаллауларны киңәйтүгә ярдәм итә» [2: 67].

Тел белемендә эмоциональ интеллект белән бәйле аны репрезентация мәсьәләсе дә аерым урын алып тора. Эмоцияләрне, хис-кичерешләрне күрсәтү, ягъни репрезантацияләү теләсә кайсы телнең дөнья тел картинасында мөһим бер өлеше булып, хәзерге лингвистикада төп урыннарның берсен алып тора [1: 40]. Репрезентация – ул кеше тарафыннан дөньяны күзаллау процессы үзе дә, һәм бу күзаллауның кеше психикасында яки билгеле бер белемнең телнең формасында күзалланганны алмаштыручы берәмлеге дә, ягъни вербаль тел репрезентациясе дә ул [4: 44].

Репрезентациянең берничә ысулы бар: кешенең төрле хисләрен номинацияләүче сүзләр ярдәмендә; эмотив чаралар ярдәмендә; кешенең хисләрен тасвирлаучы сүзләр ярдәмендә репрезентацияләү.

Эмоциональ интеллектка ия шәхес төрле эмоцияләр белән идарә итә, әйләнә-тирәдәгеләрнең хис-кичерешләрен аңлый, башка кешеләрнең хис-кичерешләренә тәэсир итә, хис-кичерешләрнең сәбәпләрен һәм нәтиҗәләрен ачыклый белә торган була. Димәк, эмоциональ интеллект – ул кешенең җәмгыятьтә яшәү, аралашу, хезмәттәшлек итү мөмкинлеген бирә торган шәхси компетенциясе.

Кешедә әлеге компетенциянең формалашуы балалык чорыннан, мәктәп елларыннан ук башлана. Бу вакытта туган тел һәм әдәбият дәресләре турыдан-туры укучыларда эмоциональ интеллект формалаштыручы төп предметлардан санала. Тел-әдәбият дәресләрендә өйрәнелә торган художестволы текстлар үзләрендә рухи тормышның эчтәлеген тәшкил иткән дулкынландыра, шатландыра, кайгырта, ләззәтләндерә, газаплый, тынычландыра, борчый торган хисләрне чагылдыра. «Укучыларның әдәби әсәрдә чагылыш тапкан тормыш картинасын эмоциональ яктан кабул итеп һәм интеллектуаль яктан аңлау «Туган (татар) телдәге әдәбият» уку предметының предмет нәтиҗәләреннән берсе булып күрсәтелә» [5: 58].

Эмотив лексиканың мөһим чыганагы булып әдәби әсәрләр тора, чөнки әдәби текст кешенең хисләре һәм хис-кичерешләре дөньясын билгеләгән төрле тел чараларын үз эченә ала. Бүген федераль эш программаларына

кергән әсәрләрнең барысы да укучыларның хис-кичерешләренә тәэсир итәрлек әсәрләр, алар төрле эмоцияләргә бай булуы белән аерылып тора. 7 нче сыйныфта өйрәнү өчен тәкъдим ителгән Гомәр Бәшировның «Туган ягым – яшел бишек» повестенда геройлар эмоцияләре, хис-кичерешләренең төрле тел чаралары ярдәмендә белдерүен күзәтеп була. Аларны тикшерү укучыга текстны тулы итеп аңлау, авторның идеясен, аның дөньяга мөнәсәбәтен тирәнрәк төшенергә ярдәм итә.

Билгеле булганча, художестволы текстта эмоцияләр, хис-кичерешләр төрле вербаль һәм вербаль булмаган чаралар ярдәмендә күрсәтелә, аларга лексик, грамматик һәм сурәтләү чараларын кертеп карыйлар.

Әйтик, әсәрдә рәхәтлек хисен кичергән төп геройның халәтенә игътибар иттерү максаты белән түбәндәге өзекләр тәкъдим ителә. Мәсәлән, рәхәтлек хисе номинатив лексика буларак билгеләгән очраклар:

*Йокының татлы ширбәте бөтен тәнемә таралган да шундый **рәхәт эчендә** оетып яткыра, минем, бу рәхәтне качырмас өчен, хәтта кыймылдап кына да карыйсым килми* [6: 42].

*Миндәге кайнарлык әле һаман да сүрелмәгән. Дәртле уенның әле генә **татыган рәхәте**, бөтен тәнемне биләп, үзалдына кинәндереп, күңелләрне җилкендереп тора* [6: 50].

*Менә син бер малайны уздың, менә икенчесен дә артта калдырдың. Син шул **рәхәтнең муллыгына** түза алмыйча, алдагы малайны да узып китәчәгеңә нык ышанган хәлдә, ташып торган бер җилкенү белән кычкырып җибәрәсең:*

– Һәәә-й-йт! Кагы-ы-ыл!.. [6: 48].

*Таунының буеннан-буена шулай буран уйнатып, сызгырып шуып төшәсең-төшәсең дә, кинәт бер заман җирдән аерылып, чын-чыннан очып китәсең! Инеш буендагы вак таллар, күпер төбендәге кар өемнәре аста кала, җиң очларыннан, изүләреңнән, бишмәт итегеңнән җил бәреп керә. **Очу рәхәтеннән** хәтта йөрәгең кысылып килә, күзләрең йомыла* [6: 48–49].

*Баш очындагы тәрәзәдән язгы җылымса җирнең бераз гына татлырак, бераз гына ниндидер үлән исләрен дә хәтерләтә торган ягымлы исе бөркелә башлый да, шушы **рәхәткә** тирбәлеп йоклап та китәсең* [6: 59].

***Рәхәт!** Чәнәшкәң оча гына. Менә гел шулай очасы да очасы, **рәхәтне** бик озакка сузасы килә* [6: 48].

Шул ук рәхәтлек хисен башка тел чаралары ярдәмендә белдерү очракларын билгеләтеп була. Алар алда күрсәтелгән мисалларда күзәтелә (*йокының татлы ширбәте*, *кыймылдап кына да карыйсым килми, кинәндереп, күңелләрне җилкендереп тора, йөрәгең кысылып килә, күзләрең йомыла, язгы җылымса җирнең татлы, ягымлы хисе)*. Шулай ук аларны рәхәтлек хисен турыдан-туры күрсәтмәгән повестьның башка җөмләләреннән дә табып була:

*Бераздан әни **йомшак** кына тагын бер дәшеп куйды* [6: 42].

*Су буйларына, тау битләренә – бөтен тирә-якка **тын гына, йомшак кына** кызгылт караңгылык иңә* [6: 47].

Әсәрдә шатлык хисен белдерүче номинатив лексика да очрый.

*Ишек алдына йөгереп чыксам, **шатлыгымнан** телдән кала яздым* [6: 42].

Әмма андыйларның күбесе соңыннан сагынып сөйләргә генә кала. Алар тора-бара күңел хәзинәсендә сабый чакның таң яктысы төсле саф һәм үтәдән-үтә күренмәле якты ***шатлыклары*** *белән кушылалар* [6: 47].

Сабан туен, язның бу шау-шулы, ыгы-зыгылы һәм ***шатлыклы*** *якты бәйрәмен без, малайлар, кар җепшекләнә башлагач ук көтәргә тотына идек* [6: 54].

Һәммәсе кулларын маңгайларына куеп күктәге матур булып тезелеп килгән өчпочмакка карыйлар, кадерле кунакларны каршы алгандай, йөзләре ***шатлык*** *белән балкый* [6: 56].

Текстта турындан-туры шатлык хисе телгә алынмаса да, укучыларның әлеге хисне тасвирлаган башка тел чараларын таптырып була.

Яр кырыенда утырган тәбәнәк баганалар, ***җелт тә җелт килеп, егылышып кына калалар*** [6: 49].

Бөтенесе ***уһылдый, көлә, кычкырып җибәрә*** [6: 49].

Канәгатьсезлек, ачу белән бәйле эмоцияләрне тасвирлаган башка тел чаралары да күрсәтеп тора:

Баскычларны ***яман*** да ***шак-шак китереп***, *үзем белән бер көтү суык ияртеп, ишектән килеп керүгә иң элек* ***яшь әтәч булып*** *апай* ***ташланды****:*

– Ә, кайттыңмы, эшем кешесе? Әле ярты төн дә җитмәгән ич, тагын йөрисең калган! [6: 50].

Кашлары җимерелгән*, такыр* ***башын*** *чабатасына* ***игән*** [6: 51].

Мин колынны аркасыннан сыйпамакчы булып «бәһ-бәһ» дип янына бара гына башлаган идем, бия, яман да ***ачуланып****, колакларын шомартты, дәү* ***сары тешләрен ыржайтып****,* ***ашардай булып*** *башын миңа таба айкады* [6: 43].

Боегу, күңелсезләнү, төшенкелек хисләренең репрезентациясе түбәндәге җөмләләрдә күзәтелә:

Бөтен дөнья ***боеккан****. Келәт кәрнизендә, кызыл тәпиләрен корсак асларына яшереп, күгәрченнәр* ***бөрешеп утыра****. Агач ботакларындагы кабарынкы йонлы мескен чыпчыклар* ***төшенке*** *тавыш белән:*

– ***Суык-суык, суык-суык****! – дип* ***зарланалар*** [6: 76].

Мин тиз генә үз җиремә борылып карадым. Шунда миңа бик тә ***күңелсез*** *булып китте. Җир өстендә ат башы тикле* ***кантарлар турсаеп тора*** [6: 74].

Әсәрдә пейзаж бирелешендә авторның эмоцияләрне белдерүче сүзләрне күпләп куллануын күзәтә алабыз.

Менә тагын беркөнне, кичкә таба, тау астындагы ***тын*** *инешкә кинәт* ***аллә ни була****. Ул, авыр эшкә тотынган сыман,* ***уфылдый, көчәнергә керешә.*** *Ул да түгел, кыш буе өстен каплап, тынын буып яткан калын бозны* ***шатыр-шотыр китереп ватып ыргыта да кабарынып, бүртенеп*** **өскә бәреп чыга**. *Килеп чыга да, – күрәсең, яз кояшы аның, башын әйләндерә торгандыр, – ул шундый* ***котырына, тилерә башлый****.* ***Шашынудан*** *кая барып бәреләсен белмичә, башта авыл уртасындагы күпергә, аннары зират янындагы тегермән буасына* ***ташлана****. Берни дә каршы тора алмый* ***котырынган*** *ташуга! Юлында нәрсә очрый, һәммәсен* ***җимереп вата*** *да* ***сыпырып кына алып китә****: карт өянкеләрне* ***сындырып ыргыта****, күпер төбендеге тау-тау тирес, кар, боз өемнәрен* ***кубарып ала****, иске мунчаларны, печән кибәннәрен* ***агызып китә*** [6: 55].

Биредә укучыларга халәтне, хисләрне, эмоцияләрне белдергән сүзләрне табып билгеләргә кушып була. Нәтиҗәдә укучылар, табигать күренешләрен ачык итеп күз алдына китерүгә ирешәләр, табигатьне тасвирлауда авторның осталыгын билгелиләр.

Әсәрдә геройның портретын биргәндә дә эмоция белдергән сүзләр ярдәмгә килә:

Фазулла зур булып ачылган, тирәли зәңгәрләнеп торган ***коточкыч*** *күзләре белән* ***йотардай, суырып алырдай булып*** *кунак кызның алсу битенә, зифа буй-сынына* ***текәлгән дә катып калган****. Аның* ***кансыз*** *иренәре өзлексез кыймылдый, әмма тавыш чыкмый. Хәзер тагын да* ***озынаеп киткән ябык*** *йөзендә* ***гаҗәпләнүме, сокланумы, каушаумы*** *билгесе булып, әллә* ***еламсырау, әллә көлемсерәү*** *шәүләләре уйный иде* [6: 83].

Эмоцияләрне белдерүнең төп сурәтләү чараларына метафора, эпитет, метонимия, синекдоха, чагыштыру, перифраз, ирония, гипербола, литота керә. Әлеге чараларны куллану әдәби текстны матурлый, әсәрнең эмоциональлеген арттыра һәм геройларның төрле эмоциональ халәтләрен тапшырырга ярдәм итә. Мәсәлән, эпитетның эмоцияне белдерүен күзәтәбез:

Көз ахырында аның үзенең бик ***сөйкемле*** *бер вакыты бар* [6: 76].

Андый батыр малайлар безнең очта бармыни соң? Җыен куркак, җыен ***тавык йөрәк****!..* [6: 53] җөмләсендә эмоциональ метафора әдәби текст персонажының эмоциональ халәтен күрсәтә, адресатка йогынты ясый, аның персонажга мөнәсәбәтен формалаштыра.

Эмоцияләрне ачыклауда фигыльләрнең дә роле зур:

Сәке өстендә шуа башлаганнан алып үз көнеңне үзең күрә башлаганчы тормыш сине кырык сират күпереннән кичерә. Әле ***иркәли*** *ул сине, әле* ***яңаклап ташлый****, бер* ***көлдерә****, бер* ***елата****, бер* ***алдын күрсәтә, биш артын күрсәтә*** [6: 46].

Әле уңда, әле сулда бары сабан ашлыгы чәчкәндә генә әйтелә торган үзенә бертөрле ***ат куу, ачулану, орышу, сызгыру*** *тавышлары ишетелеп тора* [6: 73].

Кузгала ***пышылдаулар, чыркылдаулар, китә дәртләнеп нидер көтү, нидер өмет итү, киңәш-табыш итү*** [6: 78].

Синтаксик чаралардан инверсия күренеше эмоцияләрнең көчен чагылдыра ала:

Китә шуннан су ташу! [6: 80].

Әй, бигрәк йөрәксез малай икән бу Гумәр! [6: 53].

Персонажның эмоциональ халәтен текстта график чара ярдәмендә дә чагылдырып була. Мондый чаралардан өндәү билгесен, күпноктаны күрсәтә алабыз:

Әнекәем! Карагыз әле, күрегез әле бу тамашаны! Нишләттең ул итеген, ә?! [6: 53].

– Әй, юеш танау, әй, кыланчык! – Аннары, дилбегәсен тартып, биягә чөңгереп куя [6: 44].

Менә бу эш тәк эш инде! Тырма эзләрен буйдан-буйга ничек кенә тездергән! Бур җебе белән сызганмыни! Җир башын кара син, җир башын! Машина белән чикмән якасы каеган шикелле! Шундый да матур иттергән! [6: 74].

Күренгәнчә, әдәби әсәрләрдә урын алган тойгылы җөмләләр текстка үзенчәлекле төсмер бирәләр һәм хис-кичерешләрне (шатлык, гаҗәпләнү, соклану, ачулану һ. б.) белдерү өчен хезмәт итәләр. Укучылар тойгылы җөмләләренең әдәби әсәрләрне хис-кичерешләр һәм ачык төсләр белән баетуын, вакыйгаларны яхшырак күз алдына китерергә, шулай ук геройларның характерын, аларның эмоциональ халәтен һәм төрле ситуацияләрдәге гамәлләрен аңларга булышуын аңлыйлар.

Түбәндә күрсәтелгән мисалда күпнокта сөйләүченең шикләнүен күрсәтү өчен кулланыла:

– Һм, җылы төшеп җитмәгән шул... – дип суздым. – Бүген үк чәчкәндә тишелә алмыйча сөтләнеп ятмагае, бозылып. Ярый ла җылытып җибәрсә! Чәчми торсаң, соңгарак калуы бар... Бишектәге бала инде. Җылы кирәк, җылы!.. [6: 67].

Художестволы текст белән эшләгәндә, төрле эш төрләрен кулланып, әйтик, тәкъдим ителгән өзек мисалында нинди халәт турында сүз баруын, аларны кайсы тел чаралары ачыклавын; билгеле бер эмоция, хиснең кайсы тел чаралары ярдәмендә бирелүен; өзектә нинди эмоция турында сөйләнүен билгеләтеп, билгеле бер эмоция, хиснең синонимын табарга кушып та эшләтеп була.

Шул рәвешле, мондый сорау-биремнәр укучыларда лингвистик компетенция формалаштыруга, тел күренешләрен һәм фактларын анализлау һәм бәяләү сәләтен формалаштыруга гына түгел, ә бәлки әдәби образны ачуга, персонажларның хис-кичерешләрен һәм фикерләрен тасвирлауга да юнәлдерелгән була. Бу чараларның барысы да авторга әдәби образ тудырырга, ә укучыга әдәби әсәр дөньясына керергә, автор әйтергә теләгән идеяне ачарга ярдәм итә.

Шулай итеп, мәктәптә туган (татар) тел һәм әдәбияты дәресләрендә әдәби әсәрне тикшерү барышында эмоциональ интеллект формалаштыруда әдәби текстта эмоциональ подтекстны чагылдыру (репрезентация) өчен кулланылган тел чараларын өйрәнүгә аерым игътибар бирү мөһим санала.

ӘДӘБИЯТ

1. Герасименко И.Е. Использование оценочной лексики во вторичной номинации. М.: дис. ... канд. филол. наук, 2002. 189 с.

2. Ольшанникова А.Е., Рабинович Л.А. Опыт исследования некоторых индивидуальных характеристик эмоциональности // Вопросы психологии. 2015. № 3. С. 65–74.

3. Стейн С., Бук Г. Преимущества EQ. Эмоциональный интеллект и ваши успехи. М.: Баланс Бизнес Букс, 2017. 384 с

Развитие у студентов вузов речевой культуры рассматривается как целостный образовательный процесс, в рамках которого учащиеся и преподаватели осуществляют совместную деятельность, направленную на формирование у будущих учителей важных профессиональных качеств, навыков, умений и знаний речевой коммуникации. Наличие этих профессиональных компетенций способствует эффективному решению задач, стоящих перед преподавателем в рамках образовательного процесса [3: 112].

Коммуникативная культура важное профессиональное качество педагога. Она формируется в определенной культурной среде, в том числе и языковой, наделенной в определенной степени национально-этническими особенностями. Исходя из вышесказанного, структурными компонентами коммуникации являются наличие коммуникативного идеала, системы коммуникативных норм и правил, индивидуальные особенности учащихся, условия коммуникации (двуязычие, многоязычие) и т. д. Только единство и взаимосвязь всех этих компонентов обеспечивает успешную профессиональную деятельность при обучении студентов.

Составляющие речевой культуры основаны на трех нормах общения: поведенческой, аффективной и когнитивной. Кроме этого также важны коммуникативные и межкультурные нормы межличностного взаимодействия.

Для развития речевых навыков учащихся педагогических направлений особое место отводится к выбору дидактического материала с учетом содержания и темы. В учебном процессе важно правильно использовать новейшие цифровые и педагогические технологии, направленные на развитие у учащихся навыков самостоятельного мышления, их кругозора и интеллектуальной гибкости, что позволяет будущим специалистам принимать ответственные решения в нестандартных ситуациях [1: 36].

Применение дидактических моделей позволяет учащимся вырабатывать умение логически обосновывать свои решения, лингвистически грамотно формулировать свои мысли. На следующем рисунке представлена триада компонентов модели речевой культуры для формирования у ино-

странных студентов, будущих педагогов по профилю «Педагогическое образование: Информатика».

Рис. 1. Модель структуры речевой культуры иностранных студентов, обучающихся по профилю «Педагогическое образование: Информатика»

После анализа программ и учебных планов вузов, осуществляющих подготовку учителей информатики, выявлена логическая взаимосвязь между учебными планами, которая позволяет иностранным студентам, обучающихся по профилю «Педагогическое образование: Информатика», целенаправленно, поэтапно развивать свой профессиональный уровень [5: 192].

Особое внимание привлекли такие учебные предметы, как «Русский язык и деловые коммуникации», «Риторика», «Психология» и «Педагогика», изучение которых позволяет освоить стандарты и нормы современного языка, что является важным аспектом развития у иностранных студентов речевой культуры [4: 47].

Теоретическая модель формирования у иностранных студентов речевой культуры состоит из следующих взаимосвязанных и взаимодополняющих составляющих [2: 181]:

– мотивационную: предполагающую высокий уровень активности и мотивации учащихся к освоению своей будущей профессии;

– содержательную: знания студентов структуры и сущности управления учебно-воспитательным процессом;

– технологическую: которая включает в себя владение современными технологиями, навыками их использования в современном образовательном процессе.

Технологии, ориентированные на развитие языковой компетентности, должны базироваться на принципах коммуникативного обучения, которые реализуются на базе средств компьютерной поддержки. Все компьютеризованные курсы, электронные средства, учебные пособия и их программное обеспечение должны отвечать принципам и требованиям. Вот наиболее важные из них: динамичность, целостность, организованность. К содержанию выдвигаются следующие дидактическими требования: научность,

доступность, систематичность, последовательность, адаптивность, визуализация учебной информации и активация деятельности.

Рис. 2. Теоретическая структурная модель речевой культуры выпускника

Для того, чтобы выявить уровень сформированности у иностранных студентов речевой культуры, были выделены три уровня – низкий, средний и высокий [8: 73]:

– учащиеся с низким уровнем демонстрируют негативное отношение к работе педагога, у них отсутствует мотивация к профессиональному совершенствованию, стремление к изучению инновационных педагогических технологий;

– знания педагогических процессов у студентов, обладающих средним уровнем, имеют бессистемный характер, уровень их мотивации к профессиональному развитию недостаточен;

– будущие преподаватели с высоким уровнем сформированности речевой культуры, проявляют креативный подход к учебному процессу, имеют прочные знания и навыки, на которые опираются в своей практической деятельности, хорошо мотивированы к профессиональному совершенствованию.

В рамках экспериментального исследования было определено исходное состояние рассматриваемой проблематики и итоговое. Для того, чтобы определить уровень развития речевых навыков у иностранных студентов, обучающихся по профилю «Педагогическое образование: Информатики», были проведены различные тестирования, количественный и качественный анализ итогов экспериментального исследования, метод анкетирования, собеседования, рассмотрение педагогических ситуаций, наблюдения, а также математическая и статистическая обработка данных, полученных в ходе исследования.

В ходе исследования было выявлено, что в большинство студентов продемонстрировали бессистемные знания, а их представление о будущей деятельности было неполным. Их действия в ходе педагогической практи-

ки были, как правило, импульсивными и шаблонными. Нам представляется очевидным, что наибольшим уровнем сформированности речевых компетенций обладают те учащиеся, которыми движет призвание к выбранной профессии, которой они обучаются в вузе, а не иные факторы. Поскольку другие студенты в своем большинстве демонстрируют уровни средней и низкий.

Эффективность образовательного процесса обусловлена умелым применением интерактивных технологий, которые, в свою очередь, позволяют активизировать процесс обучения, стимулируя стремление студентов к самообразованию и самосовершенствованию, позволяют выявить их наиболее сильные стороны [7: 224].

В процессе реализации исследования были апробированы и внедрены в практику интерактивные технологии, способствующие формированию у иностранных студентов таких навыков и умений речевой культуры, как участие в дискуссиях, работа с текстами, участие в мозговых штурмах, написание мини-сочинений, наблюдениях, беседах, деловых и ролевых играх, практически занятиях по решению проблемных ситуаций и т. д. Взаимосвязь познавательной, практической и игровой деятельности благотворно влияет на активность, интерес, самостоятельности учащихся, что стимулирует их творческому воображению и изобретательности.

Активное использование дебатов, деловых игр, мозговых штурмов, исследовательских и поисковых методов, а также методики проектного обучения, привели к позитивным результатам.

В ходе ролевых игр студенты играли различные роли, например, роль экскурсовода, который знакомит гостей города с его достопримечательностями. При этом другие учащиеся, выполняющие роль гостей, следят, насколько хорошо «экскурсовод» знает правила грамматики, выстраивает предложения, каково его произношение (см. рис. 3).

Следует отметить и трудности, с которыми сталкиваются многие учащиеся при участии в дискуссиях. Причинами проблем при попытках свободного общения являются опасение сделать ошибки, страх выступления перед публикой, психологический барьер. Грамотная организация преподавателем совместной работы в ходе проведения учебных дискуссий, умение с его стороны обеспечить благоприятный психологический климат в аудитории позволяют успешно преодолеть психологический барьер и достичь серьезных успехов в формировании у учащихся коммуникативных навыков.

В ходе исследовательской работы были разработаны и апробированы тестовые задания, направленные на определение уровня сформированности речевой культуры у учащихся вузов. Доказано, что большинство учащихся успешно выполнили все предложенные задания. В ходе выполнения задания, которое предполагало публичное выступление студента, где он должен был продемонстрировать свое умение свободно и корректно излагать определенный материал, с существенными трудностями столкнулись меньше половины учащихся.

После использования специальных заданий по развитию коммуникативных навыков учащихся, выяснилась динамика развития речевой культуры и повышение уровня сформированности всех составляющих речевой

культуры; освоение и развитие навыков публичных выступлений иностранными студентами [6: 40].



Рис. 3. Интерактивные формы образовательного процесса

Дальнейшая разработка рассматриваемой проблемы должна осуществляться по нескольким направлениям:

– моделирование процессов формирования и развития у иностранных студентов речевой культуры в рамках профессионального обучения в высшем учебном заведении;

– организация дополнительных курсов по совершенствованию отдельных аспектов речевой культуры учащихся;

– широкое внедрение в образовательный процесс интерактивных технологий, позволяющих интенсифицировать развитие речевой культуры.

Представленное исследование является попыткой по развитию коммуникативных навыков иностранных студентов, и не в состоянии решить всей проблемы формирования у иностранных студентов, связанные с развитием у них речевой культуры. Поэтому коммуникативная компетентность иностранных студентов, выпускников педагогических направлений, открывает перспективы дальнейших научно-исследовательской деятельности.

ЛИТЕРАТУРА

1. Гирич З.И. О методике формирования коммуникативной компетенции иностранных тюркоязычных студентов инженерного профиля в процессе обучения русскому языку // Вестник Тульского государственного университета. Серия: Совре-

менные образовательные технологии в преподавании естественнонаучных дисциплин. 2019. № 1 (18). С. 31–39.

2. Егоров К.Б., Захарова В.А. Стратегии обеспечения качества обучения русскому языку и культуре иностранных студентов // Язык и культура. 2020. № 52. С. 170–187.

3. Завадская А.В., Исаева О.В., Слонь О.В., Юдина Т.А. Приобщение иностранных студентов к русской культуре в процессе изучения русского языка // Успехи гуманитарных наук. 2019. № 4. С. 110–114.

4. Коровина П.К. Выявление речевых сложностей в процессе изучения русского языка у иностранных студентов в ДВФУ // Colloquium-Journal. 2019. № 15-7(39). С. 44–49.

5. Кузнецова А.А., Скаковский В.Ю., Ткачева Р.А. Формирование языковых возможностей студентов в процессе обучения русскому языку как иностранному // Вестник Тверского государственного университета. Серия: Филология. 2022. № 1 (72). С. 184–195.

6. Самитова С.Г. Формирование профессиональной речевой культуры у иностранных студентов в процессе обучения русскому языку (на примере тюркоязычной группы) // Казанская наука. 2021. Т. 3. № 2. С. 39–42.

7. Ульянова Э.Ф., Миролюбова Н.А. Использование адаптивной технологии обучения иностранных студентов русскому языку и культуре речи в технологическом вузе // Перспективы науки. 2022. № 4 (151). С. 222–227.

8. Чуксина И.Г., Ковалишин П.Ю. Профессионально ориентированное обучение иностранных студентов русскому языку в техническом вузе // Известия Балтийской государственной академии рыбопромыслового флота: психолого-педагогические науки. 2019. № 3 (49). С. 70–78.

УДК 811.512.145

Саттарова Мәдинә Рәшид кызы
Казан (Идел буе) федераль университеты
Казан, Россия
Саттарова Мадина Рашидовна
Казанский (Приволжский) федеральный университет
Казань, Россия
Sattarova Madina Rashidovna
Kazan (Volga Region) Federal University
Kazan, Russia
E-mail: m-sattarova@mail.ru
Болгарова Рәмзия Марс кызы
Казан (Идел буе) федераль университеты
Казан, Россия
Болгарова Рамзия Марсовна
Казанский (Приволжский) федеральный университет
Казань, Россия
Bolgarova Ramziya Marsovna
Kazan (Volga Region) Federal University
Kazan, Russia
E-mail: ramzija5@yandex.ru
Болгарова Алинә Руслан кызы
Казан (Идел буе) федераль университеты
Казань, Россия
Болгарова Алина Руслановна
Казанский (Приволжский) федеральный университет
Казань, Россия
Bolgarova Alina Ruslanovna
Kazan (Volga Region) Federal University
Kazan, Russia
E-mail: alinabolgarova@mail.ru

ТАТАР ТЕЛЕНДӘ ТАБИГАТЬ КҮРЕНЕШЛӘРЕ АТАМАЛАРЫ
НАЗВАНИЯ ПРИРОДНЫХ ЯВЛЕНИЙ НА ТАТАРСКОМ ЯЗЫКЕ
NAMES OF NATURAL PHENOMENA IN THE TATAR LANGUAGE

Аннотация. *В современном тюркском языкознании, в частности в татарском, особое внимание уделяется изучению семантических и тематических групп лексики, связанных с различными аспектами материальной и духовной культуры народа. Некоторые тематические и лексико-семантические группы до сих пор остаются малоизученными. Одна из таких групп связана с народными представлениями о климате и особенностях погоды. Данная статья посвящена описанию названий природных явлений на материале татарского языка.*

Annotation. *In modern Turkic linguistics, particularly in Tatar, special attention is paid to the study of semantic and thematic groups of vocabulary related to various aspects of the material and spiritual culture of the people. Some thematic and lexico-semantic groups are still poorly understood. One of these groups is associated with popular beliefs about climate and weather patterns. This article is devoted to the description of the names of natural phenomena based on the material of the Tatar language.*

Ключевые слова: *татарский язык, названия природных явлений, метеорологическая лексика татарского языка*

Keywords: *Tatar language, names of natural phenomena, meteorological vocabulary of the Tatar language*

Дөнья халыклары, шул исәптән татарлар да, элек электән үзе яшәгән тирәлекне күзәткән, табигать күренешләрен өйрәнгән. Әлеге күзәтүләргә бәйле төрле ышанулар, гореф-гадәтләр, сынамышлар формалашкан. Шул рәвешле, табигать күренешләре халыкның көндәлек тормышы, дөньяга карашына бәйле тотрыклы бер система барлыкка китергән. Кеше үзен табигатьнең аерылгысыз бер өлеше итеп таныган. География урнашуга бәйле төрле ел фасыллары бер-берсеннән шактый аерылу, шуларга бәйле табигать күренешләренең күптөрлелеге аларны билгеләү өчен күпсанлы атамалар барлыкка китергән.

Татар теленең сүзлек составы бик бай һәм киңкырлы. Арада табигать күренешләрен белдерә торган берәмлекләр зур бер төркемне тәшкил итә. Әлеге мәкаләдә хәзерге татар телендә кулланылышта булган табигать күренешләрен белдерә торган берәмлекләргә тематик классификация тәкъдим итү максаты куелды. Тасвирлана торган материалның лингвистик, этнографик, тел тарихы һ. б. өлкәләр күзлегеннән кыйммәте зур булу хезмәтнең актуальлеген раслый.

Рус тел белемендә метеонимнар шактый өйрәнелгән. Т.В. Горячева [1], В.М. Касьянова [5], М.А. Лазарева [6], М.О. Сорокина [9], И.Н. Суспицина [10], А.А. Чемерчева [19], Л.Е. Щербакова [21] һ. б. хезмәтләре шуны раслый. Төрки тел белемендә дә табигать күренешләрен белдергән сүзләргә берникадәр игътибар бир. Мәсәлән, Л.В. Данилова [2], В.Б. Джафаров [3], А.Г. Искәндәров [4], Л.С. Левитская [7], Ю.В. Норманская [8], М.З. Улаков [17], Д.Д. Хәйруллина [18], А.Г. Шәйхулов [20], А.Д. Эсенмадова [22] һ. б. авторлыгында дөнья күргән басмаларда аерым мәгълүматлар бар. Әлеге хезмәтләр татар телендә кулланылышта булган табигать күренешләре атамаларын өйрәнү өчен фәнни-методологик нигез булдыра.

Татар телендә кулланылышта булган бу төркем сүзләрне өйрәнүне әдәби тел мисалында башлау урынлы булыр. Әлеге мәкалә кысаларында тупланган ике йөздән артык берәмлекне тематик классификацияләү максаты куелды. Перспективада бу эзләнүләр татар теле сөйләшләрендә кулланыла торган берәмлекләр белән тулыландырылачак, шул рәвеште хәзерге татар телендә кулланылышта булган табигать күренешләре атамаларының тулы исемлеге төзеләчәк. Теоретик һәм гамәли яктан татар теленең сүзлек байлыгын өйрәнүдә кулланылырга мөмкин булган чыганак булдыру күз алдында тотыла.

Алда билгеләнгән галимнәрнең хезмәтләрендә табигать күренешләре атамаларын метеорологик лексика, метеонимнар дип билгеләү теркәлгән. Тематик яктан төркемләүгә килгәндә, фикер төрлелеге күренә. Бу табигый дип уйлыйбыз, чөнки авторларны максатлары төрле. Нигездә явым-төшем, һава шартлары белән бәйле күренешләр, җил игътибар үзәгендә. Моннан тыш яктылык, электр, температура белән бәйлеләре дә очрый. Климатик шартлар төрлелеге дә тематиканың үзенчәлеген билгели. Л.С. Левитская

«Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков» хезмәтенең «Метеорология» бүлегендә төрки телләрдәге табигать күренешләре белән бәйле атамаларны 3 төркемгә берләштерә: атмосфера күренешләре, явым-төшемнәр, җил [7: 13].

Татар теленең аңлатмалы сүзлегеннән файдаланып тупланган берәмлекләрнең эчтәлеген өйрәнеп, түбәндәге бүленешне тәкъдим итәбез. Сүзлекләр әдәбият исемлегендә күрсәтелде [11–16]. Мөстәкыйль берәмлекләрнең кулланылыш вариантлары төшенчәнең ни дәрәҗәдә киң таралуын, эчтәлеге бай булуын күрсәткәнгә, теркәлгән берәмлекләрне дә санау урынлы булыр.

1. Явым-төшем атамалары:

Яңгыр*: койма яңгыр, көчле яңгыр, күкрәүле яңгыр, ләйсән яңгыр, пыскак яңгыр, спас яңгыры, яңгыр тамгалау, тамчылау, сибәләү, эре тамчылы яңгыр, тынмастан яңгыр, шифалы яңгыр, чиләкләп яңгыр кою, яшенле яңгыр, яңгырлы һава, өермәле яңгыр, явым, явым-төшем, карлы-бозлы яңгыр, рашкылы яңгыр* һ. б.

Кар*: карлы-буранлы (көн), рашкы, ярма кар, кар бураны, кар бөртеге, кар капламы, кар суы, кар тавы, кар өеме, карт көрте, беренче кар, күбәләк кар, ябалак кар, кар давылы, епшек кар, кырпак кар, өрпәк кар, очкак кар, чапырдап торган кар, шыгырдавык кар* һ. б.

Боз: *боз китү, боз кузгалу, боз яву, боз сугу, бозлавык, тайгак, тайгалак* һ. б.

Бәс: *бәс төшү, бәс сару, кырау, кырау төшү, кырау сугу, сыкы* һ. б.

Чык: *чык тамчысы, чык төшү, чык суы, чык тамчысы, чыклы үлән* һ. б.

2. Болыт төшенчәсе белән бәйле берәмлекләр: *болыт басу, болытлар куеру, болытлар калынаю, каурыйсыман болытлар, кысыр болыт, болытлар агылу, аязучан болытлы* һ. б.

3. Томан төшенчәсе белән бәйле берәмлекләр: *томан каплау, томан күтәрелү, томалану, томан катлавы, томан төшү, төтенсу томан, томанлы көн, коры томан* һ. б.

4. Оптик күренешләр белдерә торган сүзләр: с*алават күпере, мираж, рәшә, чагым (искергән сүз), поляр балкыш, төньяк балкышы, котып балкышы* һ. б.

5. Электр белән бәйле күренеш атамалары: *аҗаган, елдырым, арыш камчылау, күк күкрәү, күкрәвек, яшен, яшен шары* һ. б.

6. Җил, һава агымы белән бәйле сүзләр: *буран, кар бураны, буран күтәрелү, буран чыгу, кар давылы, җәяүле буран, ыжгыр буран, җилле буран, карлы-буранлы, күз ачкысыз буран, ком бураны, җил, арттан искән җил, җил сызгыру, пәри туе, үзән җиле, дала җиле, гарасат, давыл, җил-давыл, өермә, җил-давыл кубу, давыл җиле, шторм, шторм сигналы, коры җил, тын куыргыч җил* һ. б.

7. Табигатьтә су әйләнеше белән бәйле төшенчәләр: *боз китү, боз агу, боз кузгалу, язгы ташу, корылык, кытлык, яңгырсызлык, яңгырсыз ел, елга юлы, елга үзәге, елга үзәне* һ. б.

8. Җир катламында бара торган күренешләр белән бәйле төшенчәләр: *җир тетрәү, зилзилә, җир кыймылдау (искергән сүз), вулкан, янартау, утлы тау, ут тавы, янар тау авызы, вулкан кратеры, ләмле вулкан.*

9. Астрономик күренеш атамалары:

Көн: *көн аралаш, көн ачылу, баш көн, буш көн, атнакөн, кояшлы көн* h. б.

Төн: *кара төн, төн уртасы, җиде төн уртасы* h. б.

Иртә: *хәерле иртә, иртә-кич, таң, таң ату, иртән-иртүк, таңгы, яктыру* h. б.

Кич*: кичтән, кичкырын* h. б.

Яз: *иртә яз, яз башы* h. б.

Җәй*: кышын-җәен, җәй җитү, җәен, җәйгелектә, карчыклар атнасы, әбиләр чуагы* h. б.

Көз: *көз җитү* h. б.

Кыш: *кыш көне, кышкы салкын* h. б.

Кояш: *кояш тотылу, язгы кояш баешы, кояш баю, кояш чыгу, кояш нурлары, кояш җылысы, кояш кыздыру* h. б.

Ай: *ай яктысы, ай туу, яңа ай, ай тулысы, тулган ай, ай тотылу, ай яктысы, ай нуры* h. б.

Йолдыз: *Зөһрә йолдыз, Таң йолдызы, Чулпан йолдыз, Тимер казык йолдыз, Җидегән йолдыз, Чүмеч йолдыз, йолдыз атылу, йолдыз җемелдәү* h. б.

Күк: *күк йөзе, җир белән күк арасы, күк гөмбәзе, күк капусы* h. б.

10. Табигать җанлану белән бәйле атамалар: *чәчәк ату, яфрак яру, яфрак коелу, уылдык чәчү* h. б.

11. Метеорология системасы белән бәйле гомуми атмалар: *антициклон, атмосфера, атмосфера басымы, һава, саф һава, дымлы һава, һава басымы, климат, комета, койрыклы йолдыз, космос, галәм, фәза (искергән сүз), ландшафт, күренеш, манзара, һава торышы, ачалак-йомалак, һава ачылу, аязу, аяз, көн суыту, көн җилләп тору, табигать, җанлы табигать, тере табигать, тере булмаган табигать, янгын, янгын сүндерү, озон, сезон* h. б.

12. Температура үзгәрү белән бәйле күренеш атамалары: *тынчу, бөркү, эссе, кызу, салкын, җәйге челлә, көн кызуы, корылык, кытлык, боз сөңгесе, суык, салкын, кырау, иртәнге салкын, кичке салкын, зыкы, үзәк өзгеч салкын, чатлама салкын, зәмһәрир, кышкы челлә, раштуа суыклары, коры суык, пар, пар күтәрелү, тузан, тузан тузу, тузан бөртеге, епшек, җепшек* h. б.

Тәкъдим ителә торган бүленешне татар сөйләшләрендә кулланыла торган берәмлекләр хисабына тулыландыру мөһим. Анализланган кадәр лексик берәмлекләр бу семантик катламның әһәмиятле булуын раслый. Бу берәмлекләрнең җанлы телдә кулланылышы, халык авыз иҗатында теркәлгән мәгънә мөмкинлекләрен өйрәнү тагын да эчтәлекле нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек тудырачак. Тематик бүленеш тә метеонимнар гына түгел, су әйләнеше, җир картламы хәрәкәте, температура һәм һава үзгәрү белән бәйле, астрономик һәм башка мәгънәләрне үз эченә алып төзелгән очракта тулырак булыр. Нәтиҗә ясап әйткәндә, татар телендә табигать күренешләре белән бәйле мәгънәдә кулланыла торган сүзләрнең активлыгын, ясалышын, килеп чыгышын өйрәнү юллары ачыла, татар теленең кардәш һәм кардәш булмаган башка телләр арасында тоткан урынын билгеләргә ярдәм итәчәк.

ӘДӘБИЯТ

1. Горячева Т.В. Заметки по этимологии русской народной метеорологической терминологии // Этимология–1977. М.: Наука, 1979. С. 102–109.

2. Данилова Л.В. Метеорологическая лексика тюркских языков: сравнительно-историческое освещение: дис. ... канд. филол. наук. Ташкент, 1972. 209 с.

3. Джафаров В.Б. Метеорологические термины в азербайджанском языке: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Баку, 1990. 24 с.

4. Искандаров А.Г. Метеорологическая лексика башкирского языка. автореф. дис. ... канд. филол. наук. Уфа, 2009. 25 с.

5. Касьянова В.М. Русская метеорологическая лексика (история и функционирование): дис. … канд. филол. наук. Москва, 1984. 258 с.

6. Лазарева М.А. Сопоставительный анализ метеорологической лексики английского и русского языков: дис. … канд. филол. наук. М., 2000. 200 с.

7. Левитская Л.С. Метеорология // Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Лексика. М., 2001. С. 13–49.

8. Норманская Ю.В. Реконструкция пратюркской системы названий метеорологических явлений и ее анализ с точки зрения диахронической лексической типологии // Природное окружение и материальная культура пратюркских народов. М.: Восточная литература, 2008. С. 68–101.

9. Сорокина М.О. Лингвокультурологическое исследование поля «погода» в русских говорах Алтая: Моделирование фрагмента региональной языковой картины мира: дис. ... канд. филол. наук. Барнаул, 2004. 178 с.

10. Суспицина И.Н. Метеорологическая лексика в говорах Русского Севера: дис. ... канд. филол. наук. Екатеринбург, 2000. 188 с.

11. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / ред.: Ф.Ф. Гаффарова, Г.Г. Саберова, Ф.И. Таһирова. Казан: ТӘһСИ, 2015. Т. 1: А–В. 712 с.;

12. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / ред.: Ф.Ф. Гаффарова, Г.Г. Саберова, Ф.И. Таһирова. Казан: ТӘһСИ, 2015. Т. 2: Г–Й. 748 с.

13. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / ред.: Ф.Ф. Гаффарова, Ф.И. Таһирова, Р.Т. Сәфәров. Казан: ТӘһСИ, 2017. Т. 3: К. 744 с.

14. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: Т. 4: Л–Р. Казан: ТӘһСИ, 2018. 760 б.

15. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: Т. 5: С–Т. Казан: ТӘһСИ, 2019. 908 б.

16. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: Т. 6: У–Я. Казан: ТӘһСИ, 2021. 912 б.

17. Улаков М.З., Махиева Л.Х., Локьяева Ж.М. Метеорологическая лексика (на материале словарей карачаево-балкарского языка). Известия Кабардино-Балкарского научного центра РАН № 4 (102) 2021. Режим доступа: https://elibrary.ru/download/elibrary_46551835_80823037.pdf (дата обращения: 26.08.2025)

18. Хайруллина Д.Д., Гилязева Э.Н., Базарова Л.В. Особенности номинации природного явления «дождь» в английском и татарском языках // Филологические науки. Вопросы теории и практики. 2021. Т. 14. Вып. 3. С. 918–922.

19. Чемерчева А.А. Народная метеорология: поверья, обряды и терминология: этнолингвистический аспект: дис. ... канд. филол. наук. Тамбов, 2006. 206 с.

20. Шайхулов А.Г. Некоторые вопросы системного исследования апеллятивных и топонимических единиц (на материале языков Урало-Поволжья) // Методы топонимических исследований: сб. науч. тр. Свердловск: Изд-во УрГУ, 1983. С. 35-41.

21. Щербакова Л.Е. Формирование русокой метеорологической лексики: наименования осадков, наименования состояний погоды: дис. … канд. филол. наук. Саратов, 1983. 154 с.

22. Эсенмадова А.Д. Лексико-семантические особенности метеорологической лексики туркменского языка // Психология, социология и педагогика. 2023. № 1 [Электронный ресурс]. Режим доступа: https://psychology.snauka.ru/2023/01/8749 (дата обращения: 26.08.2025)

УДК 811. 512. 145

Сафина Эльвира Ирфат кызы
ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
Казан, Россия
Сафина Эльвира Ирфатовна
Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
Казань, Россия
Safina Elvira Irfatovna
G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art
of the Tatarstan Academy of Sciences
E-mail: 7idillia@mail.ru

ТАТАР ХАЛЫК ҖЫРЛАРЫНДА САНДУГАЧ ҺӘМ БЫЛБЫЛ ОБРАЗЛАРЫ

ОБРАЗЫ СОЛОВЬЯ В ТАТАРСКИХ НАРОДНЫХ ПЕСНЯХ

IMAGES OF A NIGHTINGALE IN TATAR FOLK SONGS

Аннотация. *В статье рассматривается символика образа соловья в татарских народных песнях. Устанавливается, что соловей является центральным символом, выражающим целый спектр чувств: от любви и красоты до глубокой печали, тоски по родному дому, разлуки с любимым и сложной палитры лирических переживаний. Делается вывод о глубокой эмоциональной связи между народной культурой и природным миром, где соловей выступает в роли лирического собеседника и тонкого посредника, связывающего мир человеческой души с миром природы.*

Annotation. *This article provides a comprehensive analysis of the symbolism associated with the nightingale in Tatar folk song tradition. Employing structural-semantic and comparative methodologies, the study demonstrates that the ornithonym "nightingale" operates as a pivotal artistic code structuring a multilayered system of lyrical meanings, ranging from themes of love, beauty, and harmony to those of sorrow, longing, and separation. As a key mediator between the individual's inner world and the natural environment, the nightingale integrates both personal and collective emotional experiences, reflecting distinctive aspects of the national mentality. The findings underscore the profound interrelation between the emotional sphere of Tatar folk culture and the natural landscape, as well as the importance of zoomorphic symbolism in shaping the semantic field of folk song.*

Ключевые слова: *орнитоним, образы птиц, соловей, символика, татарская народная песня*

Keywords: *ornithonym, symbolism, nightingale image, Tatar folk song, folklore, emotional structure*

Халык лирикасында орнитологик образлар күплеге һәм төрлелеге белән аерылып тора. Бу кошларның татар халкының материаль һәм рухи тормышында зур роль уйнавы белән аңлатыла.

Поэзиядә һәм җыр сәнгатендә аеруча еш очрый торган орнитонимнар – сандугач һәм былбыл. Алар бүгенге көн җырларында да күп һәм һәр кешегә таныш. Сандугач белән былбыл образларының татар җырларында элек-электән үк актив кулланылуын күрсәтү максатыннан, анализ өчен махсус борынгырак җырлар алынды. 1965 елгы «Татар халык җырлары»

[13] җыентыгындагы әлеге орнитонимнар кергән 50 дән артык җыр тикшерелде.

Халык җырларының поэтик символикасы галимнәр тарафыннан XIX йөздә үк өйрәнелә башлый [5: 19]. Орнитонимнарга бәйле образларга В.И. Абрамова, Д.В. Павлов, А.В. Кузьмина, Т.М. Малыхина, Н.Н. Глухова, А.М. Хәкимьянова, Р.Т. Моратова хезмәтләрендә зур урын бирелә.

Еш һәм күп очраганга, бай образлар хасил иткәнгә күрә, кошлар символикасы гадәттә җырларны тикшерү-анализлауга багышланган хезмәтләрдә дә карала. Мисал өчен, К.М. Миңнуллинның җырларны өйрәнүгә багышланган хезмәтендә [8], Л.Ф. Җамалиеваның татар, башкорт, чуваш халык җырлары турындагы диссертациясендә [4] башка күптөрле образлар белән беррәттән, кошлар белән бәйлеләре дә анализлана. Пермь татарларының музыкаль культурасын фәнни яктан анализлауга багышланган монографиядә шулай ук җырларда орнитологик образларның күп булуы ассызыклана [2].

Сандугач – бик күп телләрдә кулланыла торган гомумтөрки орнитоним [9: 42].

Сандугач атамасы булган җыр юлларында кошлар төрле яктан тасвирлана: аларның символик мәгънәләре генә түгел, ә физик билгеләре, яшәү-тору урыннары, сайраулары да телгә алына. Мисал өчен, игътибарны җәлеп итә торган тышкы билгеләреннән сандугачларның төсе әйтеп үтелә (Кара карлыгач микән, / Сары сандугач микән / Аны үстергән әнкәсе; Таң алдыннан тал тибрәтеп / Сайрый сары сандугач; Сарылы күлмәк, сандугачым, / Саргайдым сине уйлап).

Сандугачның кайчан сайравы (ел фасылы, тәүлек вакыты) күрсәтелә. Мисал өчен, *язын* (Сандугач / Өзелеп-өзелеп сайрыйдыр, / Яз булгач); *таң атканда* (Сандугачлар сайрый, әй, садларда, / Сызылып кына таңнар атканда); *таң алдыннан* (Таң алдыннан тал тибрәтеп / Сайрый сары сандугач; Талдан талга кунып сайрый микән / Таң алдыннан сары ла сандугач?); *төнлә* (Асыл да сандугачлар кайда сайрый? / Тулган айның каршында) һ. б.

Кайда сайравы турында мәгълүмат тагын да күбрәк. Болар: *тугайда* (Сандугач моңая, әй, тугайда, / Мин моңаям нигә бу айда?); *аланда* (Сандугачлар сайрап, ай, очадыр / Аланда); *су буенда* (Сандугачлар сайрый су буенда; *чишмә янында* (Түгәрәккәй чишмә суы тулган, / Аның ягасына кош кунган); *урманда* (Сандугач сайрар яшел урманда, / Без дә сайрашыйк, әйдә, җанашым); *әрәмәдә* (Әрәмәкәйләрдә лә, талларда); *бакчада* (Сандугач сайрый бакчада, / Гөл бакчасы сәйран дип) һ. б. Бакча сүзенең рус телендәге варианты да очрый (Сандугачлар сайрый, әй, садларда). Татар халык җырларында сандугачлар хәтта мәчет башында сайрый (Мәчетләр дә башы кыйгач-кыйгач, / Кыйгачлары саен сандугач).

Фитонимнар белән бергә куллану сандугачның нинди агачка кунып сайравына ачыклык кертә. Мисал өчен, *алмагач* (Асыл да сандугачлар кайда сайрый? / Баллы алмагач башында); *каен* (Сандугачлар сайрый, әй, каршымда, / Нечкә генә башлы каенда); *миләш* (Сандугачлар ияләшкән / Су эчәргә миләштән); *карама* (Сандугачлар оя кайда ясый – / Яшел карамага – куышка); *муел* (Агыйделкәйләрнең, ай, буенда, / Сандугачлар сайрый муелда); *зәйтүн агачы* (Сандугач белән былбылны / Зәйтүн агачына

ла кундыр син); *тирәк* (Сандугачлар сайрый, ай, тирәктә); *тал* (Сандугачым, әйт үземә, / Кайсы талга кунасың?; Сандугачларның, ай, баласы, / Куныр сайрамага тал тапмый; Сандугачлар оча тал эзләп); *тал тирәк* (Җәй аенда матур аяз көндә, / Сандугачлар сайрый-сайрый / Тал тирәккә кунганда шул). Агачлардан тыш, сандугач *гөлләргә* басып сайрый (Сандугачлар басып сайрап / Сындырган гөлләремне; Сандугач очар гөл күреп, / Асыл кошлар очар күл күреп; Бакчадагы гөлләремә / Сандугачлар ияләшми).

Сандугачларның күбрәк тал һәм тирәккә кунуларына игътибар иткәннәр булса кирәк, агач исемнәре арасында алар иң еш кулланыла. Бу фитонимнар аерым-аерым да, бергә дә очрый (Безнең каршыбызда тал да тирәк, / Сандугачка сайрарга шул кирәк). *Тал тирәк* дигән вариант та күп (Сандугачлар сайрый-сайрый / Тал тирәккә кунганда). Бүгенге көндә әлеге агач исемнәре я кушылып, я сызыкча аша языла. К.: Тал-тирәк *җый. и.* Талсыман агачлар, төрле тал агачлары [11: 343]; Талларның һәртөрле төре күп үскән җир [12: 339]. Талтирәк – талчалар семьялыгыннан сулыклар буенда үсә торган очлаебрак торган яфраклы талга охшаш биек агач; русчасы: ветла [Шунда ук]. Халык җырларындагы *тал тирәк* бүгенге көн сүзлекләрендәге *талтирәк* тә, җыйма *тал-тирәк* тә булырга мөмкин.

Кошларның кайда сайраулары турында сүз барганда, җырларда Татарстандагы һәм татарлар яшәгән өлкәләрдәге елга исемнәре телгә алына. Татар халкы җырга салган сандугачлар *Зәй буенда* (Зәй буенда үскән тал тирәккә / Сандугачлар тәхтен корырмы?); *Агыйдел буенда* (Агыйделкәй буе тугай-тугай, / Сайрап тора сандугач-тургай); *Сакмар буенда* (Сакмар да гынай суы буйларында / Сандугачлар тавышын тыңладым) сайрый.

Сандугачларның ничек сайравы түбәндәге юлларда күренә: Сандугач чут-чут итеп сайрыйдыр, / Яз булгач; Таң алдыннан чут-чут килә / Сандугачлар тавышы. Орнитоним *сайрау* сүзе белән еш очрый. *Сайрар* сүзе белән кулланыла (Яшь акылым белән сизми калдым, / Сайрар сандугачым шул булган).

Күзгә күренеп торган үзенчәлекле билгеләреннән образлылыкка күчкәндә, сандугач образының беренче чиратта хис-тойгылар, кичерешләр белән бәйле булуы күзгә ташлана. Шуларның иң көчлесе – тирән сагыш хисе.

Сандугач образының сагыну, юксыну, сагыш белән бәйлеләрен ике төркемгә бүлеп карарга була. Беренчесе – туган якны, икенчесе – сөйгән ярны сагынып сагышлану.

Туган як, туган ил, туып үскән җиргә бәйле рәвештә сандугач сайраулары аеруча еш телгә алына. Сандугач я туган якта сайрый, я аның сайраулары туган якны искә төшерә, я туган җирен сагынучы лирик герой сандугач белән серләшә, аңа сагыну-сагышлары турында сөйли (Сайрамачы, сандугачым, син сайрасаң, / Күңелләрем тулып җилкенә; Искә төшә сөйгән газиз ярлар, / Искә төшә туган ил генә). Шуңа бәйле рәвештә, билгеле инде, сандугачның сайравы үтә дә моңлы булып ишетелә (Сандугачның сайравы / Ник болай моңлы икән? Моңлы бала түгел идем, / Миңа ниләр булды икән?). Сөйгән ярын сагынуга түзә алмаган лирик герой өчен дә сандугачларның тавышы бик моңлы булып тоела (Сандугачлар тавышы моңлы икән, / Сөйгәнеңне өзелеп сагынгач).

Сагышлы җырларда сандугач образы түбәндәге хисләрне белдерә: *сагыну* (Сагынсам да, җаныем, нихәл итим, / Барып та гына күрер җир түгел. / Сандугач, / Бик ямансу була икән Сагынгач; Сандугачлар сайрар, әй, җир түгел, / Сайрар урыннары ла киң түгел. / Сагынмаслык түгел, саргаерлык, / Йөгереп җитә торган җир түгел); *күңел тулу, күңел җилкенү* (Син сайрасаң, / Күңелләрем тулып җилкенә); *саргаю* (Сандугач кебек сайрый-сайрый, / Саргайдым йөргән җиремдә; Сарылы күлмәк, сандугачым, / Саргайдым сине уйлап).

Сагыну-сагыш, юксыну хисләре тулы шигырь юлларында лирик геройның авыр халәте *елау, җырлау, моңаю, сайрау* фигыльләре аша белдерелә (Сандугачлар тавышын тыңладым да / Өзелеп-өзелеп җырлар җырладым; Сайра, сайра син, сандугач, / Моңлы тавышың берләп, / Мин дә җырыңа кушылыйм / Кайгы-сагышым берләп; Җырлау түгел җыларсың да, / Өзелеп-өзелеп сагынгач; Сандугачлар идем бит илемдә, / Кайтсам сайрар идем җиремдә; Сары сандугач, сайрый сандугач, / Егъладым сагынгач; Сандугач моңая, әй, тугайда, / Мин моңаям нигә бу айда?; Үткән гомерләрем кайтыр микән, / Сандугачлар булып сайрасам?).

Шул ук вакытта, сандугач сайравын тыңлап, халык моңаеп кына калмый, киресенчә, *сагышын тарата* (Сайра, сайра син, сандугач, / Тыңлыйм матур тавышың, / Сине тыңлап таратырмын / Эчемдәге сагышым); *хушлана, йөрәгенә ял ала* (Сайра, сайра син, сандугач, / Басып тал-тирәгеңә, / Сайравыңнан хушланам да / Алам ял йөрәгемә). Әлеге җыр юлларында сандугачның сайравы якты хисләр уятса да, алар артында авыр хискичерешләр, тойгылар ята. Биредә алар кешеләрнең шул халәтен онытты рып торырга ярдәм итә торган позитив эмоцияләр буларак кабул ителә. Ә тулаем позитив, уңай төсмерле бер генә мисал очрады: сандугач сайравыннан *җир ямьләнә* (Сайра, сайра син, сандугач, / Сайра, юат, күңелең ач, / Сайравыңнан җир ямьләнсен, / Чәчәк атсын алмагач).

Сандугач сайравы гадәттә кешеләрне тәэсирләндерсә, бер җырда, киресенчә, сандугачларның кешеләр җырлавын тыңлавы турында әйтелә: Агыйделкәй буйлап, әй, сал ага, / Сал өстендә кемнәр, әй, моңлана? / Без җырласак салда курай тартып, / Сандугачлар туктап, әй, тыңлана.

«Сандугачым» дип мөрәҗәгать итеп, лирик герой сандугач белән сөйләшә (Сөйгәнем исемен яздырдым, сандугачым, / Кулымдагы йөзеккә, карлыгачым. / Гыйшык диңгезе бик тирән, сандугачым, / Чыгып булмый йөзеп тә, карлыгачым; Суда тау-таш кыялары, сандугачым, / Былбыл кош оялары, карлыгачым, / Ике гашыйк бергә килсә, сандугачым, / Нурлана дөньялары, карлыгачым).

Сөйгән ярга *сандугачым* дию киң таралган. Җырларда *сандугачым, сайрар кошым* (Калфагыңны күтәр-күтәр, / Көдрә чәчең, / Сандугачым, сайрар кошым); *сайрар кошым, сандугачым* (Рәхәт көннәрем бар иде, / Сайрар кошым, сандугачым, / Тибрәнгәндә бишектә; Нинди шатлыклар булса да, / Сайрар кошым, сандугачым, Баса алмыйдыр кайгымны); *асыл кошым, сандугачым* (Асыл кошым, сандугачым, / Җырлап җибәрә микән?) сүзләре очрый. Кайбер җырларда сандугач образы – хатын-кыз, ә карлыгач образы ир-ат белән тиңләштерелә (Син сандугач булсаң, мин карлыгач, / Елама, иркәм, китмәм, иркәм, / Кил, аппагым, саргайтмам).

Орнитоним башка кош атамалары белән дә кулланыла. Мисал өчен, *сандугач-күгәрчен* (Биек тауларда бер авыл, / Ничек алмый җил-давыл? / Сандугач-күгәрчен, / Хәсрәт чигәм, күрәмсең; Төшләремдә бергә булдык, / Уянсам тагын ялгыз. / Сандугач-күгәрчен, / Хәсрәтем синең өчен; Беләсеңме хәлләремне, / Бер күрергә тилмерәм. / Сандугач-күгәрчен, / Саргаям синең өчен); *күгәрчен-сандугач* (Күгәрчен-сандугач, / Ни кылырбыз аерылгач; Алма чәчәге коела / Таңда искән җил белән. / Күгәрчен-сандугач, / Нишлим бәхетем булмагач?); *сандугач-тургай* (Сайрап тора сандугач-тургай).

Җырлардан тупланган мисаллар сандугач орнитонимының халык ижатында чынлап та бик киң кулланылуын һәм күптөрлелеген күрсәтә.

Былбыл орнитонимы гарәп теленнән кергән [9: 53]. Сандугач атамасының синонимы буларак кулланылса да, орнитологик чыганаклар күрсәткәнчә, былбыл – башлыча Африка һәм Азиядә тереклек итә торган *былбыл кошлар* (рус. Бюльбюлевые; лат. Pycnonotidae) семьялыгына керә торган кошларны белдерә [10: 26]. Моңа кадәр Россиядә былбылларның бер төре генә очрый дип санала иде. Орнитологлар мәгълүматы буенча, соңгы елларда тагын бер төре – кытай былбылы күренә башлаган [1: 621; 3: 46].

Сөйләм телендә, көндәлек тормышта сандугач атамасы кулланылса, былбыл – матур әдәбиятта, аеруча поэтик жанрда актив.

Татар халык җырларын тикшерү күрсәткәнчә, былбыл образы нигездә сандугач образы белән тиңдәш. Без тикшергән җырларда иң беренче чиратта былбыл шулай ук хис белән (туган якны һәм сөйгән ярны сагыну) бәйле. Былбыл сайраулары туган якны искә төшерә, сагындыра (Былбыл өзелеп сайраганда, / Бик ямансу, бик ямансу, / Бик ямансу ят җирдә шул / Бик ямансу ят җирдә; Кычкырыр ла күке, сайрар былбыл, / Шул чагында ничек лә түзәрбез?).

Татар халык җырларында былбыл *сагышлы* (Сайрамачы, былбыл, ник сайрыйсың? / Өзелә үзәк синең тавышка. / Сайрыйсыңмы син дә, минем кебек, / Көне-төне ачы сагышка?); *моңлы* (Кара урманнарның уртасында / Былбыл кошлар сайрый моңланып. / Барлык дус-ишләрем арасында / Бер мин генә моңлы булганмын). Лирик герой үзен дә былбыл белән тиңли, былбыл тавышларын тыңлап моңая (Ай, былбылым, гүзәлем! / Өзелә ич үзәгем, Әй, моңаям).

Сандугач кебек үк, былбыл да гыйшык җырларындагы иң тәэсирле образ (Талда былбыл кошлар утыра, / Чыдап булмый гыйшык утына). Сандугачка тиңләгән кебек, хатын-кызны былбылга тиңлиләр (Сандугач микән, былбыл микән / Бу язуны язган иясе?), сөйгән ярга *былбыл, былбылым* дияләр (Үстем, җаным, гөл-гөл, / Синең өчен, былбыл, / Ятлар өчен үсмәдем; Егет: Укалы калфагыңны чыкчы киеп, былбылым, / Кузасына керләр кунмасын гына. / Аерылышыр булсак, бәхилләшик, былбылым, Соңгы көндә рәнҗүләр булмасын гына). Халык җырларында *былбылым* дип кызга да, егеткә дә әйтелә (Кыз: Алмас та гына булгач, ник сөйдең соң, былбылым, / Яшь гомеремне әрәмгә уздырып кына; Егет: Елама, сөйгән яр, син елама, былбылым).

Былбыл кошларның үзләренә мөрәҗәгать итү дә очрый (Ай, былбылым, вай, былбылым, / Агыйделнең камышы. / Таң алдыннан чут-чут

килә / Сандугачлар тавышы; Ай, былбылым, вай, былбылым, / Кунып сайрый талларга. / Синең хакта серләремне / Сөйлим сандугачларга).

Былбыл – матурлык символы. Яраткан яр былбыллардан да матуррак итеп тасвирлана (Ни еллардан бирле күргәнем юк, / Былбыллардан сылу булгандыр).

Былбыл – дус, сердәш, ярдәмче (Әй, югалттым сәгать лә чылбырым, / Тапмадыңмы, сары ла былбылым?).

Татар халкы былбылларга зур хөрмәт белән карый. Ярату һәм алар турында кайгырту (Былбыл оча, канаты талмасын), аерым мөнәсәбәт, сакчыл караш, затлы кош итеп санау сизелеп тора (Былбыл кошларны тотмыйлар, / Тотсалар да атмыйлар).

Сандугачларныкы кебек үк, былбылларның да сайрау урыны *алмагачта* (Алмагач өстендә сары былбыл / Канатларын кага очканда); *талларда* (Былбыл да бар, кондыз да бар / Димнең талы ягында; Агыйдел кага ярына гына, / Былбыллар куна талына гына); *кылганда* (Кенәлекәй буе кылгандыр, / Кылганына былбыл кунгандыр); *гөлләрдә* (Гөл бакчасында гөлләр үсә, / Арасыннан былбыллар үтәлми. / Үзеңне күреп сөйләмичә, / Хатка язып сүзләрем бетәлми; Бакчаларда гөлләр, әй, үсәдер, / Арасыннан былбыл үтәдер, үтәдер); *муелларда* (Безнең каршыбызда куш муеллар, / Муелларга кунган былбыллар); *камышларда* (Төрле кошлар сайрый икән / Идел камышларында. Иртә уянам, кич моңаям / Былбыл тавышларына); *зәйтүн агачында* (Сандугач белән былбылны / Зәйтүн агачына ла кундыр син).

Анализдан күренгәнчә, татар җырларында сандугач һәм былбыл уңай коннотацияле. Икесе дә матурлык, затлылык символы. Сандугач, былбыл образлары беренче чиратта туган як һәм сөйгән яр белән ассоциацияләнә. Шунысы әһәмиятле: сандугач башка халыкларда да шундыйрак төсмерләрдә, образларда сурәтләнә. Мәсәлән, русларда сандугач – мәхәббәт, романтизм һәм бөек хисләр символы булып тора һәм яшь чак, гашыйк булу чоры белән бәйле рәвештә кулланыла [7: 277]. Башкорт җырларында беренче чиратта матур итеп сайравына бәйле рәвештә телгә алына. «Хәтта кошның үзенә түгел, ә аның сайравына дан җырлана кебек» [6: 174]. Шул ук вакытта сандугач белән былбыл образлары сөйгән кызны белдерә һәм ялгыз, сагыш утында янган кешеләрнең юлдашы ролендә килә [14: 137]. Башка халыкларныкыннан аермалы буларак, мари җырларында сандугач әти һәм әни, чуваш җырларында әни белән тиңләштерелә [8: 11]. Болар барысы да әлеге образларның төрлелеген күрсәтә. Сандугач сүзенә башланган 500 ләп кыска җырны туплаган «Сандугачым-былбылым» (Казан, 1985) исемле җыентык та сандугачларның татар халкының рухи һәм мәдәни тормышындагы ролен ассызыклый.

Шулай итеп, җыр үрнәкләре татар телендә сандугач һәм былбыл атамаларының чынлап та синонимнар буларак кулланылуын күрсәтте. Былбыл – җылы якларда гына очрый торган былбыл кошлар семьялыгы кошы булып түгел, үзебезнең каен, карама, алмагачларыбызга кунып сайрый торган кош буларак кабул ителә.

Анализланган татар халык җырларында сандугач һәм былбыл: 1) су буенда, урманда, бакчада, чишмә янында һ. б. очрый; 2) талга, тирәккә, каенга, миләшкә, камышка һ. б. кунып сайрый; 3) Агыйдел, Дим, Зәй, Идел

буйларын үз итә; 4) матур сайравы белән таң калдыра; 5) моңлы сайравы белән туган якны искә төшереп тора; 6) гашыйкларның сердәше ролен үти; 7) сөйгән яр образында килә; 8) матурлык, затлылык символы булып тора. Сөйгән ярга «сандугачым», «былбылым» дип дәшү, яраткан кешене сандугач белән былбылга тиңләү шулай ук халыкның әлеге кошларга карата ихлас хисләрен һәм яратуын, хөрмәтен белдерә.

ӘДӘБИЯТ

1. Беляев Д.А. Увеличение числа встреч рыжеухого бюльбюля Microscelis amaurotis на Дальнем Востоке России за последние годы / Д.А. Беляев, В.П. Шохрин, Ю.А. Дарман [и др.] // Амурский зоологический журнал. 2022. Т. 14, № 4. С. 620–631.

2. Галимова Э.М. Традиционная музыкальная культура пермских татар. 2-е изд. Казань: ИЯЛИ, 2021. 328 с.

3. Глущенко Ю.Н. Китайский бюльбюль Pycnonotus sinensis – новый вид в авифауне России // Русский орнитологический журнал. 2013. Т. 22. № 835. С. 46–47.

4. Замалиева Л.З. Генетическая и типологическая общность в тематике и образной системе татарских, башкирских, чувашских народных песен: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2004. 26 с.

5. Кузьмина А.В., Малыхина Т.М. Наименования птиц в курской песенной лирике // Лингвофольклористика. 2024. № 39–1. С. 15–24.

6. Лексика башкирского песенного фольклора в этнолингвистическом освещении / отв. ред. – д-р филол. наук, проф. Ф.Г. Хисамитдинова. Уфа: ИИЯЛ УНЦ РАН, 2017. 260 с.

7. Ли Фэн. Зоонимы в жанре русской народной песни: деривативные аспекты // Казанская наука. 2024. № 10. С. 276–279.

8. Миңнуллин К.М. Җырларның шигъри табигате. Казан: Мастер Лайн, 1999. 107 б.

9. Сафина Э.И. Названия птиц в татарском языке и их лексикографирование. Казань: Дом печати, 2006. 160 с.

10. Сафина Э.И. Татарча-русча-латинча кош атамалары сүзлеге. Казан: ТӘhСИ, 2018. 184 б.

11. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: V т.: С–Т / Э.И. Сафина, И.И. Сабитова, О.Н. Галимова, Г.Г. Саберова, Р.Т. Сәфәров, А.Ф. Гайнетдинова, Ю.Ф. Борһанова, Ф.И. Таһирова, Ф.Ф. Гаффарова, А.Ә. Тимерханов, Р.Р. Абдуллина. Казан: ТӘhСИ, 2019. 908 б.

12. Татар теленең мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. 510 б.

13. Татар халык җырлары. Казан: Татар. кит. нәшр., 1965. 455 б.

14. Хакимьянова А.М. Символика в башкирской народной песенной традиции // Вестник Челябинского государственного университета. 2014. № 10 (339). С. 133–138.

УДК 811.512.145

Сәфәров Ринат Тәһир улы
ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
Казан, Россия
Сафаров Ринат Тагирович
Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
Казань, Россия
Safarov Rinat Tagirovich
G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art
of the Tatarstan Academy of Sciences
Kazan, Russia
E-mail: safar.rinat@yandex.ru

АҢЛАТМАЛЫ ЛЕКСИКОГРАФИЯДӘ СҮЗЛЕК МӘКАЛӘСЕ ЗОНАЛАРЫН ПАРАМЕТРИЗАЦИЯЛӘҮ ПРОБЛЕМАЛАРЫ

ПРОБЛЕМЫ ПАРАМЕТРИЗАЦИИ ЗОН СЛОВАРНОЙ СТАТЬИ В ТОЛКОВОЙ ЛЕКСИКОГРАФИИ

PROBLEMS OF PARAMETERIZATION OF DICTIONARY ENTRY ZONES IN EXPLANATORY LEXICOGRAPHY

Аннотация. *Статья посвящена актуальной проблеме параметризации зон словарной статьи в татарской лексикографии. На материале современных толковых словарей татарского языка проводится комплексный анализ микроструктуры словарных статей. Основное внимание уделяется таким ключевым зонам, как вокабула (включая проблему подачи глагольной леммы), фонетическая характеристика (акцентология и транскрипция) и этимологическая справка. Выявляется вариативность в представлении лингвистической информации и отсутствие единых стандартов. Результаты исследования позволяют определить приоритетные направления для унификации и оптимизации структуры словарных статей в будущих словарях татарского языка с целью повышения их научной ценности и функциональности.*

Annotation. *The article is devoted to the actual problem of parameterization of dictionary entry zones in Tatar lexicography. Based on the material of modern explanatory dictionaries of the Tatar language, a comprehensive analysis of the microstructure of dictionary entries is carried out. The main focus is on key areas such as vocabulary (including the problem of presenting a verbal lemma), phonetic characteristics (accentology and transcription), and etymological reference. The variability in the presentation of linguistic information and the lack of uniform standards are revealed. The results of the study allow us to identify priority areas for the unification and optimization of the structure of dictionary entries in future dictionaries of the Tatar language in order to increase their scientific value and functionality.*

Ключевые слова: *татарский язык, лексикография, толковый словарь, микроструктура, зоны словарной статьи, лемма, этимологическая справка*

Keywords: *Tatar language, lexicography, explanatory dictionary, microstructure, dictionary entry zones, lemma, etymological reference*

Сүзлек мәкаләсенең микроструктурасы аңлатмалы сүзлекләрнең иң мөһим компонентларыннан берсе. Нәкъ микроструктура баш сүз (вокабула, сул як), фонетик транскрипция, морфологик характеристикалар, мәгънәне аңлату, иллюстратив мисаллар, стилистик тамгалар һ. б. зоналарны үз

эченә алган һәр аерым сүзлек фрагментының эчке структурасын (уң якны) бирү ысулларын билгели [6].

Микроструктураны (яки сүзлек мәкаләсенең структурасын) өйрәнү аерым сүзлек берәмлеге кысаларында материалны сайлап алу һәм системалаштыру принципларын аңлау өчен зур әһәмияткә ия. Сүзлек мәкаләсе элементларының урнашу үзенчәлекләрен, зоналарның урнашу тәртибен, бирелгән мәгълүматның характерын һәм аны визуальләштерү ысулларын анализлау сүзлек структурасын оптимальләштерү юнәлешләрен билгеләргә мөмкинлек бирә.

Хәзерге лексикографиянең теориясе һәм практикасы сүзлек мәкаләләренең структур характеристикаларын җентекләп өйрәнүне таләп итә, чөнки тикшеренүнең нәкъ менә шушы өлкәсе сүзлектән файдалануның уңайлы булуы һәм барлык кирәкле лингвистик мәгълүматны җыйнак һәм ачык итеп бирә алу мөмкинлеге белән турыдан-туры бәйләнгән.

Татар теленең хәзерге аңлатмалы сүзлекләрендә микроструктураның төрлечә булуына карамастан, сүзлек мәкаләләрендәге зоналар системасы нигездә бер үк принципларга нигезләнә. Лексикографик анализ нәтиҗәләре күрсәткәнчә, бигрәк тә фигыльләрнең сүзлек мәкаләләре структура һәм эчтәлек ягыннан профессиональ лексикографларның таләпләренә тулысынча җавап бирми, шулай ук тәжрибәле кулланучылар өчен дә җитәрлек дәрәҗәдә ачыклык һәм тулылык тәкъдим итми. Хәзерге вакытта хәл ителмәгән төп проблемалар арасында фигыль формаларының тулысынча чагылыш тапмавы, төрле юнәлештәге фигыльләрнең системалы теркәлмәве [4: 22], шулай ук хәл фигыльләрнең сүзлектә фрагментар рәвештә күрсәтелүе аеруча әһәмиятле мәсьәлә булып кала бирә.

Сүзлек мәкаләсенә караган бу һәм башка кайбер проблемаларны ачыклау максаты белән, тикшерү объекты буларак 1) 1977, 1979, 1981 елларда басылып чыккан өч томлы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (алга таба – АС3); 2) 2005 елгы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (АС1); 3) 2013 елгы «Татар теленең мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлеге» (МАС); 4) 2015–2021 елларда нәшер ителгән алты томлы «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (АС6) һәм шуның 2020–2024 елларда басылып чыккан икенче басмасы алынды.

В.В. Дубичинский фикеренчә, әгәр дә тасвирланасы тел берәмлеге турында «бөтен» мәгълүматны үз эченә алган инвариант сүзлекнең сүзлек мәкаләсен күз алдына китерсәк, ул 1) баш сүз, 2) аның фонетик тасвирламасы, 3) аның грамматик тасвирламасы, 4) семантизациясе, 5) баш сүзнең башка сүзләр белән бәйләнеше, 6) баш сүзнең сүзьясалыш мөмкинлекләре, 7) этимологик белешмә, 8) иллюстратив белешмә (лексикографик иллюстрация), 9) лексикографик тамгалар, 10) энциклопедик мәгълүмат һәм 11) сылтамалардан гыйбарәт булыр иде [1: 107–112].

Татар теленең хәзерге аңлатмалы сүзлекләре инвариант сүзлек дәрәҗәсендә түгел, шулай да аларны бу юнәлештә камилләштерү киләчәктәге бурычыбыз итеп каралырга тиеш. Бу контекстта В.В. Дубичинский тәкъдим иткән һәр зона анализына мөрәҗәгать итү һәм аның методологик аппаратын татар теленең аңлатмалы сүзлекләренә карата кулланып тикшерү урынлы булыр дип саныйбыз. Безнең бу мәкалә үзәгенә исә баш сүз, фонетик тасвирлама һәм этимологик белешмә зоналары алынды.

1. Баш сүз (вокабула). Рус теленең аңлатмалы сүзлекләрендә, кагыйдә буларак, вокабуланы оештырган сүзләр, баш хәрефләр генә кулланып, эзлекле рәвештә бертөрле бирелә. Гадәттә юл хәрефеннән язылган сүзнең баш хәрефтән язылу очраклары мәкалә эчендә аңлатма башында күрсәтелә:

ЛУНА, -ы, мн. луны, лун, лунам, ж. 1. (в терминологическом значении Л прописное). Небесное тело, спутник Земли, светящийся отраженным солнечнымсветом. *Полет на Луну. Серп луны.* <...> 2. Свет, идущий от такого небесного тела. *Читать при луне.* 3. Спутник любой планеты (спец.). [Ожегов, Шведова, Толковый словарь русского языка]

ПИСАНИЕ, -я; **ср. 1.** к Писать (1-3, 8-11 зн.). <...> *Учиться писанию букв.* **2.** Разг. То, что написано от руки; письмо, рукопись. *Неразборчивое п.* **3.** Разг. О многословном, малосодержательном сочинении. *Не хочу читать газетных писаний!* **4.** [с прописной буквы] Книги Ветхого Завета (*включая книги пророков*). <...> **5.** Для последователей какой-л. религии: Текст, содержание которого составляет основу вероучения и считается священным (1 зн.). [Большой толковый словарь русского языка].

Рус телендә сүзнең гомумән һәр очракта яки аерым мәгънәсенең генә баш хәрефтән язылуы *Антарктика, Арктика, Библия, бобыль, Богоматерь, варшавянка, Восток, Вселенная, Господь, Дубинушка, май, октябрь, Пасха, Рождество, Талмуд* һ. б. сүзлек мәкаләләрендә күрсәтелгән.

Төрек теленең аңлатмалы сүзлегендә, кагыйдә буларак, баш хәреф аша языла торган сүзләр аерым мәкалә булып бирелә:

tatar *is., esk.* Mektup, haber vb. şeyleri gidecekleri yere götüren atlı posta arabasını süren kimse.

Tatar *öz is.* Rusya Federasyonu'na bağlı Tataristan Özerk Cumhuriyeti'nde ve Kırım'da yaşayan Türk halkı ve bu halkın soyundan olan kimse.

Güneş *öz is., astr.* Gezegenlere ve yer yuvarlağına ışık ve ısı veren büyük gök cismi.

güneş *is.* Bu gök cisminin yaydığı ışık ve ısı; gün, şems. [Türkçe sözlük]

Татар теленең аңлатмалы сүзлекләредә вокабула бирелеше рус сүзлекләре белән тәңгәл, ләкин мәгънәсенә карап баш хәрефтән яки юл хәрефеннән языла алган сүзләр төрлечә чагылыш тапкан:

КӨНЧЫГЫШ *и.* 1. Дөньяның дүрт ягының берсе: горизонтның көнбатышка каршы булган, кояш чыккан ягы. <...>; 2. (*баш хәреф белән языла*) Көнбатыш Европа дәүләтләреннән көнчыгышка таба урнашкан илләр. <...> [АС3: т. 2; 268].

КӨНЧЫГЫШ *ис.* **1.** 1) Дөньяның дүрт ягының берсе, кояш чыккан ягы. <...>; 2) (*Беренче хәрефе баш хәреф белән языла*) Бу юнәлештә урнашкан илләр, Көнбатыш Европага һәм Америка илләренә каршы куела. <...> [АС1; 321–322].

КӨ́НЧЫГЫШ (-ка; -тан; -ы) *ис.* **1.** 1) Дөньяның дүрт ягыннан берсе: көнбатышка капма-каршы, горизонтның кояш чыккан ягы; мәшрикъ. <...>; 2) Көнчыгышта урнашкан өлеш. <...>; 3) Көнчыгышта урнашкан дәүләтләр турында. <...>. [МАС: 202]

КӨ́НЧЫГЫШ *и.* **1.** 1) Дөньяның дүрт ягының берсе: горизонтның көнбатышка каршы булган, кояш чыккан ягы; мәшрикъ. <>

2) Европага карата шул тарафта урнашкан илләр. *Урта гасыр мәзһәбләреннән оеган Көнчыгыш тирән йокыда хәзер.* Р. Хәкимов. <...> [АС6: т. 3: 437].

Шулай итеп, татар теленең аңлатмалы белешмәлекләрендә баш хәреф кулланышына карата түбәндәге үзгәрешләр күзәтелә: элеккерәк сүзлекләрдә баш хәрефтән языла торган лексемалар аерым билгеләнгән булса, соңгырак басмаларда бу критерийгә әһәмият кимегән. Аларда баш хәреф кулланышы я бөтенләй күрсәтелмәгән, я иллюстратив материаллар аша гына чагылдырылган.

Лексикографик практика күрсәткәнчә, сүзлек кебек белешмәлектә, аеруча аның тулы типтагы булганында, мондый мәгълүмат системалы рәвештә күрсәтелә. Һәрхәлдә, сүз инвариант сүзлек турында барганда, ул һичшиксез күрсәтелергә тиеш.

Вокабулага караган тагын бер мәсьәлә – фигыльләрнең сүзлек формасы. Хәзерге татар лексикографиясендә фигыль леммасын билгеләүдә бердәм стандарт юк. Кайбер сүзлекләр фигыльләрне инфинитив формасында (*укырга, язарга*), кайберләре исем фигыль формасында (*уку, язу*) бирә. Элегрәк төзелгән сүзлекләрдә баш сүз буларак фигыльләрнең бирелеш төрләре тагын да күбрәк булган [2: 7–10]. Мондый вариатлылык башка төрки телләрдә дә (мәс., казак телендә) күзәтелә. Бу исә сүзлек мәкаләләрен унификацияләүне катлауландыра.

Безнеңчә, аңлатмалы (һәм бигрәк тә тәрҗемәле) сүзлекләрдә фигыль леммасын инфинитив формасында кабул итү уңышлырак булыр иде. Инфинитивны сүзлек формасы итеп сайлау берничә проблеманы чишә: 1) ул баш сүзнең фигыль булуын күрсәтеп тора; 2) фигыльләрне исемнәрдән аеру проблемасын хәл итә (*көтү I* һәм *көтү II* түгел, *көтәргә* һәм *көтү; сайлау I* һәм *сайлау II* түгел, *сайларга* һәм *сайлау*); 3) *ул-, уп-, яз-, кип-, көл-* кебек күпсанлы бер иҗекле фигыльләрнең орфографиясен нормалаштыра һәм ныгыта [5: 368], чөнки исем фигыль формасында, мәсәлән, *көлү* дип бирү *көләргә*ме, *көлергә*ме икәнен күрсәтми.

2. Фонетик тасвирлама. Фонетик характеристика баш сүз итеп бирелгән тел берәмлегенең әйтелешен (башлыча транскрипция һәм басым билгесе) күрсәтүне үз эченә ала.

Татар теле язылышы белән укылышы арасында зур аерма булган телләрдән берсе. Бу аерма үзтума сүзләрдә дә (калын/нечкә [к]/[к], [ғ]/[г] авазлары өчен аерым графемалар булмау; [w] авазының позицион вариантлары өчен *в, у, ү* кебек төрле графемалар кулланылу; ирен гармониясе язуда чагылмау: *бөтен, болытлы* һ. б.), алынмаларда да (*шикаять, вәкаләт, гуаһ* кебекләрдә [к] һәм [г] нечкә булуы язуда чагылмау, рус алынмаларында нигездә рус фонетик нормалары саклану һ. б.) бик еш очрый. Шуңа карамастан, татар лексикографиясендә фонетик транскрипция кулланылышы системале характерда түгел. Мисал өчен, инглиз телендә дә укылыш белән язылыш аермасы зур. Шул ук вакытта «Инглиз теленең Оксфорд сүзлеге» («The Oxford English Dictionary») кебек норматив сүзлекләрендә һәрвакыт һәр сүзнең фонетик тышчасы мәҗбүри рәвештә күрсәтелә.

Анализ өчен алынган татар аңлатмалы сүзлекләре арасыннан бары тик өчтомлыкта гына кайбер омографларның укылышын ачыклап квадрат җәяләр эченә транскрипциясе бирелгән:

А́РКА *и. махс.* 1. Ишек, тәрәзә, мич кебек нәрсәләрнең көймәләп эшләнгән түбәсе (түшәме) <...>.

АРКА́ [арқа] *и.* 1. Гәүдәнең муеннан алып оча сөягенә кадәрге арткы як (хайваннарда, кош-кортларда – югарыгы, сырт як) өлеше. <...>. [АС3, т. 1: 67]

КОРТ [қорт] I *и.* 1. Озынча гәүдәсе белән боргаланып яки бер җыерылып, бер сузылып хәрәкәт итә торган умырткасыз тереклек иясе. <...>.

КОРТ [қорт] II *и. махс.* Әчегән сөтне әкрен янган утта озак, кызыл төскә кергәнче кайнатудан алынган ашамлык, кызыл эремчек. <...>

КОРТ *и. спорт.* Теннис уены мәйданы. [АС3, т. 2: 160–161]

Басым билгесе һәр вокабулага куелган бер генә аңлатмалы сүзлек тә юк. Күпчелек очракта бу билгене куймау татар телендә басымның сүздәге соңгы иҗеккә төшүе белән аңлатыла, шул сәбәпле лексикографлар аны махсус билге белән күрсәтүне кирәксенми. Алты томлы аңлатмалы сүзлектә *-ау* яки *-әү* дип бетә торган сүзләрдә, *у* һәм *ү* [w] тартыгын белдергәнне күрсәтү максаты белән, алардан алда килгән *-а-* һәм *-ә-* хәрефләренә басым билгесе куелган:

АША́У *ф.* 1) Ашамлык, ризык кабул итү. <...>. [АС6, т. 1: 275]

БЕРӘ́Ү *сан* 1. Барысы, бөтенесе бергә бер генә булуны белдергән җыю саны. <...>. [АС6, т. 1: 492]

Басым соңгы иҗеккә төшмәгән очракта анализланган сүзлекләрдә ул махсус билге белән күрсәтелгән. Ләкин, фикеребезчә, норматив сүзлек статусына ия булган һәр белешмәлектә басым билгесе һәр очракта һәм һәрвакыт күрсәтелергә тиеш. Басымның кушымчага күчүе яки күчмәве дә грамматик зонадагы мәгълүматта чагылыш табарга тиеш. Мәсәлән:

САБА́К *и.* -гы́, -кка́, -та́н <...>.

КОММУНИ́ЗМ *и.* -ы, -га, -нан <...>.

Аеруча басымны парлы һәм кушмы сүзләрдә, ярдәмлек сүз төркемнәрендә мотлака билгеләү сорала, чөнки ике төрле әйтелештән кайсы дөрес икәнен норматив сүзлекләр генә күрсәтә ала. Бу аларның төп бурычларыннан берсе. Кайбер сүзлекләрдә, бигрәк тә уку-укыту сүзлекләрендә, басым билгесе вокабулада гына түгел, ә аңлатмаларда һәм иллюстратив материалда да куелырга тиеш. Бу үзенчәлек мәктәп яшендәге балалар, татар телен өйрәнүчеләр, шулай ук телебезнең интонацион нормаларын өйрәнүчеләр өчен бик мөһим. Бүгенгә исә транскрипция мәсьәләсе дә, басым мәсьәләсе дә киләчәктә төзеләсе сүзлекләрдә уңай хәл ителүне көтә.

3. Этимологик белешмә. Хәзерге тулы типтагы аңлатмалы сүзлек мәкаләләрендә этимологик комментарийның кирәклеге, хәтта мәҗбүрилеге шик тудырмый. Диахроник мәгълүмат сүзне тирәнрәк һәм төгәлрәк аңларга ярдәм итә һәм кулланучының гомуми мәдәниятен күтәрүгә өлеш кертә [7: 56–57].

Татар теленең сүзлекләрендә этимологик белешмә беренче тапкыр 2005 елгы аңлатмалы сүзлеккә кертелә. Ул баш сүздән соң этимонның чыганак телен күрсәтү белән чикләнә:

РОМА’ШКА *и. бот. рус* Акбаш. <...> [АС1: 451].

Шул ук принципта алынма сүзләрнең чыганак теле алты томлы сүзлектә дә бирелә:

ГОЗЕР *и. гар.* 1) Үтенеч, ялыныч, йомыш. <...> [АС6: т. 2, 84].

Шул ук вакытта этимон турында мондый кыска мәгълүматның җитмәве бәхәс тудырмый. Күп вакытта сүз чыганак телдәге мәгънәне сакламаска мөмкин. Арадаш телләрне күрсәтү проблемасы бар. Шулай ук төрки телләрнең үзара алынмалары һәм гарәп теленнән кергән дип саналган, ләкин асыллары борынгы грек яки латин теленә кайтып кала торган берәмлекләрнең (мәс., *җенес, намус*) этимологик тасвирламасын бер генә тамга белән биреп бетерү мөмкин түгел.

Күпчелек очракта сүзнең килеп чыгышы турында мәгълүмат алынма сүзләрдә бирелә, чөнки борынгы гомумтөрки лексикадан татар теленә мирас булып калган сүзләр этимологик белешмә белән тәэмин ителми. Шулай ук тел һәм халык атамаларының этимологиясе турында да мәгълүмат бирелми. Этимологик белешмәләрдә хәзерге тарихи, этимологик һәм аңлатмалы сүзлекләрдә шик астына алынмаган иң ышанычлы мәгълүмат кына китерелә ала. Килеп чыгышы бөтенләй аңлашылмый яки актив фикер алышулар объекты булган сүзләрнең этимологиясе турында шулай ук комментарий бирелми.

Г.Н. Скляревская җитәкчелегендә «XXI гасыр рус теле сүзлеге» дип аталган аңлатмалы сүзлек инструкциясендә этомологик белешмә өчен махсус зона каралган. Проект авторлары сүзнең килеп чыгышына бәйле сигез төрле схема тәкъдим итә:

1. Әгәр дә сүз рус теленә чыганак телдәге прототибы (этимоны) мәгънәсендә керсә, этимон аңлатылмыйча күрсәтелә:

апре́ль <…> [лат. Aprilis] <…>
биле́т <…> [франц. Billet] <…>.

2. Әгәр дә алынма белән аның прототибының (этимонның) мәгънәләре тәңгәл булмаса, соңгысының аңлатмасы китерелә:

а́ура <…> [< греч. aura ветерок, дуновение] <…>
эффе́кт <…> [< лат. effectus исполнение, осуществление] <…>

3. Әгәр этимонның формасы һәм мәгънәсе турында мәгълүмат җитәрлек булмаса яки каршылыклы булса, ләкин сүз чыганагы булган тел билгеле булса, этимология зонасында этимонның формасын китермичә, ул тел (яки телләр төркеме) күрсәтелә:

ано́лис <…> [нов.-лат. Anolis < аравакский яз.] <…>
арча́ <…> [тюрк.] <…>

4. Әгәр сүз рус теленә кергәнче берничә Европа телендә таралган булса һәм аның якындагы чыганагын төгәл билгеләп булмаса, этимологик белешмәдә сүзнең беренче чыганагы гына китерелә (гадәттә латин яки борынгы грек телләре):

акаде́мия <…> [< греч. Akadēmia назв. школы в пригороде Афин, в которой учил Платон] <…>
ге́ний <…> [< лат. genius талант, дарование] <…>

5. Халыкара фәнни номенклатурада кабул ителгән ботаника, зоология һәм медицина терминнары өчен этимология зонасында, кагыйдә буларак, аларның яңа латин формасы китерелә (үсемлек һәм хайван төрләренең исемнәре баш хәрефтән языла):

аннóна <…> [нов.-лат. Annona < яз. таино anon] <…>
ба́дис <…> [нов.-лат. Badis < лат. badius каштановый] <…>

6. Этимология зонасында шулай ук шәхси исемнәрдән һәм топонимнардан ясалган алынма һәм рус телле терминнарның килеп чыгышы да аңлатыла; мондый очракларда, гадәттә, сүзнең иң башта барлыкка килгән теле күрсәтелми:

айршúр <…> [по назв. графства Айршир в Шотландии] <…>

базáровщина <…> [по фамилии главного героя романа «Отцы и дети» И. С. Тургенева (1818–1883)] <…>

фаллóпиев <…> [по имени итальянского врача-анатома Г. Фаллопио (1523–1562)] <…>

7. Әгәр этимонның эчке формасы һәм аның алдагы тарихы рус алынмасы семантикасын яки ул билгеләгән чынбарлыкның килеп чыгышын аңлау өчен кызыклы булса, этимологик белешмәдә сүзнең рус теленең элементы булганчы башка телләрдә нинди юл үтүе турында хәбәр ителә. Бу мәгълүмат кыскартылып бирелә һәм сүз тарихының ике (сирәк өч) этабы белән чикләнә. Роман чыгышлы сүзләр өчен этимология, кагыйдә буларак, аларның латин телендәге беренче чыганагына җиткерелә (әгәр бу чыганак билгеле булса). Алынма юнәлеше һәм этаплары < график билгесе белән билгеләнә:

ананáс <…> [франц. ananas, нем. Ananas < яз. тупи naná, ananá] <…>

бензоúн <…> [нем. Benzoe, франц. benjoin < араб. (lu)bān-ğāwi яванский ладан] <…>

8. Этимологик белешмәдә этимонның катлаулы составы турында да мәгълүмат булырга мөмкин:

алтабáс <…> [тур. altynbäz < altyn золото + араб. bazz холст, полотнище] <…>

ведáнта <…> [санскр. vedānta < veda (священное) знание, Веда + anta конец, завершение] <…> [3: 188–191].

Шулай итеп, рус теленең яңа төзелә торган сүзлекләрендә этимологик зонага зур игътибар бирелә. «XXI гасыр рус теле сүзлеге» проекты этимологик белешмәне төгәл системага салып биргән үрнәк ролен үти ала. Авторлар тәкъдим иткән схемалар аша этимологик мәгълүматны беренче чыганак телдән башлап, арадаш телләрне дә исәпкә алып, тулы һәм иерархик рәвештә тәкъдим итү мөмкин. Бу модель татар теле лексикографиясе өчен дә өлге булырлык югары стандартлар куя.

Татар теленең аңлатмалы сүзлекләрендә сүзлек мәкаләсе зоналарын параметризацияләү ачык, системалы һәм фәнни нигезләнгән стандартлар эшләп чыгаруны таләп итә. Хәзерге татар сүзлекләрендә зоналар системасы катлаулы, аларның төзелешендә һәм форматында аермалар саклана. Мәкалә зоналарын параметризацияләү бердәм стандартлар эшләүне таләп итә. Безнең тикшеренү вакабула формасын стандартлаштыру, фонетик тасвирламаны (транскрипцияне һәм басым билгеләрен) системага салу һәм этимологик белешмәне тирәнәйтү кебек юнәлешләрдә ачык параметрлар билгеләргә мөмкинлек бирә.

Җитди, бигрәк тә тулы типтагы һәм мәктәп сүзлекләрендә баш сүзләрнең транскрипциясен бирү, басым билгеләрен вокабулада гына түгел, аңлатмаларда, мисалларда да куллану кулланучылар өчен аеруча мөһим. Шулай ук бу ялгышлар һәм ике төрле укылышлардан качарга мөмкин-

лек бирә торган чара. Фигыль леммасын инфинитив формасында (язарга, укырга) күрсәтү аны башка сүз төркемнәреннән аеру, кайбер орфографик проблемаларны чишү һәм сүзлек мәкаләләрен унификацияләү өчен иң рациональ юл дип саныйбыз. Этимологик зонаны баетырга, рус лексикографиясендә кулланылган принципларны (чыганак телне, этимонны, аның мәгънәсен, арадаш телләрне күрсәтү, график тамгалар куллану) алда төзеләсе сүзлекләрнең иң мөһим бурычларыннан берсе. Бу сүзнең семантикасын аңлатуны тирәнәйтә һәм кулланучының лингвистик мәдәниятен күтәрергә ярдәм итә торган белешмә.

Сүзлек мәкаләсенең барлык зоналарын да (грамматик, иллюстратив, фразеологик, стилистик һ. б.) бердәм стандартлар буенча параметризацияләү – киләчәктәге татар аңлатмалы сүзлекләрен төзүнең төп юнәлеше. Бу эш лексикографиянең хәзерге заман таләпләренә җавап биргән, кулланучы өчен уңайлы һәм лингвистик яктан тулы, югары сыйфатлы белешмәлекләр булдырырга мөмкинлек бирәчәк.

ӘДӘБИЯТ

1. Дубичинский В.В. Микроструктура инвариантного словаря // Вестник Новосибирского государственного педагогического университета. 2014. № 4 (20). С. 107–113.

2. Миннуллин Ф.Г. Глаголы татарского языка и их лексикографирование: автореф. дис. … канд. филол. наук. Казань, 2003. 26 с.

3. Проект «Словаря русского языка XXI века». Образцы словарных статей / Г.Н. Скляревская, И.О. Ткачева, М.Л. Сергеев [и др.] // Journal of Applied Linguistics and Lexicography. 2019. Т. 1, № 1. С. 136–311.

4. Сәфәров Р.Т. Берничә йөкләтү юнәлеше кушымчасы белән килгән фигыльләрнең сүзлектә теркәлеше // Фәнни Татарстан. 2023. №. 3(39). С. 21–25.

5. Сәфәров Р.Т. Сүзлекләрдә фигыльләрнең бирелеше // Хәзерге академик фәндә Россия халыкларының телләре, әдәбиятлары һәм мәдәниятләре: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты оешуга 85 ел тулуга багышланган Халыкара фәнни форум (Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары җыентыгы), Казан, 09–11 октября 2024 года. Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, 2024. С. 367–372.

6. Структура словаря [Электронный ресурс]. URL: https://lab314.brsu.by/kmp-lite/kmp2/OTT/tLecture/tDictEntry.htm (дата обращения: 14.08.2025)

7. Шимчук Э.Г. Толковый словарь русского языка с включением сведений о происхождении слов. Составили Н.Ю. Шведова, Л.В. Куркина, Л.П. Крысин. Отв. ред. Н.Ю. Шведова. М., 2007. 1175 с. // Известия Российской академии наук. Серия литературы и языка. 2010. Т. 69, № 4. С. 54–58.

СҮЗЛЕКЛӘР

АС3 – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда. Казан: Татар. кит. нәшр., 1977, 1979, 1981.

АС1 – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / Ф.Ә. Ганиев ред. Казан: Матбугат йорты, 2005.

МАС – Татар теленең мәктәпләр өчен аңлатмалы сүзлеге. Казан: Татар. кит. нәшр., 2013. 510 б.

АС6 – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: алты томда. Казан: ТӘһСИ, 2015, 2016, 2017, 2018, 2019, 2021; Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: алты томда. Тулыл. һәм төзәт. 2 нче басма Казан: Татар. кит. нәшр., 2020, 2020, 2021, 2022, 2023, 2024.

УДК 811.512.157’373

Скрябина Алевтина Афанасьевна,
Институт гуманитарных исследований и проблем
малочисленных народов Севера СО РАН
Якутск, Россия
Skryabina Alevtina Afanasievna,
Institute for Humanities Research and Indigenous Studies
of the North of Siberian branch of the RAS
Yakutsk, Russia
E-mail: alevtinaskr@gmail.com

ОБРАЗ ДЕВУШКИ-НЕВЕСТЫ В ЯКУТСКОЙ ЛИНГВОКУЛЬТУРЕ

THE IMAGE OF A BRIDE IN YAKUT LINGUOCULTURE

Аннотация. *Статья посвящена анализу образа молодой девушки-невесты в якутской лингвокультуре. В якутском героическом эпосе олонхо и произведениях якутских писателей сформировался идеализированный образ невесты, который представляет собой синтез физических и моральных характеристик, символизирующих высокие эстетические и этические стандарты якутского народа.*

Annotation. *The article is devoted to the analysis of the image of a young girl-bride in the Yakut linguoculture. In the Yakut heroic epic olonkho and the works of Yakut writers, an idealized image of a bride was formed, which is a synthesis of physical and moral characteristics symbolizing the high aesthetic and ethical standards of the Yakut people.*

Ключевые слова: *якутский язык, лингвокультурология, лексика, невеста, образ*

Keywords: *Yakut language, linguoculturology, vocabulary, bride, image*

С древних времен в культурах различных народов формировался идеальный образ девушки, невесты и женщины, который отражает эстетические и культурные ценности общества. Этот идеализированный образ часто воспевается в поэзии, песнях и других художественных произведениях, служа символом красоты, добродетели и женственности. В контексте якутской культуры можно наблюдать, как образы женщин, созданные якутскими писателями, подчеркивают их связь с природой, а также их роль как источника красоты и жизни. Эти произведения демонстрируют женщину как не только объект восхищения, но и как активного участника в сохранении и передаче культурных традиций. Образ женщины в якутском эпосе и литературе становится многозначным символом, который отражает как идеалы, так и реалии жизни, подчеркивая её важность в общественной структуре и культурном наследии народа.

В тюркологии лексика, репрезентирующая образ невесты, как объект анализа был рассмотрен в работах таких исследователей как, Ф.Х. Хасанова [11], А.Р. Габбасова [3], Г.Г. Кульсарина [8], Л.С. Караоол [7], Г. М. Гимашева [4], К.А. Джеенбаева [5] и др. Выделяется лишь ряд работ, в которых изучение образа невесты проводилось на материале якутского языка. Так, например, внимания заслуживает статья Ю.П. Борисова, где рассмотрен концепт «невеста богатыря» в контексте феноменологического подхода на материале шести ранних текстов якутского олонхо [2]. В результате анали-

за выявлены концепты «женская красота», «портрет», «тело», «рукоделие», «жаворонок» и др.), которые образуют представление о «невесте богатыря» – идеально красивой женщине, эталоне красоты в языковой картине мира якутов. Лексико-семантические особенности действующих лиц свадебного обряда, в том числе главного участника – невесты, рассмотрены А.А. Скрябиной [10].

Невеста у якутов обозначается терминами *сүктэр кыыс* и *кийиит*. *Сүктэр кыыс* – кэргэн тахсан, саҥа ыал буолар кыыс. Девушка, вступающая в брак, невеста [1, 2012: 240]. Первая часть этого словосочетания происходит от общетюркского слова «сүк», которое в якутском языке имеет значения, связанные с действиями «класть», «взваливать» или «брать на себя что-либо» (например, ответственность или вину) [там же: 238]. Это слово восходит к древнетюркскому «jük», что означает «груз» или «поклажа» [6: 285]. Вторая часть – это общетюркская лексема «кыыс», которая в якутском языке обозначает «девочку» или «девушку» (до замужества), а также состояние незамужней женщины [1, 2007: 433]. *Кийиит* – 1. Ким эмэ уолун эбэтэр бэйэтиттэн балыс аймаҕын (бырааты, сиэнин) кэргэнэ. Сноха, невестка. 2. Кэргэн тахсан, сүктэн эрэр кыыс. Невеста [там же: 87]. В более ранних словарях значения «невеста» не было, что свидетельствует о расширении значения этого слова в современном якутском языке. По мнению Э.К. Пекарского, *кийиит* относится к жене младшего родственника сына (невестка), племянника или деверя (невестка, ятровь) [9: 1080]. В «Якутско-русском словаре» также указано значение «невестка, сноха» [12: 164]. Э.К. Пекарский считает, что этот термин происходит от общетюркского слова *kelin*, которое означает «невестка, жена сына» [9: 1080] и восходит к древнетюркскому *kelin* «невеста, невестка» [6: 296].

В произведениях якутских писателей, в якутском героическом эпосе олонхо и народных преданиях ярко воплощается образ-идеал якутской девушки-невесты, который характеризуется эстетическими и моральными качествами, такими как красота, чистота помыслов, доброта, гибкость ума, кротость нрава и отменное здоровье. Для передачи красоты якутской невесты в якутском эпосе часто используются устойчивые выражения, такие как *күндү дьүһүннээх* ‘с ликом красивым’, *кубаҕай маҥан* ‘с белоснежным ликом’, *тоҕус былас суһуохтаах* ‘с косой в девять маховых саженей’, *хара киис хаастаах* ‘с черными соболиными бровями’. Эти метафорические конструкции не только подчеркивают физическую привлекательность, но и создают многослойный образ невесты как символа идеальной женственности. Концепт «невеста» эксплицируется посредством сравнения красоты девушки с небесными светилами. Например, строки *Аламаҕай маҥан күн Атыылыыта буолбут Ала тыргыл харахтардаах эбит* ‘у соболинобровой моей Такие сияющие глаза, Что на солнце похожи они’, *Тоҕус күн холбоспутун курдук Туналҕаннаах дьахтар ньуура Туналыс гына түстэ* ‘Засверкал лик женщины, Подобный девяти солнцам, соединившимся в одно’ создают образ невесты как источника света и тепла. Также красота невесты передается через следующие сравнения: *хара саарбатын Хардарыта туппут курдук Хамныы тэрбэйэр Хара хаастардаах эбит* ‘У гордоголовой моей два камчатские соболя, Положенные голова к голове Расходятся вместо бровей’, *Кириэстээх атыыр манньыаты Кэккэлэтэ туппут курдук*

Килбиэн маҕан иэдэстээх эбит ‘У сверкающеглазой моей Такие круглые щеки, Что на серебряные рубли Похожи они’. Эти образы подчеркивают не только физическую красоту, но и гармонию с природой.

Тело девушки описывается как столь светлое и тонкое, что сквозь него просвечиваются вены и кости: *Тело сквозь одежду светлеет, Сквозь тело кости белеют, Сквозь кости мозг просвечивает.* Эти описание создает ощущение хрупкости и невесомости, что также символизирует чистоту и невинность.

Отдельное внимание уделяется одеянию якутской невесты. Полный комплект традиционного костюма невесты состоял из головных уборов в зависимости от времени года *ураа бэргэһэ, чопчуурдаах дьабака бэргэһэ*, наличного покрывала *аҥнах,* шарфа *моойторук*, наплечной одежды *таҥалай, бууктаах сон, кытыылаах сон, халадаай,* натазника *сыалдьа*, рукавицы *үтүлүк,* обувных изделий *тыс этэрбэс, саары*, а также из многочисленных серебряных украшений. В олонхо дается следующее описание: «*…Была ей к лицу говорят, Подвески узорного. Серебра, Цепочки на шейном кольце. Тонкие илин-кэлин кэбисэр, Переливаясь, ярко блестя, поигрывали на груди и спине, Круглая чеканная туосахта, укрепленная надо лбом, Радостно на солнце блестя, озаряла ее лицо…*».

Якутская невеста выделяется не только своей физической красотой, но и музыкальностью голоса, который сравнивается с голосами различных птиц, что подчеркивает ее гармоничное единство с природой. В якутском эпосе и фольклоре ее голос метафорически сопоставляется с мелодичностью и выразительностью певчих птиц. Например: *Ханаҕар быһыылаах, Халыгырас саҥалаах Халлаан хаҥыл кыыла Хаастыыра барахсаҥҥа Ханыылыы харахтыахпын* ‘Сравню я ее с молодой гусыней, С резвой птицей весеннего синего неба (Голова ее запрокинута гордо, Голос у нее – гогочущий громко),’ *Кынтаҕар быһыылаах ,Кылбаҕар дьүһүннээх, Кыҥкынас ырыалаах, Кынаттаах кыылым Кырасыабай бэрдэ Кыталыктыыра барахсан* ‘Сопоставлю ее с самой гордой птицей, С самой стройной и белой из всех пернатых (Оперенье божественное сверкает И как музыка голос ее клекочет)’, *Табыталлаах талыыта, Таҥараны сааратар Тапталлаах чыычаах Татыйыктыыра барахсаҥҥа Таҕааран тэҥниэхпин* ‘Сравню ее с маленькой певчей птицей, Ну хотя бы с хлопотуньей синицей, С той, которая лучше из всех пернатых Услаждает пеньем и людей и богов’. Зооморфные признаки актуализируются также при сравнении девушки с лебедем, жеребенком, жаворонком: *По траве шелковистой Плыла навстречу Лебедем белым, Лепестком прелестным*; *На щеках румянец заиграл, На глазах слеза заблистала, Глазами влажными Февральского жеребенка; Сереброгрудый жаворонок мой, Медногрудый птенчик мой, Говорящая вещая птичка моя, Молодая невеста, бедняжка моя!*

Кроме того, якутская невеста обладает ясным проницательным умом и острым языком: *Эппэт кэлэҕэй гынар Элбэх эргитиилээх мэйиилээх* ‘Голова у нее такая умная, Что всех в молчание повергает’, *Ыллыбыт суолу ыпсарар Ыллыктаах ыраас тыллаах* ‘Язык у нее так остер и меток, Что самых дерзких замолчать заставляет’. Важно отметить, что якутская невеста также обладает доброй душой и оказывает облагораживающее воздействие. Ее присутствие очищает людей от злых мыслей и наполняет их чистыми

помыслами: *Саҥата суох ыытар Сайаҕас сайдам санаалаах* ‘Душа у нее такая добрая, Что все в удивлении замолкают’, *Ыксаласпыт эрэ киһи Быттах санааттан быралыйан Ыраас санааны ылынар* ‘Если кто окажется рядом Все нечистые мысли свои теряет, Только чистые помыслы остаются’, *Дьүөкэт үөрэҕиттэн төлөрүйэн Дьүүллээх өйүн* түмүнэр ‘Если кто окажется рядом Все коварные помыслы растеряет, Все затеи глупые позабудет’.

Овладение рукодельными навыками является важным элементом подготовки невесты к ее новой социальной роли, что может быть проиллюстрировано через использование ключевых выражений, таких как *солко нуоҕай саптаах* ‘с шелковыми нитками’, *көмүс күөгэл иннэлээх* ‘с золотыми иголками’. На протяжение веков будущие невесты обучались различным традиционным ремеслам, включая вышивание, бисероплетение, шитье одежды и изготовление берестяной посуды.

Таким образом, в якутском героическом эпосе олонхо, народных преданиях и произведениях якутских писателей образ молодой девушки-невесты становится многозначным символом красоты, добродетели и культурной традиции. Образ идеальной невесты актуализируется через такие ключевые понятия как белоснежный лик, черные соболиные брови, длинная коса, тонкая прозрачная кожа, добрая душа, проницательный ум, красивый голос. Он отражает идеалы общества и служит основой для формирования представлений о женственности в якутской культуре.

ЛИТЕРАТУРА

1. Большой толковый словарь якутского языка: в 15 т. Т. IV: Буква К, 2007; Т. VIII: Буква С: с – сөллөҕөр, 2012.

2. Борисов Ю.П. Концепт «невеста богатыря» в ранних текстах якутского олонхо: феноменологический аспект // Проблемы исторической поэтики. 2023. Т. 21. № 2. С. 66–85.

3. Габбасова А.Р. Репрезентация концепта «свадьба» в русской и башкирской языковой картине мира: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Уфа, 2013. 24 с.

4. Гимашева Г.М. Концептосфера «Ғаилә» («Семья») в творчестве Мустая Карима: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Уфа, 2022. 24 с.

5. Джеенбаева К.А. Концепт свадьба в кыргызской и русской лингвокультурах // Вестник Ошского государственного университета. 2023. № 2. С. 175–182.

6. Древнетюркский словарь / под ред. В.М. Наделяева и др. Л.: Наука. Ленингр. отд-ние, 1969. 677 с.

7. Караоол Л.С. Лексика предсвадебного обряда в тувинском языке // Урало-алтайские исследования. 2015. № 4 (19). С. 17–31.

8. Кульсарина Г.Г. Вербализация концепта «туй» («свадьба») в башкирской языковой картине мира (на материале фольклорных текстов) // Вестник ВЭГУ. 2014. № 4 (72). С. 112–118.

9. Пекарский Э.К. Словарь якутского языка: в 3 т. 2-е изд. М., 1959. 3858 стлб.

10. Скрябина А.А. Наименования действующих лиц свадебного обряда в якутском языке // Филологические науки. Вопросы теории и практики. 2025. Т. 18. № 3. С. 1032–1037.

11. Хасанова Ф.Х. Лингвокультурологическое поле концепта «Туй» в татарской языковой картине мира: автореф. дис. ... канд. филол. наук. Казань, 2008. 24 с.

12. Якутско-русский словарь. М.: Советская энциклопедия, 1972. 608 с.

УДК 811.512.01

Таһирова Фәридә Инсан кызы
ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
Казан, Россия
Тагирова Фяридя Инсановна
Институт языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
Казань, Россия
Tagirova Fyaridya Insanovna,
G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art
of the Tatarstan Academy of Sciences
Kazan, Russia
E-mail: feride2412@mail.ru

БҮГЕНГЕ ТАТАР ЛЕКСИКОГРАФИЯСЕНЕҢ КАЙБЕР ТЕОРЕТИК МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

НЕКОТОРЫЕ ТЕОРЕТИЧЕСКИЕ ВОПРОСЫ СОВРЕМЕННОЙ ТАТАРСКОЙ ЛЕКСИКОГРАФИИ

SOME THEORETICAL QUESTIONS MODERN TATAR LEXICOGRAPHY

Аннотация. *Работа охватывает небольшой спектр самых существенных теоретических вопросов, непосредственно связанных с практикой составления словарей: принципы отбора лексики, требования нормативности, обеспечение системности и т. п. Также подчеркивается в работе лексикографа вопросов, сопряженных с решением также проблем общелингвистического характера.*

Annotation. *The work covers a small range of the most significant theoretical issues directly related to the practice of compiling dictionaries: the principles of vocabulary selection, the requirements of normativity, ensuring consistency, etc. The lexicographer's work also highlights issues related to solving problems of a general linguistic nature.*

Ключевые слова: *лексикография, татарский язык, словарь, кодификация*

Keywords: *lexicography, Tatar language, dictionary, codification*

Татар лексикографиясенең тирән тарихы һәм бай традицияләре бар. Алар һәм фәнни һәм фәнни-популяр әдәбиятта чагылыш таба. Темага кагылышлы соңгы елларда чыккан хезмәтләрне генә күздән кичерү дә сүзлекчелек мәсьәләләренең актуальлеген югалтмавын күрсәтә [6; 9; 7; 8; 3 h. б.]. Фәнни эзләнүләрнең татар сүзлекчелегенә юнәлгән игътибары, әлбәттә, юкка гына түгел. Татар лингвистикасында сүзлекләр төзү эшенең туктalып торганы юк, хәзерге вакытта да интенсив рәвештә дәвам итә. Соңгы биш ел эчендә генә дә төрле типтагы берничә дистә сүзлек дөнья күргән. Бу хезмәтләрнең барысы да практик һәм теоретик сүзлекчелек эшенең реаль чагылышы ул. Эшнең бу ике тарафын аеру мөмкин дә түгел, чөнки теоретик өлеш кертелмәгән сүзлек чынлыкта юк һәм була да алмый. Һәм киресенчә, теоретик лексикографиянең бурычлары турыдан-туры гамәлдә сүзлекләр төзү вакытында барлыкка килгән проблемалар һәм аларны хәл итү белән бәйле.

Теоретик лексикографиянең приоритет юнәлеше булып татар лексикасын үстерү кала. Хәзерге вакытта тел процесслары һаман да тизләнә, лек-

сикада бигрәк тә. Билгеле вакыт аралыгында телгә кергән яңа берәмлекләр саны да, мәгънәсен үзгәртү, кулланыштан төшеп калу, стилистик статусы үзгәрү очраклары һ. б. да күбрәк. Бу эш күргән-ишеткән сүзләрне туплау һәм теркәү белән генә чикләнмәвен ассызыкларга кирәк.

Лексиканы үстерүнең икенче ягы булып, яңа сүзләр, бигрәк тә яңа терминнар ясау эше тора. Ул да турыдан-туры теоретик үзенчәлеккә ия. Алдарак нәшер ителгән аерым тармакларга караган терминологик сүзлекләр туктаусыз анализлана, үзара чагыштырыла, терминнарның актуальлеге (чөнки алар да искерә), дефинициялəрнең тулылыгы, иске атамаларның һәм аңлатмаларның яңа классификацияләр һәм систематикаларга туры килүе тикшерелә. Төрле фәнни, фәнни-популяр хезмәтләрдә, язма истәлекләрдә булган, ләкин сүзлекләрдә теркәлмәгән яки искергән терминнарны сүзлектә теркәү мөмкинлеге карала, әзер сүзъясалыш калыплары нигезендә яңа терминнар ясау мөмкинлеге, гомумән татар теленең бу өлкәдәге потенциалы бәяләнә һ. б. лар эшләнә.

Теоретик лексикографиянең икенче, бәлки тагын да мөһимрәк, бурычы – кодификация һәм нормалаштыру эше. Яңа берәмлекләрнең һәр яктан дөрес булу-булмавын – мәсәлән, татар теленең сүзъясалыш калыпларына һәм мантыйгына туры килү-килмәве, язылышы һ. б. үзенчәлекләре күзлегеннән тикшерү, аларның телдәге норматив статусын билгеләү эше һ. б. һәрдаим дәвам итә. Бу эш аеруча әлеге берәмлекләрне сүзлекләрдә теркәү өчен кирәк. Алга табан бу мәсьәләгә конкретрак кагылып үтәрбез.

Гомуми планда карасак, сүзлек төзү барышында сүзлекче хәл итәргә тиеш булган проблемаларны ике төркемгә бүлеп карарга мөмкин. Беренче төре теоретик тел белеменең графика, орфография, морфология, сүзъясалыш кебек берәр өлкәсенә караган хәл ителмәгән мәсьәләләр. Әйтик, берәр тел проблемасына багышланган мәкаләдә яки монографиядә «бу мәсьәләгә карата шундый-шундый фикерләр бар, ул әлегә бәхәсле булып кала» рәвешендә язылырга мөмкин. Сүзлек эшләгәндә исә алар кискен рәвештә килеп баса һәм шушы урында һәм шушы мизгелдә конкрет хәл итүне сорый. Бу турыда В.В. Морковкин үз фикерен бик үтемле итеп белдерә: «<...> роль автора-составителя словаря как кодификатора в теоретическом плане явно недооценена в силу ограниченного, даже ошибочного представления о ней. Представляется, что лексикограф имеет дело с некой готовой лингвистической интерпретацией языковых явлений, которую лексикографу остается только взять и использовать. Между тем, если обратиться к описаниям языка, <…> общезначимые решения в лингвистике скорее исключение, чем правило. Правилом же является нечто противоположное – наличие широкого спектра альтернативных, несходных и взаимно дополнительных точек зрения практически по каждому из существующих вопросов начиная от определения понятия «слово» и кончая интерпретацией целых лексико-грамматических классов (ср. местоимения, числительные, категория состояния и некот. др.)». [2]. Ә бит һәр берәмлек билгеле язылышта, төгәл морфологик яки стилистик помета белән төгәл үз урынында теркәлергә тиеш һәм теркәлә дә. Шулай итеп, бу бәхәсле мәсьәләгә карата конкрет фикер дә теркәлә. Хәтта сүз хәл ителгән тел мәсьәләләре турында барса да, шул ук В.В. Морковкин әйтүенчә, аларны һәр конкрет

очракта лексикография эшендә гамәлгә ашыру катлаулы, чөнки сүзлекченең алдында торган тел фактларының «исемлеге ачык», ягъни һәрдаим тулылана тора.

Сүзлекчелекнең гамәли тарафына турыдан-туры караган, шул ук вакытта аның теоретик нигезен тәшкил иткән проблемаларны да күрсәтеп үтү урынлы. Аларның кайбер иң мөһимнәренә генә игътибар итик:

1. Сайлап алу критерийларын билгеләү. Мәсәлән, диалект сүзләрен алу-алмау мәсьәләсе. Аларның кайсы әдәби телне баетырдай берәмлек, кайсы кирәкмәгән дублет, ялгыш вариант һ. б.ш. булып тора? Аларны алганда нинди билгеләргә таянырга? Шул ук проблема тиешле рәвештә кодификацияләнмәгән яки сүзлекләрдә бөтенләй теркәлмәгән гади сөйләм, сленг, профессиональ жаргон, алынма һ. б. сүзләргә карый.

2. Алынган очракта статусын ничек билгеләргә: ул әдәби сүз булып китәме яки берәр стилистик төсмер белән каламы? Нинди помета белән бирелергә тиеш? Стилистик статусы үзгәргән очраклар җанлы тел системасында сирәк түгел, һәм аларны вакытында бәяләп, тиешле коррективалар кертү шулай ук сүзлек төзүченең бурычы.

3. Сүзлекнең лөгатлегенә кертеләсе лексик-фразеологик берәмлекләрне туплау өчен чыганакларның ышанычлылыгын билгеләү, башкача әйтсәк, авторитетлы чыганаклар мәсьәләсе. Мондый таләпләргә югары сыйфатлы әдәбият кына җавап бирүе сүзлекчеләр тарафыннан гомуми кабул ителгән. Шул ук вакытта, күп кенә белгечләр, мәсәлән, Ж.М. Гузеев, чыганакның һәм авторның нинди генә авторитетлы булуына карамастан, тәнкыйть күзлегеннән карап, фәнни анализ ясамыйча бер сүзне дә әдәби тел сүзлегенә теркәргә ярамый, чөнки аларда да уңышсыз сүзьясалыш калыбы, куллану очрагы яки гап-гади хата булырга мөмкин, ди [1: 17].

Аеруча бу фикерне электрон корпуслар һәм базалар белән эшләгәндә хәтерләргә кирәк. Чөнки еш кына теге яки бу берәмлекне лөгатьлеккә кертү яки кертмәүне хәл иткәндә яисә сүзлектә берәр сүз теркәлмәвен тәнкыйть итеп, «фәлән электрон корпуска кергән бит» кебек аргументлар китерелә. Белгечләр исә корпусларга кертелгән текстларга карата кырыс таләпләр куелмавын белә, шуңа күрә аларны җәлеп итүнең чикле булырга тиешлеген аңлый.

4. Сүзлеккә теркәләсе берәмлекнең сүз булуын аныклау, сүз чикләрен билгеләү һәм аны башка берәмлекләрдән аеру, ягъни сүзне идентификацияләү. Сүзлектә баш сүз / мәкалә башы / вокабула / реестр сүз итеп теркәлгән һәр берәмлек бер үк статуста була: ул сүз яки (сүзлек төренә карап) сүзтезмә, фразеологизм һ. б.

Бу таләп конкордансларда гына үтәлми. Сүзлектә, мәсәлән, *китап* сүзе генә бирелсә, конкорданста аның *китапка, китаптан, китабы* кебек теләсә нинди формасы да теркәлә, шуңа күрә дә алар чын мәгънәсендә сүзлек булып саналмый һәм сүзлек функцияләрен үти алмый. Конкордансларның үз бурычлары һәм мөмкинлекләре бар. Алар билгеле әсәрдә яки авторда сүзнең кулланылу-кулланылмавын, аның контекстларын, ешлыгын, гомумән потенциалын аңларга мөмкинлек бирә. Конкордансларның үзенчәлеге шунда ки: бу мөмкинлекләрдән файдалануны аларның электрон варианты тулырак тәэмин итә. Шуңа күрә, сүзлекләрдән аермалы буларак, аларның басма вариантының белешмәлек сыйфатлары бермә-бер түбән була.

5. Сүзлекнең һәм лөгатьлекнең баланслылыгы, системалылыгы, эзлеклелеге һәм бердәйлеге мәсьәләсе дә җитди якын килүне таләп итә. Бер үк төр, класс, категория һ. б.ш. караган атамалар я барысы да теркәлергә тиеш, я билгеле принцип нигезендә сайлап алынырга тиеш. Бер үк морфологик яки структур статустагы берәмлекләрнең аңлатмалары / тәрҗемәләре бердәй яки охшаш булырга тиеш. Төрле тематик төркемнәр яки стилистик катламнар арасында зур күләм дисбалансы булырга тиеш түгел. Бигрәк тә норматив сүзлекләрдә бу таләпләр тиешенчә үтәлергә тиеш һ. б.

Югарыда күрсәтелгән һәм башка шундый мөһим тезислар һәр сүзлекченең белергә һәм эшендә таянырга тиешле төп принциплар булып тора. Боларның кайберләре моңа кадәр дә яктыртылды [5].

Сүзлек төзү эшендә сүзлекче булмаган кешенең күзенә бәрелеп тормаган, бер уку йортында да өйрәтелмәгән һәм үзлегеннән өйрәнү кыен булган тагын күп кенә нечкәлекләр бар. Аларны шул эштә зур тәҗрибә туплаган белгечләр генә күрә ала. Шуның өчен үзешчән, компетентсыз басмалар мәсьәләсендә дә шул белгечләр – турыдан-туры гамәли сүзлекчелек белән шөгыльләнгән галимнәр тарафыннан фикер әйтелергә тиеш. Кайбер хезмәтләребездә бу мәсьәләгә галимнәрнең игътибарын җәлеп итәргә тырышкан идек [4].

Әлеге мәсьәләләрнең күпчелеге универсаль характерда, ягъни алар барлык милли телләрнең лексикографияләрендә һәм рус лексикографиясендә мөһим булып кала. Күп кенә махсус хезмәтләрдә дә, бигрәк тә рус галимнәре тарафыннан шактый җентекле итеп яктыртыла. Ләкин гамәлгә килсәк, сүзлек төзү белән шөгыльләнгәндә бу җитди теоретик хезмәтләр белән танышу мөмкинлекләре чикле.

Сүзлекчелекнең югарыда күрсәтеп үтелгән һәм гомумән хәзерге татар лексикографиясенең актуаль проблемаларын системалы рәвештә тикшерү һәм чишелеш юлларын билгеләү, гамәли лексикография өлкәсендәге белемнәрне системалаштыру, күп еллык практик лексикография тәҗрибәсен махсус хезмәтләрдә чагылдыру сүзлек төзү эшенең гамәли ягына да ярдәм итәр, төзелгән сүзлекләрнең сыйфатында да уңай чагылыр иде. Татар теленең гомуми үсеш тенденцияләре һәм аның хәзерге объектив вазгыяте халыкның академик һәм гомуми характердагы сүзлекләргә ихтыяҗының тотрыклы булуын, мондый хезмәтләрне төзү һәм бастыруны дәвам итүнең кирәклеген раслый. Шулай булгач, теоретик лексикография юнәлешендә дә эзләнүләр дәвам итәргә тиеш.

ӘДӘБИЯТ

1. Гузеев Ж.М. Проблематика словника толковых словарей тюркских языков. Нальчик, 1984. 158 с.

2. Морковкин В.В. Об объеме и содержании понятия «теоретическая лексикография» // Вопросы языкознания. 1987. № 6. С. 33–42.

3. Сафаров Р.Т. Слово об «Этимологическом словаре татарского языка» // Золотоордынское обозрение. 2016. Т. 4, № 2. С. 458–460. – EDN WELFIJ.

4. Tagirova F. Sözlüklerin Normatif Fonksiyonu Meselesi // Türk Dil Kurumu Yayınları. VII. Uluslararası Türk Dili Kurultayı. 24-28 Eylül 2012. I. CİLT. Ankara, 2020. S. 687–691.

5. Тагирова Ф.И. «Толковый словарь татарского языка» в 6 томах в свете современной лексикографической парадигмы // Теория языка и межкультурная коммуникация. 2023. № 2(49). С. 349–360. – EDN IWEZIF.

6. Татар лексикологиясе: өч томда / проект җит. М.З. Зәкиев; ред. Г.Р. Галиуллина. Казан: ТӘhСИ, 2018. Т. III. 2 кис. 464 б.

7. Тимерханов А.А. О некоторых тенденциях развития современной национальной лексикографии // Научный Татарстан. 2010. № 4. С. 184–189.

8. Тимерханов А.Ә. Татар лексикографиясенең үткәне һәм киләчәккә бурычлары // Фәнни Татарстан. 2015. № 4. С. 21–34.

9. Юсупова А.Ш. Лексикографическое наследие татарского языка. Казань: Алмалит, 2010. 133 с.

УДК 811.512.145

Тимерханов Айнур Ахатович
Академия наук Республики Татарстан
Казань, Россия
Timerkhanov Aynur Akhatovich
Tatarstan Academy of Sciences
Kazan, Russia
E-mail: timtako22@mail.ru

«ТОЛКОВЫЙ СЛОВАРЬ ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА» В 6-ТИ ТОМАХ (2015–2021 ГГ.): НОВЫЙ ЭТАП В РАЗВИТИИ ТАТАРСКОЙ ЛЕКСИКОГРАФИИ

«EXPLANATORY DICTIONARY OF THE TATAR LANGUAGE» IN 6 VOLUMES (2015–2021): A NEW STAGE IN THE DEVELOPMENT OF TATAR LEXICOGRAPHY

Аннотация. *Статья посвящена выходу шеститомного «Толкового словаря татарского языка» (2015–2021 гг.), ставшему важным этапом в развитии татарской лексикографии. Рассматриваются ключевые принципы составления словаря, охватывающего всю сферу современной татарской лексики, включая неологизмы, заимствования, специализированную терминологию и культурно-историческую лексику. Особое внимание уделено уникальной татарской лексике, важной для сохранения этнокультурного наследия. Новый словарь отличается значительным объемом словника, широким использованием иллюстративного материала и соблюдением современных принципов научного подхода. Аннотируемый источник призван служить надежным ориентиром для исследователей, педагогов и широкого круга пользователей, заинтересованных в изучении и сохранении татарского языка.*

Annotation. *The article is devoted to the publication of the six-volume «Explanatory Dictionary of the Tatar Language» (2015-2021), which became an important stage in the development of Tatar lexicography. The article considers the key principles of compiling a dictionary covering the entire sphere of modern Tatar vocabulary, including neologisms, borrowings, specialized terminology and cultural and historical vocabulary. Special attention is paid to the unique Tatar vocabulary, which is important for the preservation of ethnic and cultural heritage. The new dictionary features a significant vocabulary volume, extensive use of illustrative material, and adherence to modern principles of scientific approach. The annotated source is intended to serve as a reliable reference point for researchers, educators, and a wide range of users interested in learning and preserving the Tatar language.*

Ключевые слова: *татарский язык, лексикография, толковый словарь, лексическое богатство, сохранение языка*

Keywords: *Tatar language, lexicography, explanatory dictionary, lexical wealth, language preservation*

Словари являются фундаментальным элементом формирования культурного ландшафта общества, наглядно демонстрируя объем накопленных человечеством знаний и степень цивилизационного прогресса. Особенное значение среди множества лингвографических справочников принадлежит толковым словарям, воплощающим важную культурно-историческую миссию – они служат важнейшим инструментом, помогая современному пользователю разобраться в непрерывно меняющихся процессах языка и культуры.

Появление значительных словарных проектов служит ярким показателем уровня развития нации и богатства её интеллектуальной сокровищницы. Каждая эпоха вправе гордиться своим собственным словарем, отражающим её дух, ценности и мировоззрение. Толковый словарь становится своеобразным зеркалом эпохи, фиксируя лингвистические трансформации, обусловленные развитием общественного сознания и изменением запросов социума.

Толковые словари представляют вершину лексикографической практики, причем языки с богатой письменной традицией обладают несколькими такими словарями. Именно они аккумулируют накопленные знания и позволяют зафиксировать текущее состояние языка, включая новую лексику, терминологию и стилистические изменения. Такие словари важны не только для исследователей, филологов и лингвистов, но и для широких слоев населения, обеспечивая понимание исторических, культурных и социальных аспектов функционирования родного языка.

В тюркской лексикографии создана богатая база в этом направлении. Тем не менее некоторые современные тюркские языки получили собственные толковые словари сравнительно недавно. Например, «Толковый словарь тувинского языка» начал издаваться лишь в начале XXI века (том 1 – 2003 г.; том 2 – 2011 г.) [1], а первый «Толковый словарь хакасского языка» увидел свет совсем недавно, в 2020 году [2].

Татарская лексикография имеет богатый опыт в создании толковых словарей. Одним из первых значимых трудов в этой области стало издание «Ләһҗә́и татари» («Татарское наречие») выдающегося татарского просветителя Каюма Насыри в конце XIX века, содержащее около 20 тысяч слов [3; 4]. В 1927 [5], 1929 годах [6] были изданы две части первого тома «Полного словаря татарского языка» Джамала Валиди.

Значительным успехом татарской и тюркской лексикографии своего времени стал трехтомный «Толковый словарь татарского языка» 1977–1981 гг. (32000 слов, 14000 фразеологических единиц) [7; 8; 9]. Его лучшие традиции были реализованы позднее в однотомных «Толковом словаре татарского языка» 2005 года (52000 слов, 6000 фразеологических единиц) [10] и «Школьном толковом словаре татарского языка» 2013 года (10000 слов) [11], которые представляют собой словари оперативного пользования. Они отражают состояние и динамику развития татарского языка

конца XX в. Каждый из них – это оригинальный труд с конкретными целями и пользовательской аудиторией.

Несмотря на значительные успехи национальной лексикографии прошлых лет, современный этап ее развития требует непрерывного обновления словарей и расширения существующих словарных ресурсов, отражающих динамику изменений в лексике татарского языка в условиях глобализации, цифровизации и трансформации общественной жизни. Такая потребность обусловливается также интенсивным развитием междисциплинарных научных подходов к интерпретации языкового материала, совершенствованием методов анализа и углубленным изучением ранее известных фактов. Нередко возникает необходимость и кардинального научного переосмысления предыдущего лексикографического опыта ввиду того, что в прежних словарях выявляются неполные дефиниции, несоответствие старых толкований с новыми классификациями и подходами к систематизации, отсутствие новых значений слов, несоответствие нормативного статуса, недостаточное количество зафиксированных дериватов, спорный или неопределенный этимологический, морфологический, орфографический и акцентологический статус и множество других погрешностей, требующих оценки и исправления.

Совершенно новый этап в развитии тюрко-татарской лексикографии ознаменовался выходом шеститомного «Толкового словаря татарского языка» (2015–2021 гг.) [12; 13; 14; 15; 16; 17]. Данный проект – это итог почти двадцатилетнего труда нескольких поколений ученых-языковедов отдела лексикографии ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова АН РТ под началом профессора Ганиева Ф.А., чей труд был продолжен и доведен до логического завершения его последователями под руководством автора этих строк.

Словарь характеризуется масштабностью и глубиной исследования, охватывая наиболее полный спектр современных лексико-грамматических явлений татарского языка. Его отличительной чертой является фиксация как традиционной, так и инновационной лексики, включая неологизмы, заимствования и специализированные термины. Общий объём словника превышает 70 тысяч слов, 10 тысяч фразеологических единиц, что существенно превосходит предыдущие аналоги. Это самый полный и совершенный из всех видов татарских словарей с точки зрения описания основного фонда лексико-фразеологического богатства национального языка.

Он выполняет нормативную функцию, существенно расширяет исследовательскую базу для системного описания татарского языка.

